1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ГЫЙНВАР № 1

СӨЕМБИКӘ

ТЫЛМАЧ
кешелек белән бергә туган һөнәр

«ҺАМАН ЯРАТАМ»
җыр тарихы

ИРЕМ ӨЙЛӘНӘ
мин – икенче хатын

Айгөл НӘБИУЛЛИНА:

«ЭЗЛӘП ТАПКАН БӘХЕТ КАДЕРЛЕ...»





70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

Гаҗиз булып, тилмереп көтеп алынган, кат-кат укылган, һәр сүзе ятланган, күз яшьләренә чыланган өчпочмаклы солдат хатлары... Дары исе сеңгән, сугыш дигән мәхшәрнең эченнән килгән... Тормыш авырлыгыннан басылган иңнәргә кабат канат куйган, өзелә язган өметләрне тергезеп җибәргән, күңелдә ышаныч уяткан. Хаты килеп ирешкән икән, димәк, исән! Кайтыр! Сугыш кына бетсен! Ә чынбарлыкта... Хатлар, кәгазьгә язган сүзләр күп очракта аларга җан җылысы салган хат иясе гомереннән озынрак булып чыккан.

Здравствуй, дорогая моя сестра!!!

Прими от меня пламенный привет и наилучших пожеланий в твоей суровой армийской жизни.

Дорогая моя, вчера получила от тебя письмецо от 3-3 45 г., за которое искренно благодарю.

Роза, я очень рада, что связь наша налаживается. Послала тебе бумаги, может быть получила, и 200 р. деньги.

Если получишь, опять пошлю.

Живу по старину, в этом же госпитале. Работы хватает, приходится работать день и ночь.

Вот уже недели не работаем, отдыхаем. Сегодня приказ на передислокацию, дальше вглубь Германии. Собираемся, я сижу, пишу тебе письмо, тороплюсь.

Я о тебе ничего не знаю. Если можно, в другом письме пиши, как живешь, с кем, с чем как говорится. Дружишь ли с кем-нибудь? Смотри не верь мужикам, в армии все мужики нахалы, я не кому не верю. Дружила многими, но себя держу как надо, после войны перед кем-нибудь придется отчитываться. Так что, дорогая, береги себя. Не верь мужикам, особенно красивым. Гуляй, но знай себя. Думай, что жизнь твоя впереди. Я насколько старше тебя, и то жалею себя, юность. Вот так. Пиши, что тебе надо, я постараюсь помочь тебе в любое время. Равза, 13.03.1945 домой посылку послала, разное барахло платья, сахар и т.д. всего 5 кг. 1000 руб. деньги послала. Слава богу, хоть на этом немного помогла им. Получаю письмо из дома регулярно, от Исмаила редко. Ты все спрашиваешь, где я нахожусь, кем я работаю. По моему я на каждом письме пишу, что я в Германии работаю в госпитале медсестрой. Вот ты никогда не пишешь кем ты работаешь. Досвидания, дорогая моя. Целую крепко, крепко.

Пиши по русский, письма такие быстрее ходят.

16. 03. 1945.

Ф. Р. Пожалуеваның сеңлесе Розага язган хаты (хат Минзәлә районының крайны өйрәнү музеенда саклана). Роза Рәхим кызы фронтка 1943 елны китә. Туган ягына 1945 елны, сугыш тәмамлангач кына әйләнеп кайта. Хатны үзгәртмичә-төзәтмичә тәкъдим итәбез.


на фото: 1945 год, Чехословакия. Р.Р. Пожалуева в нижнем ряду справа

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2011 елның 23 мартында «Сюмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы ПИ № ФС 77-44363



2007, 2008, 2009 елларда журнал Россия матбугатының Алтын фондына кертелде.

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.



Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте
Казан, Академия урамы, 2.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рафикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова
Pre-press:
Игорь Глушков

Тышлыкта:
Айгөл Нәбиуллина
Фото: Газинур Хафизов

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Күләме 8 басма табак.

Басарга кул куелды: 21.01.2015 ел.
Заказ О-37.
Тираж 7630

Журналда полиграфия кимчелеге булган очракта нәшриятның техник контроль бүлегенә мөрәҗәгать итегез. Тел.: 519-44-61.

Журналны тарату мәсьәләләре белән абунәчеләр – җирле элемтә бүлегенә; элемтә бүлекләре – нәшриятның газета-журнал экспедициясенә (420066, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Тел.: 562-10-66) мөрәҗәгать итә ала.

Банк реквизитлары:
Филиал ОАО «Татмедиа»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламалар аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Нәшер итүченең адресы: Казан, Академия урамы, 2, ААҖ «Татмедиа».

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.



Сату бәясе – килешү буенча.

Роберт МИҢНУЛЛИН

Казан кышы

Казаныма тагын карлар кайтты,
Ак бураннар кайтты, ак көннәр.
Ак кар гүя кияү-кәләш өчен
Әзерләнеп куйган ак мендәр.

Тик чәчләргә төшкән ак түгел бу,
Кәфенлек тә түгел, ә шатлык.
Яшь кызларның ак хисләре кебек,
Ак шәлләре кебек бу аклык.

Казаныма тагын карлар кайтты,
Урамнары китте яктырып.
Сагындырган икән кар кызлары,
Сагындырган карлы яктылык.

Күмеләсе килә көртләренә,
Ураласы килә буранга.
Ярсуларны тыеп буламыни,
Янәшәңдә буран булганда...

Бар аклыгы кучәр күңелеңә,
Ак карларга сөеп бак кына.
Казаныма тагын карлар кайтты,
Дөньяларым һаман ак кына.





Фото: Газинур Хафизов

Саҗидә СӨЛӘЙМАНОВА

Кар ява

Буранланып яңа еллар керә.
Ак аргамак – давыл яллары –
аргы очтан оча бирге очка,
сыкы чәчле кышка юл ярып.
Иске елдан чыгам изге юлга –
җир карасын каплап, кар ява.
Кар өстендә, акка кара булып,
карганалар ала каргалар.
Каргышлары оча аргы очка.
Безнең очта бәйрәм-нарасый!
Аргамакның ялкын-ялын кочып,
барасы да әле, барасы! –
Зәмһәрирләр белән сызгырышып,
Зөлхиҗәләр белән биешеп!
Көтә мине кары кагылмаган
көмеш кыңгыраулы бер ишек!
Кагылырмын –
кар-бизәкләр сибәр
кыңгырауның көмеш чыңнары.
Кышкы бураннарга уралып бара
серле хыял, кырыс чынбарлык.
Берәүләргә – салкын кар бөртеге,
берәүләргә – йолдыз, энҗеләр!
Карны кар дип белгән син акыллы,
ак чәчәкләр күрәм мин җүләр.
Җил-давылда җылы яңгыр күрә –
кыр-далада бүген ил күзе.
Игенченең хыялында шаулый
уҗымнарның яшел диңгезе.
Уең нинди, шундый төскә буя –
өр-яңадан дөнья агара!
Җир карасын, кыр ярасын каплап,
өметләрне аклап кар ява.





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





20

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8

СЫНАУЛАРНЫ БЕРГӘ УЗАРБЫЗ!
М. Авзалова



ҖИР СУЛЫШЫН ИШЕТӘМ!
М. Кашапова,
Ф. Моратова

16



12

ТЫЛМАЧ
Г. Сафиуллина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24

БЕЗ БУЛМАСАК, КЕМ?
Л. Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК


МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34

САФ АЛТЫН
А. Юнысова

40



КАЙТАРЫЛУ СЕРЕ
А. Хәлим

ЯШӘЕШ 

48



«ҺАМАН ЯРАТАМ»
Э. Закирова

ШУЛАЙ УК: 

БЕЗ БУ ҖИРДӘ КУНАК КЫНА 26
Р. Камалетдинова

«БИРДӘНБЕРЕМ ДИГӘН ИДЕҢ...» 50
М. Авзалова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60



ӨЙ «ЧИТЕГЕ»

ҺӘР САНЫБЫЗДА: 

БЕЗНЕҢ ПОЧТА 6

ДӨНЬЯ ГАМЕ 11


ФОТОРЕПОРТАЖ 32

ШИГЪРИЯТ 38

РӘССАМ СӘХИФӘСЕ 64







«Сөембикә» журналында Рәисә Миңлегәрәеваның «Кайтыр идем туган якларга» дигән сүзләрен укыдым да, җавап язарга утырдым.

Мин – Нәсимә Корбангали кызы – Башкортстанның Ахун авылында туганмын. Мәктәпне тәмамлап, 1975 елда Үзбәкстанга чыгып киттем. Бохара шәһәрендәге туку фабрикасына эшкә урнаштым. Соңрак шул юнәлеш буенча укып, технолог булып эшләдем. Инде хәзер пенсиядә. Татар-башкорт милли-мәдәни үзәгенең эшендә катнашып йөрим. Үзебезнең милли костюмнарыбызны тегеп, төрле бәйрәмнәр уздырабыз, «Сабан туй»ларында чыгышлар ясыйбыз. Кояшлы, җиләк-җимешле Үзбәкстанда тыныч-имин яшәп ятабыз. Милләтара ызгышлар да юк, ачлык-ялангачлык та күрмибез. Әмма бик авыр вакытлар да булмады түгел. Иң интектергәне эшсезлек иде. Гөрләп эшләп торган комбинатыбыз ябылды, банкрот, диделәр. Эш эзләп, кем кая таралды. Мин дә туган якларга юл тоттым. Өметләрем, уйларым якты иде. Туган ягымда тырышып эшләп, лаеклы ялга чыгарга, шушында төпләнергә уйладым. Әмма... Юкка гына өметләнгәнмен. Без инде монда да кирәксез һәм чит икән. «Башта туган ягыгызны сатып киттегез дә хәзер, тегендә кыса башлагач, исегезгә төштеме?» яки «Кайтып тулды инде җыен әтрәкәләм!» ише кимсетүләр яңгырады. Туып-үскән йортымны үги әни сатып җибәргән, кабат шул йортны сатып алырга теләсәм дә, акчам җитеп бетмәде. Санкт-Петербург шәһәрендәге туку комбинатына эшчеләр кирәк икән, шунда урнаштым. Тырышып эшләдем, кая кушсалар, шунда бардым. Төрле конкурсларда катнашып алган бүләкләрем дә күп. Комбинатта эшләүчеләр арасында кайсы гына милләт кешесе юк иде: белоруслар, украиннар, молдаваннар... Тик, нигәдер, үземә карата гел кимсетүле мөнәсәбәт тойдым. Үзбәкстаннан, дип, ничектер, мыскыллап карыйлар иде.

Хәзер улым белән киленем дә Уфа шәһәрендә яшиләр. Киленем – Мәскәүдә бухгалтерлыкка укыган кеше. Белеме буенча эшкә урнаша алмады. Ялланып, базарда сату итә. Улым төзелештә төрле кара эш башкара. Ни тырышып эшләсә дә, килешүдә күрсәтелгән хезмәт хакын түләмиләр.

Ярый инде, гел зарлану килешмәс, булганыннан Ходай аермасын. Шулай да кайберәүләрнең: «Туган якларын сатып киттеләр», – дигәне җанымны бик әрнетә. Мин туган ягымны сатмадым. Тәкъдир, язмыш алып китте безне. Кайвакыт комсомол оешмасы чакыруы буенча төрлебез төрле якларга таралдык. Ул вакытта Үзбәкстан чит ил түгел, колач җитмәс СССРның бер республикасы гына иде. Минем кебек, эшкә дип китеп, чит илләрдә бүленеп калучылар бихисап.

Туган ягымны, аның урманнарын бик сагынып яшим. Балаларымны да күрәсем килә. Исәнсау булсам, кайтып та килермен әле. Милләттәшләремә саулык-сәламәтлек, эшләрендә уңышлар телим, якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм.

Нәсимә ГУЛОВА (ИСМӘГЫЙЛЕВА). Үзбәкстан.

P. S. Хатны номерга әзерләп бетергәндә генә Нәсимә ападан күңелсез хәбәр килеп иреште, улы вафат булган. Нәсимә апаның авыр кайгысын уртаклашабыз.

Ага да ага сулар... Шул сулардай гомерләр ага.

13 гыйнвар көнне кадерле апабыз Айсылуга да 80 яшь тулды.

Апам Менделеевск районының (элеккеге Бондюг) Песәй авылында Шәмселбәнат белән Мулламөхәммәт гаиләсендә туа. Башта җидееллык мәктәпне, аннан Алабуга педучилищесын тәмамлап, Ютазы районы Урыссу мәктәбенә укытучы булып эшкә билгеләнә. Авыл халкы бик яратып кабул итә аны. Чибәр, яшь укытучыны кем яратмас! Укытучы апаларының туган авылын, якыннарын сагынудан күңеле сыктаганын гына беркем дә сизенми. Ара бик ерак шул...

Көннәрдән бер көнне мәхәббәтен очрата ул. Чибәр, гәүдәле, кара бөдрә чәчле, тырыш Әмирҗан белән таныштыра аны язмыш. Бер-бер артлы балалары Роза, Марсель, Илдар туа. Урыссуда

фатир алып, шунда яши башлыйлар. Тормышлары матур, яшәр җирләре бар, балалары үсә, бөтен дөньялары түгәрәк. Әмма бәхет түм-түгәрәк була алмый, ахрысы, кинәт кенә Әмирҗан авырып, дөнья куя.

Өч баласы белән туганнарыннан еракта берьялгызы калган Айсылу апаның хәлен күзаллыйсызмы? Үз хәлләрен үзе генә белгән инде ул. Тырышкан, тырмашкан, балаларын аякка бастырган. Балалар шатлыгы белән шатланып, тыныч кына яшим дисә, янә хәсрәт. Чаллыда яшәүче улы Илдар да вакытсыз гүргә керә. Айсылу апаның хәсрәтен аңлатырдай сүзләр дөньяда юктыр ул. Үз башына төшкән кеше генә аңласа аңлар. Инде монысын да күрдек, алга таба авыр хәсрәт күрсәтмә дип яшәп яткан көннәрдә, янә аяктан егарлык хәбәр. Кызы Розаның бердәнбер улы Радислав юл һәлакәтендә вафат була. Ике кызы ятим кала.

Кеше тормышы шулай катлаулы борылышлар, авыр юллар аша үтә шул. 44 ел мәктәптә балаларга белем биргән Айсылу апа хәзер инде лаеклы ялда. Кызы Роза, кияве Фәнис белән бер-берсенә булышып, ярдәмләшеп яшиләр. Оныклары Эльвира, Әмир, Алинә, туруннары Радмира һәм Милана белән аралашып, аларның уңышларына куанып гомер кичерә Айсылу апа. Җылы оекбашлар бәйли, тәмле ризыклар пешерә, китап-журналлар укый, якыннарына, дөньялыктан күчкән газизләренә атап догалар кыла. Айсылу апаны яратабыз, хөрмәт итәбез.

Таң калабыз синең батырлыкка,
Сокланабыз синең сабырлыкка.
Йөзләреңә чыгармыйча
хәсрәт төсен,
Үстердең син балаларны
ялгызлыкта.
Карашларың җылы яңгыр кебек,
Елмаюың айдай сөйкемле.
Исемең дә җисемеңә туры килә,
Кояш сипкән нурлар шикелле.
Иң изге теләкләр белән, сеңлең

Илгизәр ТИМЕРГАЛИЕВА.
Менделеевск.

Сезгә беренче генә хат язуым түгел инде бу. Хатларымның берсе дә моңарчы җавапсыз калмады. «Сөембикә» ярдәме белән фатирлы да булдым хәтта. Һәрберегезгә рәхмәтләр яусын. Менә хәзер дә сезгә мөрәҗәгать итәм, бәлки, ярдәм итә алырсыз.

1978 елда урта мәктәпне тәмамлап, 1 сентябрьдә Ютазы районы Урыссу бистәсендәге «Электросоединитель» заводына эшкә килдем. Эшкә керешкәнче мине заводның училищесына укырга җибәрделәр. Менә шул көннән бирле мин заводта. Ул минем өчен кадерле һәм газиз бер йортка әверелде. Гаилә корып, дүрт бала үстереп, илле яшемнән пенсиягә чыктым (гарип балам булганлыктан, пенсия иртәрәк билгеләнде). Пенсиягә чыксам да, әле һаман шул эшемдә эшлим. «Завод ветераны», «Заводның мактаулы ветераны» исемнәренә лаек булдым. Пенсиягә чыгар вакыт җиткәч, Россия Космонавтика федерациясенең медале белән дә бүләкләделәр. Пенсия кенәгәсе белән медаль алу хакындагы таныклыкны тотып, районыбызның социаль яклау бүлегенә киттем. Аз булса да ярдәме тимәсме, янәсе. Чөнки биргән чакта бу медальне хезмәт ветераны медаленә тиңләшә дигәннәр иде. Кызганычка, ташламаларны бетергәннәр булып чыкты. Шулай итеп, мин ул медальнең өстенлекләреннән бер генә көн дә файдалана алмый калдым. Әле бу хатымны сезгә Мәскәүдән язам. Апамның юбилеена килгән идем. Ул яши торган районның социаль яклау бүлегенә барып сораштым. Аларда бу медаль өчен ташламалар бар икән. «Сезнең төбәктә генә бетергәннәрдер», – диделәр. 34 елдан артык эш стажым бар. Гомерем буе бер генә урында тырышып эшләдем, картлык көнемдә шул тырышлыгымның әҗерен күрергә өметләндем. Бар булган ташлама – ел саен бирелә торган чираттагы ялыма өч көн өстәмә. Завод тормышында да актив катнашып яшим: чаңгы ярышларын, төрле конкурсларны көтеп алам. 2012 елда «Балкыш» һәвәскәр ветераннар фестивалендә катнашып, үзебезнең ансамбль белән лауреат исеменә лаек булдык.

Минем кебек гомерләрен шушы заводка багышлаган кешеләр күп. Бу коллективта эшләвемә бик горурланам. Завод капкасын үтеп, эшкә кергәч, өйдәге барлык мәшәкать онытыла. Дус-тату яшибез, тырышып эшлибез. «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булу өчен ничә ел эшләргә кирәк икән соң? Әгәр дә бу медаль өчен булган ташламаларны бетергәннәр икән, киләчәктә, олыгайган көндә сөендереп торырлык башка берәр медальгә алыштырып булмый микән соң аны?

Венера ШӘЙХУЛЛИНА.
Ютазы районы,
Урыссу бистәсе.

P. S. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына юллаган соравыбызга алынган җавапка караганда, сезне медаль белән бүләкләгән Россия Космонавтика федерациясе иҗтимагый оешмалар исәбенә керә, һәм бу оешма биргән бүләкләр «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен нигез була алмый. Әмма завод җитәкчелеге Сезгә бу исемне бирүнең бүтән юлын, әмәлен табарга мөмкин. Аларга мөрәҗәгать итеп карагыз.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: suyumbike@telebit.ru

Яңа елга без һәрчак матур уйлар, якты өметләр белән аяк басабыз. Гел яхшысын гына уйлыйбыз. Шулай дип өйрәтәләр дә бит: әйбәтне юрасаң, әйбәткә булыр, диләр. Өйләребезгә, илләребезгә ишекне киң итеп каерып ачып кергән бу елны авыр булачак, илдә янә 2008 ел кабатланачак дип, кисәтеп-куркытып куйсалар да, кризис дигәннәрен инде бер кичергәнгәме, никтер күңелдә андый ук шом юк та шикелле. Гомумән дә, вакытлы кыенлыклар куркытмый безне.
Шулай да, долларның да, евроның да моңарчы бу кадәр «сикергәне», «кара алтын»ның бу кадәр тәгәрәгәне юк иде әле.
Ил җитәкчелеге бу хәлләрне кул кушырып, тыныч кына күзәтеп утырырга җыенмый анысы. Кирәгә искән җилләрне үз юнәлешенә бору, килеп туган проблемадан чыгу юллары эзләнә. Безне быел нинди үзгәрешләр көтә? Нәрсәгә әзер булып торырга безгә? Ил өстенә авырлык килдеме, иң беренче эш итеп яклауга аеруча мохтаҗлар турында борчыла башлыйсың. Бу очракта да... күп балалы әниләрнең, физик мөмкинлеге чикле кешеләрнең хәле тагын да катлауланмасмы? Эшсезлек артмасмы? Пенсиясе 6 меңнән артмаган өлкәннәр нишләр? Гомумән, безне нинди үзгәрешләр көтә? Берсеннән-берсе уйландырырлык сорауларны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира ЗАРИПОВАга юллыйбыз.



СЫНАУЛАРНЫ БЕРГӘ ҮЗАРБЫЗ!

Социаль ярдәм турында

– Ниһаять быелның гыйнвар аеннан әле 2013 елның 28 декабрендә үк кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданнарына социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында»гы федераль закон көченә керде. Шуның нигезендә «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне көйләү турында» Татарстан Республикасы законы һәм берничә норматив-хокукый акт кабул ителде. Бездә пенсиясе аз булган пенсионерларга бушлай социаль хезмәт күрсәтү каралган. Әгәр дә ул элек кереме 5709 сумнан түбән булган кешеләргә генә күрсәтелсә, хәзер инде андый кадер-хөрмәтне кереме 8563,5 сумнан түбән пенсионерлар да күрәчәк. Федераль законнарыбыз иң элек социаль ярдәмгә мохтаҗ катлау – күп балалы гаиләләр, балаларын ялгыз тәрбияләгән, авыру бала караган әниләр, инвалидлар турында кайгыртуга юнәлтелгән. Ул гомергомергә шулай булды һәм шулай булып калачак. Мондый вазгыятьтә социаль сәясәт уйланылган һәм киләчәккә төбәлгән булырга тиеш дип саныйм. Шушы уңайдан кертелгән яңалыкка гына игътибар итик: элек ата-аналарга 15 яшькә чаклы булган авыру баланы

караган өчен пособие түләнсә, бу елның 1 гыйнварыннан ата-аналар балага 18 яшь тулганчы пособие алачак. Бу җәһәттән, «Россия Федерациясе гражданнарына социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында»гы федераль законның көченә керүе, Россия Федерациясендә гаилә сәясәтендә дәүләт концепциясе гамәлгә аша башлау да безгә ныклы терәк булып тора. Шул законнарга, шул карарларга таянып эш итәбез. Балалы гаиләләргә күрсәтелә торган ярдәмнең артуын да әйтик: бала тугач та бер мәртәбә бирелә торган ярдәмнең күләме хәзер 14497,8 сум тәшкил итә; баласы яшь ярымга җиткәнче өйдә утыручы әниләргә ай саен: беренче балага – 2718,3 сум, икенче һәм аннан да күбрәк балалы әниләргә – 5436,7 сум акча бирелеп барылачак. Әйтергә кирәк, Ана капиталының суммасы да артты – ул 453026 сумга җитте. Россия Федерациясендә иң аз хезмәт хакы 5965 сум булса, Татарстанда ул икътисадның казнаныкы булмаган секторларында эшләүчеләр өчен 6420 сумны тәшкил итә. Күп булмаса да, аермасы бар һәм ул безнең файдага.

Эшсезлек турында

– Татарстанда эшсезлекнең артуы турында Президентыбыз да борчылып әйтте. Кызганычка каршы, шулай. Әле былтырның декабрь аенда гына эшсезләр саны 14651 тәшкил иткән булса, быелның гыйнварында, бер ай эчендә, 15211 гә авышкан. Мәшгульлек үзәкләре бу мәсьәлә белән бик җитди шөгыльләнәләр. Чынында, 35 меңнән артык эш урыныбыз бар. Тик, эшсез булуларына кармастан, берсе дә тәкъдим иткән эшкә барырга ашкынып тормый: күп акчалы эш кирәк! Ә бит үз эшеңнең остасына әверелгәч кенә әйбәт хезмәт хакы ала башлыйсың. Бу берәүгә дә сер түгел. Былтыр Үзәкләргә төрле мәсьәләләр буенча 164 мең кеше мөрәҗәгать иткән. Шуларның 72 меңе исәпкә куелган. Түләүле җәмәгать эшләрендә 11,7 мең кеше катнашкан, 453 инвалид вакытлыча эшкә урнашкан. 14 яшьтән 18 яшькәчә 22,3 мең егет һәм кызларыбыз да вакытлыча эшләп алган. 641 кеше үз эшләрен ачып җибәргән. Саннарга килгәндә, шулай.

> *Быелның 1 гыйнварыннан хезмәт ветераннарына һәм пенсионерларга айлык акчалата түләү – 399 сум, ә тыл хезмәтчәннәренә 595 сум тәшкил итә.*

Республикада формаль булмаган хезмәт базары барлыгын да онытмыйк. Дөрес, ул базарда эшләүчеләр саны әкренләп кими бара. Хәзер «соры» хезмәт базары икътисадый яктан актив халык санынннан караганда 12–14% тәшкил итә. Формаль булмаган хезмәт базары дигәндә, без хосусый эшмәкәрләрне, аларга ялланып эшләүчеләрне, төрле хосусый оешмаларда хезмәт итүчеләрне (ул таксист, юрист булып эшләргә дә мөмкин) күздә тотабыз. Шунысын кисәтергә тиешмен: без пенсия турында уйларга тиешбез. Картлыгыңда, әгәр иминият өлешенә үзең теләп акча күчереп бармасаң, минималь пенсия белән калу куркынычы яный. Шулай да, безнең халыкның мәшгульлек күрсәткече (68,8) илнеке белән чагыш-

КОТЛЫЙБЫЗ



Замана журналисты нинди булырга тиеш? Үткен, өлгер-житез, булдыклы һәм ярдәмчел. Кеше кайгысын йөрәгенә якын ала торган. Зарлы-моңлыга ничек тә ярдәм итү җаен эзли һәм таба торган. Чөнки «Сөембикә» кебек бөтен халык ярата торган басмага абунәче (абунәче генәме, хәтта журналны яздырып алмаган, күршесеннән яки дусларыннан алып кына укыштыручылар да бер-бер хәлгә тарыса, еш кына редакция телефонын җыярга тотына) нәкъ менә ярдәм өмет итеп шалтырата. Әйтик, Мәдинә Авзалова тотынса, берәр чарасы табыласына ышана. Чөнки «Сөембикә»дә егерме елдан артык эшләү дәверендә талантлы журналист кемнәрнең генә язмышында якты эз калдырмагандыр да, кемнәрне генә рәхим-шәфкатьле сүзе белән куандырмагандыр. Моны беләләр. Ә иҗат кешесе өчен борын-борыннан иң кадерле бүләк – укучының аны тануы, хөрмәт итүе... «Кешеләргә ярдәм итү – миңа Ходай тарафыннан йөкләнгән бурычтыр. Үтенеп киләләр икән, булдыра аламмы, юкмы – ярдәмгә алынам. Уйланган эш уңышлы гына барып та чыга. Авыр чакта кешене ташламыйм. Бу – минем принцибым. Кемгәдер булышмасам, көнем бушка, әрәмгә узган кебек», – Мәдинә Авзалованың бу сүзләре аны тулаем ача да сала инде!
Социаль темалар, кеше хокуклары, сәламәтлек, иҗтимагый оешмалар, авыл хуҗалыгы, милек, торак, ипотека... Тынгысыз журналист колачлаган темаларны санап чыгу да җиңелләрдән түгел шул!
Ул – һәрчак юлда. Ашыгыч ярдәм кебек, яхшылык эшләргә, игелек кылырга, башкаларны сөендерергә ашыга. Шуңа да эзләнүчән, туры сүзле, үткен каләмле Мәдинә Авзалова кебек шәхеснең хөкүмәт бүләкләренә лаек булуы гаҗәп түгел: Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистлары берлеге премиясе лауреаты, «Бәллүр каләм» иясе, Татарстан Президентының Мактау кәгазенә, дипломына лаек булды, «Сөембикә» журналының 100 еллык юбилее уңаеннан «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. Хезмәттәшебезне гомер бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз! Исәнлек-саулык, яңадан-яңа иҗат уңышлары юлдаш булсын аңа!

тырганда (65,6), күпкә өстен. Эшсезлектән, кризистан чыгу юлын Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов моңарчы чит илләрдән кертелгән товарларга алмаш булдыру программасы кысаларында республикада яңа заводлар эшләтеп җибәрүдә күрә. Андый заводлар бездә тиздән 8-9 лап булачак. Ә бу – янә эш урыннары дигән сүз.

Балага бирелә торган айлык пособие – 262 сум, ә әнисе белән генә тәрбияләнгән балага 696 сум булачак.

Эшсезләрнең 60 процентын хатын-кызлар тәшкил итсә дә, декрет ялында – өйдә бала карап утыручы әниләргә дә яңа һөнәр, яңа белгечлек үзләштерү өчен мөмкинлекләр бар. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә демографик сәясәтне гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы нигезендә республикада кабул ителгән махсус карар шушы максатны күз алдында тота да. Мәгълүм карар бала караучы, шуның белән бергә эшне дә алып баручы хатын-кызларга кирәкле шартлар тудыру өчен чаралар планы раслады. Анда хатын-кызга льгота һәм гарантия дә, әниләрне социаль яклау да, балаларын санаторийда дәвалауны оештыру да, алар өчен вакансия ярминкәләре уздыру да, яңа һөнәргә өйрәтү дә каралган. Ел саен безнең министрлык укытуның яңа программасын раслый. Исемлеккә Татарстан буенча гомумроссия вакансия банкыннан алынган һөнәрләр кертелә. Еракта килеп йөрүчеләргә юл чыгымы һәм яшәү өчен акча түләнә. Яшь әниләр күбрәк дизайн, бухгалтерия, компьютер, чәчтараш, менеджерлык эшләре белән кызыксына. Эшкә чыккач та аларның күбесе бездә үзләштергән һөнәрне сайлый. Кирәк икән, индивидуаль график буенча да укытабыз. Бөтенесе хатын-кызның үз теләгеннән тора. Былтыр бу максатларга республика бюджетыннан 8,9 миллион акча бүлеп бирелде. Шул акчага 815 хатын-кыз белем алды.

«Уңайлы мохит» турында

– Мәгълүм ки, Татарстан Республикасында 2011 елдан бирле «Уңайлы мохит» программасы эшли. Аны гамәлгә ашыруга 2011–2014 елларда 2 миллиардтан артык акча тотылган. Бу юнәлештә даими рәвештә зур һәм җитди эш алып барыла. Элек физик мөмкинлеге чикле кешеләр өйләреннән чыгып китә алмый, дүрт стена арасында бикләнеп утырырга мәҗбүр булса, бүген алар өчен транспорт та, метрополитен да үз мөмкинлекләрен ача: җәяүлеләр өчен юллар үзгәртеп корыла, социаль объектларга, подъездларга пандуслар, тотынгычлар куела. Инвалид балаларны гомумбелем мәктәпләрендә – яшьтәшләре арасында укытуны оештыру да, минемчә, зур казаныш ул.

Бүген инвалидлар өчен квота программалары эшли, махсус эш урыннары булдырыла. Бу юнәлештә эшне алга таба да дәвам иттерәчәкбез әле.



Юридик фәннәр кандидаты
Таңсылу САБИРОВА
җавап бирә.

?«Хөрмәтле редакция! 2013 елда мин «N» фирмасына 2 нче категорияле инженер булып эшкә урнаштым. Хезмәт килешүе буенча, декрет ялындагы кеше урынына вакытлыча алынган идем. Хәзер үзем дә бала көтәм. Директор, минем авырлы икәнемне белгәч, үз ризалыгым белән эштән китүемне таләп итә. Бу очракта мине эштән җибәрә алалармы?
Балага бирелә торган айлык пособие да түләнмәс микән инде?

Гөлназ Зыятдинова. Арча».

Хөрмәтле Гөлназ ханым! Хезмәт кодексының 261 нче маддәсе нигезендә йөкле хатыннарны бары тик ике очракта гына эштән җибәрү рөхсәт ителә: ул да булса, оешманың ябылу («ликвидация») яисә хосусый эшмәкәрнең үз эшчәнлеген туктату очрагы. Әмма нормадан чыгармалар да булырга мөмкин. Хатыгыздан аңлашылганча, вакытлы хезмәт килешүе нигезендә эшлисез һәм вакытлыча эштә булмаган хезмәткәрнең вазыйфаларын башкарасыз. Тик хатыгызда килешүнең тәмамлану вакытын күрсәтмәгәнсез. Әгәр хезмәт килешүе сез бала тапканчы ук тәмамлана икән, бу очракта шул ук 261 нче маддәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Дөрес, алда әйтеп узганча, йөкле хатынны эштән азат итә алмыйлар, эш бирүче сез бала тапканга кадәр хезмәт килешүен озайтырга мәҗбүр, әмма бер искәрмәне онытмавыгыз зарур: Сибгатуллина ханым эшкә чыккан көннән башлап, бала табу көненә кадәр эш бирүче сезгә, бәлки, түбәнрәк дәрәҗәле, әмма сезнең сәламәтлегегез торышына туры килгән башка берәр эш тәкъдим итәргә тиеш. Анда эшләргә ризалык бирәсез икән, бала тапкан көнгә кадәр хезмәт килешүегез озайтылачак. Ризалык бирмәгән очракта, эшкә алучы сезне Хезмәт кодексының 261 нче маддәсенең 3 нче абзацы нигезендә эштән азат итәргә хаклы.

Юрист буларак, эшкә алучы тәкъдим иткән теләсә кайсы эшкә ризалашырга киңәш итәр идем сезгә. Бу очракта сез йөклелек чорында хезмәт хакына, бала табу алдыннан бирелә торган ял вакытына (Хезмәт кодексының 255 нче маддәсе), йөклелек һәм бала өчен бирелә торган түләүләргә дәгъва итә алачаксыз. Әйтергә кирәк, 2006 елның 29 декабрендә кабул ителгән федераль закон 255-ФЗ нигезендә, әлеге түләүләрнең күләме уртача хезмәт хакының 100 процентын тәшкил итә.

Аңлашылса кирәк, сезнең очракта бала табу көне хезмәт килешүе тәмамлану вакыты белән тәңгәл килә, димәк, декрет ялы һәм декрет акчасы гамәлдәге закон буенча сезгә бирелмәячәк.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Мәскәү шәһәренең татар этно-мәдәни компонентлы 1186 нчы мәктәбендә Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге ачылды. Күренекле татар мәгърифәтчесе, фикер иясе, этнограф-галим, тел белгече, язучы, педагог Каюм Насыйри исемендәге бу институт КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында төзелде. Татар телен таныту, аңа өйрәтү белән шөгыльләнәчәк үзәкләрне институт татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә ачарга җыена. Мәскәүдәгесе — беренчесе. Мәктәптә үзәк өчен аерым кабинет бирелгән. Институт аны җиһазлар, дәреслекләр, сүзлекләр белән тәэмин иткән. Үзәктә татар телен өйрәнү буенча бушлай курслар оештырылачак. Казаннан килгән педагоглар татар әдәбияты буенча конферецияләр үткәрәчәк.

■ 2015 ел — Россиядә әдәбият, Татарстанда парклар һәм скверлар елы дип игълан ителде. Бу уңайдан, Казанда якын арада Аксенов паркы һәм Шаляпин йорты ачылачак. Ел ахырына кадәр Казан зоопаркы һәм «Крылья Советов» паркында төзекләндерү эшләре үткәреләчәк. Казансу яр буе, «Казан-Арена» тирә-юне халыкның яраткан ял урынына әйләнәчәк. Гомумән, парк һәм скверларны яңарту өчен миллиард сум каралган.

■ «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе итеп Роскомнадзорның Татарстан Идарәсе башлыгы Айрат Ринат улы Зарипов билгеләнде. 2006—2010 елларда ул Татарстан Президентының матбугат үзәге башлыгы булган, аңа кадәр Казан шәһәре хакимиятендә матбугат белән эшләү бүлеген җитәкләгән.

МӘДӘНИЯТ

■ Мәскәүдә, Россия Дәүләт академия Кече театрында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры гастрольләре узды. «Зәңгәр шәл» белән ачылып киткән тантанага Россия Дәүләт Думасы, Мәскәү мэриясе, Россия Кече театры вәкилләре килгән иде. Башкала тамашачысы «Гөргөри кияүләре», «Авыл эте Акбай», «Мәхәббәт FM» спектакльләрен яратып карады.

■ К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында «Кара Пулат» операсының премьерасы булып узды. Либретто авторы – Ренат Харис, музыкасын Эльмир Низамов иҗат иткән, әсәрне сәхнәгә Георгий Ковтун куйган. Шәһри Болгардагы Кара Пулат һәм аның тирәсендәге хан кызына бәйле риваятьләр нигезендә язылган бу яңа опера киләчәктә Казанда музыкаль театр ачу өчен нигез булыр дип фаразлана.



КОТЛЫЙБЫЗ



Татарстан Милли китапханәсенең яңа җитәкчесе итеп Сөембикә Җиһаншина билгеләнде. Моңарчы ул әлеге китапханәнең директор урынбасары булган, китапханәнең чит телләр бүлеген җитәкләгән, АКШта магистратурада укыган, Нью-Йорк китапханәсендә тәҗрибә туплап кайткан.

СӘЛАМӘТЛЕК

■ Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш кысаларында «Яраткан шәһәребезне кардан чистартыйк» акциясе уздырды. Үзе дә кулына көрәк тотып, урамда кар көрәп йөргән министр Гадел Вафин: «Кешеләрнең күбрәк хәрәкәтләнүе, йөрәкнең яхшырак эшләве мөһим безнең өчен», – дип белдерде.

■ Гыйнвардан апрельгә кадәр Бөек Ватан сугышы ветераннарына, блокада, фашизм тоткынлыгын узганнарга, тыл ветераннарына, ире сугышта һәлак булганнарга медицина тикшерүе планлаштырылды.

СПОРТ

Кукмара районы Сәрдекбаш авылы кызы — 16 яшьлек Фәнүзә Кадыйрова яшьләрнең хоккей буенча Дөнья чемпионатында Американы таң калдырды: өченче периодта исәпне тигезләп (3:3), сиренага 3 (!) секунд кала, җиңү алкасын кертте! Кызлар Россия җыелма командасы беренче тапкыр Дөнья чемпионаты пьедесталына күтәрелде.







Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТЫЛМАЧ

Берничә тел белгән һәркем тәрҗемәче була аламы? Юк, һәркем җырлый алмаган кебек, теләсә кем тәрҗемәче дә була алмый. Хәтта телне яхшы белгән очракта да.

Тәрҗемәче – кешелек җәмгыяте белән бергә туган һөнәр. Аллаһы Тәгалә, артык тәкәбберләнеп киткән колларын җәзаларга теләгәч, халыкларны төрле-төрле төркемнәргә бүлә дә, дөнья күп теллегә әйләнә. Әмма шунда ук алар бер-берсен аңлый, аралаша алсын дип, коткаручылар – тылмачлар да җибәрә ул.

«Тылмачның акылы теленнән озын булсын», – диләр. Нишләтәсең, анык тәрҗемә итмәү аркасында патшалар арасында низаг чыккач, тылмачның башын кисү кебек хәлләр дә булган кайчандыр. Хрущевның, ә аннан соң Брежневның шәхси тәрҗемәчесе Виктор Суходрев: «Башка вакыт беркайчан, берничек тә аралаша алмаган кешеләрне гәпләштерү минем үземә дә могҗиза кебек тоела иде», – ди. Хрущевның: «Мы вас похороним», – дигән атаклы җөмләсен тәрҗемә иткән кеше ул. 1956 елның 18 ноябрендә Мәскәүдә, чит ил илчеләрен кабул итү вакытында әйтә Хрущев бу сүзләрне. Чит ил матбугаты, шушы җөмләне генә аерып алып, Көнбатыш халкы күңеленә чын-чынлап шом сала... «Телисезме, юкмы, әмма тарих безнең яклы. Без әле сезне җирләячәкбез». Тулысынча бу җөмлә шулай яңгырый. Социализм (ә аннан коммунизм) отышлырак, шуңа күрә капитализмга караганда озынрак гомерле булачак дигән фикерне күз алдында тоткан була Илбашы.

Читкәрәк киттек.

Тылмач һөнәренең үзенчәлекләре турында тәрҗемәче Ләйлә ГАФФАРОВА сөйли.

ТЫЛМАЧ СҮЗЕН КҮРГӘЧ, «МИНЕМ МЕНӘ БЕРКАЙЧАН БЕРНӘРСӘ ТӘРҖЕМӘ ИТКӘНЕМ ЮК», – ДИЯРГӘ АШЫКМАГЫЗ ӘЛЕ. Ә ЧИТ ИЛДӘ ЭШЛӘНГӘН ЯҢА ТУЗАН СУЫРТКЫЧНЫҢ ИНСТРУКЦИЯСЕН, ТЕЛЕВИЗОРДАН ФИЛЬМНЫҢ ИСЕМЕН ТӘРҖЕМӘ ИТӘРГӘ ТЫРЫШЫП КАРАГАНЫГЫЗ?

Әлбәттә, булгандыр. Чит илдәге партнерлар белән килешү төзергә, эшлекле очрашу үткәрергә теләүчеләр турында әйтмим дә. Монда инде профессиональ тәрҗемәчедән башка бер адым да атлый алмыйсың.

Тәрҗемәче булып туалар

Тәрҗемәче булырга мин беркайда да махсус укымадым. (Элек мондый белгечләрне Мәскәүдә, М. Горький исемендәге әдәбият институтында әзерләгәннәр. КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме буенча махсус төркем бар.) Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укыган җирдән, III курстан соң, Төркиягә укырга китеп барырга туры килде. Әмма шунысы кызык, мин анда... инглиз телен һәм әдәбиятын өйрәндем. Әнкара университетында башта бакалавриатны, аннары магистратураны тәмамладым. Дипломыма «сәнгать магистры» дип язылган. Төркиядә торып укыгач, төрекчәне барыбер өйрәнәчәкмен дип уйладым, шуңа күрә инглиз телен сайладым. Төркиядә яшәвемнең файдасы тагын шул булды, мин телне генә түгел, менталитетны да өйрәндем: төрекләр белән сөйләшкәндә, фикерләренең нинди юнәлештә барганын тоям. Ә әйбәт тылмач булу өчен син тәрҗемә иткән тел мохитендә яшәгән илнең менталитетын белү бик кирәк.

Мин Төркиягә туксанынчы еллар башында киттем һәм 2001 елны гына кире әйләнеп кайттым. Ә аңа кадәр, 1998 елда, Әнкара университетында бакалавриат тәмамлап диплом алгач, нәкъ ике көннән Казан университетында кабат диплом якладым. Журналистика факультетының ул чактагы деканы Флорид Әгъзамовка рәхмәт: диплом эшемне шулкадәр кыска вакыт арасында карап чыгарга, бәяләргә вакыт тапты. Әйе, бер елда ике диплом яклау җиңел булмады, әмма кайвакыт шулай «кирәк» дип эшлисең дә, соңыннан артыңа борылып карагач кына, нинди юл узганыңны күреп, үзең дә шаккатасың...

«Казанские ведомости» газетасына эшкә урнаштым. Мин бу басмада Казанда укыган вакытта ук үз кеше идем. Әмма матбугат бу еллар эчендә шактый үзгәрешләр кичерергә өлгергән булып чыкты. «Журналистика минем өчен түгел икән инде», – дигән фикергә килер өчен берничә ай җитте... Кабат эш эзләргә керештем. Төрекләрнең зур бер төзелеш фирмасына тәрҗемәче кирәк булып чыкты. Нигә сәләтемне сынап карамаска дип уйладым. Фирма заводлар төзи иде: алар белән мин башта Мәскәүгә киттем, аннан Санкт-Петербургка. Гади тәрҗемәчедән техник директор дәрәҗәсенә күтәрелдем. Санкт-Петербургта эшләгәндә шундый кызык хәл дә булды: бер атна эчендә миннән ике подрядчы: «Ә сез кайсы югары уку йортын тәмамладыгыз?» – дип сорады. Канализация үткәрүчеләр белән дә, ут кертүчеләр белән дә, күрәсең, бер телдә сөйләшкәнмен. Чыннан да, үземә тәрҗемә итәргә туры килгән проект белән бәйле проблема турында сүз чыкса, мин аны шунда ук аңлый идем.

Беренче коймак «төерле»ме?

Заводларны төзү эшләре тәгәлләнеп, Казанга кайткан гына көннәрем иде. Көтмәгәндә Президент Аппаратыннан шалтыраттылар: Илбашы төрекләр белән эшлекле сөйләшү үткәрергә җыена икән. Тәрҗемәче эзлиләр. Төркиянең Татарстандагы консуллыгыннан: «Бездә андый белгеч юк, әмма бу кызга мөрәҗәгать итеп карый аласыз», – дип телефонымны биргәннәр. Аларга синхрон тәрҗемәче кирәк иде ул чакта. Төрек телен белүче, төрекчә сөйләшүчеләр Казанда шактый, билгеле. Әмма нәкъ менә миңа тукталулары... Анысы язмыштыр. Аннары тел белү белән тәрҗемә итү берберсеннән бик нык аерыла бит. Бу очракта русчаны камил белүем дә өстенлегем булып торгандыр.

> *Яхшы тәрҗемәче һәр очрактан чыгу юлын таба белергә тиеш.*

(Алгарак китеп булса да әйтим, туган телемдә дә сөйләшүем, татарчаны яхшы аңлавым төрекчәгә тәрҗемә иткәндә шактый ярдәм итә. Беренчедән, төрек телен өйрәнгәндә, әле күп сүзләрне белмичә дә, аларда җөмләнең ничек төзелгәнен – фигыльнең татар телендәге кебек иң ахырда торырга тиешлеген шунда ук төшендем. Икенчедән, Рөстәм Нургалиевич әңгәмә вакытында татарчага да күчкәли.)

Төрек фирмасы вәкилләре белән очрашу иде ул. Барып утырдым. Курыкмадым, каушамадым дип әйтсәм, әлбәттә, дөрес булмас. Әмма әңгәмә башланып, ун минутлар узгач, барысын да онытып, эшкә чумдым – бер сәгатьнең ничек узганын сизмәдем дә...



Тәрҗемәче булу өчен талант, аерым сәләт кирәк дияргәме, анысын белмим. Телне – әдәби телне яхшы белүдән тыш, яхшы тәрҗемәче тиз уйларга да тиеш. Кайсы вакыт ниндидер сүзне белмисең, техник сүз була ул, әмма нәрсә хакында сөйләшкәннәрен аңлагач, аның синонимын барыбер уйлап таба аласың. Тиз уйлый белү тәрҗемәче өчен зарур сыйфат!

Язылган һәм язылмаган кагыйдәләр

Төрек эшкуарлары, фирмалар белән эшлекле очрашуларны тәрҗемә иткәндә гадәти этикет кагыйдәләре саклана. Ә рәсми очрашулар вакытында, әлбәттә, протокол кагыйдәләре өстәлә. Аларны миңа махсус өйрәтүче булмады – анысына янымдагы кешеләрне күзәтә-күзәтә төшендем. Анда иң мөһиме – чәчрәп чыкмау. Беркайчан да! Син шәүлә, күләгә кебек булырга тиешсең. Хәтта тавышың да.

Ике фирма, ике компания вәкиле очрашканда, нәтиҗә килешү белән тәгәлләнсә, әлбәттә, күңелдә сөенеч туа – моңа минем дә катышым бар!

Рәсми делегацияләр очрашуын тәрҗемә итәргә чакырганда миңа, әлбәттә, алдан: «Өстеңдә протокол киеме булырга тиеш», – дип әйтелә. Офис стилен сакларга дигән сүз бу. Әмма минем болай да беркайчан кыска итәк кигәнем юк иде, шуңа күрә киенү рәвешем әллә ни үзгәрмәде дисәм дә ярый. Дөрес, «casual» стиле миңа күбрәк ошый.

МӘЗӘК

Диңгез юлбасарлары талап алган хәзинәләрен Гвинеяга илтеп күмәләр. Бу хакта полициягә дә билгеле була. Шушы җинаятьтә катнашкан пиратларның берсен кулга алгач, аның белән аңлашу өчен алар тәрҗемәче чакырталар. «Сора, хәзинәне кая күмгәннәр?» – диләр. Юлбасар: «Белмим», – дип җавап бирә. Тылмач аның сүзләрен полицейскийларга тәрҗемә итә. «Әйт үзенә, барыбер җавап бирергә туры киләчәк, югыйсә без аны җәзалыйбыз, төрмәгә утыртабыз», – диләр. Тәрҗемәче сүзен сүзгә җиткерә. Сайлау мөмкинлеге калмаган пират: «Менә шул кыяда, шул агач төбендә, миңа гына тимәсеннәр», – ди. Тәрҗемәче җавап көтеп торган полицейскийларга борыла да, күзен дә йоммыйча: «Юк, ул әйтергә теләми!» – ди.

Әле студент чакта ук Сталинның тәрҗемәчесе турында бер китап укыган идем. 1945 елны аңа Потсдам конференциясендә катнашырга, Сталин, Трумэн һәм Черчилльнең очрашуында тәрҗемәче вазыйфасын башкарырга туры килә. «Мин аңарчы бер тәүлек ашамаган-эчмәгән идем, – дип яза ул. – Табын артына утыргач, ашыгып нәрсәдер каптым. Һәм шул вакыт Сталинга сорау бирделәр... Авызга капкан ризыгымны ашыгып чәйнәп бетерергә, йотып җибәрергә тырышам, үзем шул ук вакытта тәрҗемә итәм... Сталин миңа борылды да: «Син монда нәрсәгә килдең? Ашаргамы, әллә тәрҗемә итәргәме?» – диде». Ул кыйсса күңелемә бик сеңеп калган. Шуңа күрә, теге тәрҗемәче хәленә төшмәс өчен, очрашу вакытында мин беркайчан ашамаска тырышам. Чәй йотып куйсам гына. (Рәсми визитлар вакытында программа бик тыгыз төзелә, һәр минут исәптә – без анда барыбыз да ашау-эчү турында онытабыз. Татарстанның рәсми визитлары бик югары дәрәҗәдә оештырыла. Үз эшләрен белгән чын профессионаллар шөгыльләнә моның белән. Президентыбызны, аэропорттан башлап, һәрвакыт, һәркайда зур хөрмәт белән каршы алалар. Минем өчен дә бу зур горурлык! Ә иң мөһиме: ике-өч айдан карыйсың, әлеге эшлекле сәфәрләрнең инде нәтиҗәсе күренә.)

Әйе, фирмалар, компанияләр белән очрашу алдыннан аларның нинди темага сөйләшәчәген алдан белеп торам. Әңгәмәдә кемнәр катнаша, фирма ни белән шөгыльләнә... Болардан хәбәрдар булмыйча барсаң, алар кулланган берәр сүзне (гадәттә, техник термин була инде ул) аңлый алмый торуың ихтимал.

Сүзнең мәгънәсен генә түгел, әңгәмәнең тонын бирә белү дә мөһим. Мине филолог булуым коткара, русча ул сүзнең синонимнарын эзли башлыйм. Табам!

Тәрҗемә нинди була?

Миңа иң ошаганы – синхрон тәрҗемә. Болай тәрҗемә иткән вакытта читтә, аерым бүлмәдә утырасың, сине беркем күрми, шуңа яратам (күпләр экстраверт дип уйласа да, чынлыкта, мин интроверт шул, оялчанмын). Чынлыкта, ул – иң авыры. Синхрон тәрҗемә ясаучылар, гадәттә, икәү эшли: унбиш минуттан соң берсе икенчесен алыштыра. Ә мин – үзем генә, эзләп тә кулалмаш тапканым юк әле. Шуңа да өч-дүрт сәгатькә сузылган фәнни конференцияләрдән кило ярымга ябыгып чыгам.

Конференциягә бер атна кала без, тәрҗемәчеләр, текстларның кулыбызда булуын таләп итә алабыз. Әмма мондый хәл бик сирәк була. Югыйсә халыкара конференциядә катнашкан галим өчен үзенең чыгышын аңлаулары, ишетүләре беренче урында торырга тиештер. Бер генә тәрҗемәче дә текстны болай да йөз процентка тәрҗемә итә алмый. Чыгышын алдан бирмичә, галим үз-үзенә зыян гына сала.

Кемдер чыгышын алдындагы кәгазьдән генә укый: туктап та тормый, тыныш билгеләренә дә игътибар итми... Миңа, тәрҗемәче буларак, үз сүзләре белән

сөйләүчеләр күбрәк ошый. Чөнки андый кеше әйтсә фикерен иң элек уенда төзи, шуңа мин аның логикасын аңлыйм – тәрҗемә итү дә җиңелрәк.

Иң кызыгы тагын шул: конференциядән чыккач: «Ә нәрсә турында сөйләштеләр?» – дип сорасалар, күп вакыт җавап бирә алмыйм. Башта аерым сүзләр, өзекләр генә кала. Мин чыгышларны үз күңелем, йөрәгем аша үткәзеп әйтмим, дөресме, дөрес түгелме фикерләре, мин аның белән килешәмме, юкмы, бу хакта уйламыйм – сүзне генә җиткерәм. Шуңа онытыладыр.

Эзлекле, бер-бер артлы тәрҗемә, чагыштырмача, иң җиңеледер – кеше җөмләсен әйтә яки фикерен тәмамлый, син әңгәмәдәшеңә аны җиткерәсең. Тәрҗемәнең тагын «пышылдап сөйләү» (русчасы «шушутаж») дигән төре бар: сөйләшүдә катнашучылар арасында телне бер яки ике кеше генә аңламаганда, яннарына утырып шыпырт кына тәрҗемә итеп барасың. Пышылдап әйтеп тору шактый авыр: тыңларга да кирәк, тәрҗемә дә итәргә. Тирә-юньдәгеләргә дә комачауламаска, шул ук вакытта әңгәмәдәшең төшенерлек итеп аңлатырга да.

Мин хәзер башкаларның уй-фикерләрен аңлатырга, ачыкларга, интерпретация ясарга шулкадәр өйрәндем, үзем инде беркайчан журналист булып эшли алмамдыр. Хәтта интернетта комментарийларны да җәелеп яза алмыйм. Әйтәсе килгәнем бик кыска килеп чыга. Һәр сүзне мәгънәсенә туры китереп кенә кулланырга өйрәнгәннән бу. Үзем сизмим, әмма сөйләшкәндә дә моңа игътибар итәм икән инде.

Сүзлекләр

Мин элек гел сүзлекләр җыя идем. Студент чакта безгә Төркия мәгариф министрлыгы ярты елга бер китаплар алырга акча (стипендия дип әйтсәң дә ярый) биреп килде. Инглизчә «Аңлатмалы сүзлек» сатып алуым зур бәйрәмгә әйләнгәнен хәтерлим... Әмма мин аларның берсеннән дә хәзер файдаланмыйм. Китап киштәмдә тезелешеп торалар. Хәзинә, әлбәттә. Инглизләр кешенең башындагы «сүзлек»не – ягъни сүз запасын «vocabulary», диләр. Аның бай булуы тәрҗемәче өчен бик мөһим. Без өйдә кечкенәдән китап укып үстек – сүз сандыгы буш түгел. Интернетта «ABBY Lingvo» дигән сүзлек бар – ул минем иң беренче ярдәмчем хәзер. Аның төрекчәсе бик үк бай түгел, әмма бу сүзлекне үзең тулыландыру мөмкинлеге дә бар. Ә мин төзелештә эшләгәндә үк үз сүзлегемне төзи башлаган идем инде. Ул – иң зур «байлыгым».

Тәрҗемәче күп белә

Юк, төрекчәмне камилләштерү өчен махсус нидер эшләмим. «Казан профессиональ тәрҗемә үзәге» белән килешүем бар, мин көн саен диярлек русчадан төрекчәгә нидер тәрҗемә итәм: килешүләр, сызымнар, техник текстлар, проектлар... (Төркия белән элемтәләребез күп яклы бит хәзер безнең. Алабугада гына да зур биш төрек предприятиесе эшли. Арада Европада иң зурлардан саналганнары бар. Тиздән төрекләр анда пыяла заводы та ачачак.)

Техник текстларны тәрҗемә итү, ни гаҗәп, миңа җиңелрәк. Втулка яки газ турбиналары компрессорының нәрсә икәнен белмичә дә эшли алам, чөнки текстлар бик төгәл язылган. Артык сүз юк: нәрсә, кайчан, ничек. Шуның белән бетте. Ә юристлар, мәсәлән, бер җөмләгә әллә никадәр мәгънә, мәгълүмат салырга тырыша. Җөмләне көчкә ерып

> *Тәрҗемәченең башкалардан бер өстенлеге бар – ул бик күпне белә.*

чыгасың, матур да яңгырый кебек, әмма төрекләр: «Без бернәрсә аңламыйбыз», – диләр. «Сез борчылмагыз, руслар да юридик текстларда бер укуда барысын да төшенми», – дим мин. Әдәби текстларны тәрҗемәләү дә җиңел түгел. Филолог кешегә киресенчә булырга тиеш кебек тә бит... Анда гел эзләнергә кирәк: нәрсә әйтергә теләгән автор, бу сүзне кулланыргамы, әллә башкасы күбрәк туры киләме? Рус теле бик бай бит ул. Төрекчәдә, мәсәлән, бер сүзнең бер синонимы бар, русчада – бишәү. Әмма бай булмаса да, төрек теле бик матур тел ул, логикага нигезләнгән.

Дусларым нидер турында сүз чыкканда, аптырап: «Бу сиңа кайдан таныш соң?» – диләр. Ә минем кайчандыр шушы өлкәгә, темага кагылышлы текст тәрҗемә иткәнем бар! Тирән беләм дия алмыйм мин аны, әмма беләм! Шуның янына, журналистка хас кызыксынуны да өстәсәң...

Гөлнур САФИУЛЛИНА язып алды.

РЕКЛАМА

ПРОФЕССИОНАЛЬНЫЕ ПЕРЕВОДЫ
С ИНОСТРАННЫХ И НА ИНОСТРАННЫЕ ЯЗЫКИ
(ЕВРОПЕЙСКИЕ И ВОСТОЧНЫЕ)



КАЗАНСКИЙ ЦЕНТР ПРОФЕССИОНАЛЬНЫХ ПЕРЕВОДОВ

- Перевод документации различной тематики.
- Перевод личных документов (паспорта, свидетельства о рождении, браке; дипломы, аттестаты и т д.).
- Сопровождение нотариального заверения, перевода.
- Перевод и заверение документов для Генерального Консульства Турецкой Республики в г. Казань.

Казань, ул. Калинина, 6. Тел. (843) 237-63-41; Моб. +7 9172 92 44 32.
kazanperevod@mail.ru, kazanperevod@gmail.com
Понедельник – пятница – с 9.00–18.00.



Фото: Газинур Хафизов

ЖИР СУЛЫШЫН ИШЕТӘМ!

Мәдинә КАШАПОВА, Фирая МОРАТОВА

АЛАРНЫҢ КАЙСЫ ОЧКЫН ТӨШСӘ, ДӨРЛӘП КАБЫНЫП КИТӘРДӘЙ УТ ШИКЕЛЛЕ, КАЙСЫ САЛМАК КЫНА АГА-АГА ЗУР ДИҢГЕЗЛӘРГӘ БАРЫП ТОТАШКАН ЕЛГА ШИКЕЛЛЕ. ҺӘМ АЛАР БАРЫСЫ ДА ЕЛНЫҢ «ИҢ ЯХШЫ АГРОНОМЫ».

Үсемлек табибы

Аңа нибары 32 генә яшь әле. Ул инде әнә елның «Иң яхшы агрономы» булып, грант-премия алырга да өлгергән. «Нинди казанышлар өчен?» – дип кызыксынабыз. Ә ул елмая гына. Ничек әйтә-аңлата алсын соң ул үзенең акыл да, көч тә җитә алмастай тоелган тынгысыз эшенең үзенчәлеген?! Иртә таңнан көн дә, төн дә «кояш» балкып торган, ел әйләнә җәй патшалык иткән шушы гаҗәеп дөньясында ич ул...

Дистәләгән гектарга сузылып киткән «Майский» теплица комбинатының 3 нче цехында йөрибез. Гәрчә бирегә беренче генә килүем булмаса да, барысы да яңа, күрелмәгәнчә тоела. Башлары күкләргә ашкандай утырган кыяр сабакларының тамырлары күренми дә. Алар уч төбенә сыярдай җыйнак кына савытларда, бертуктаусыз туендырып торган тамызгычлардан тукланып, рәхәтләнеп үсәләр дә үсәләр.

Алар инде күптән агулы химикатлар белән эшләми. Теплицада экологик чиста продукция җитештерергә мөмкинлек бирүче биометод кулланыла.

– Димәк, кыярларга суны кызганмыйсыз?

– Су гына түгел, суга тукландыргыч матдәләр дә кушабыз, – ди Энҗе Хәбибрахманова.

Ул безнең белән сөйләшкән арада якында гына эшләп йөргән хатыннар янына йөгереп барып, киңәшен дә биреп ала. «Кая сезнең алъяпкычларыгыз?» – дип кисәтү ясарга да онытмый. Монда да, камилләшүгә йөз тоткан башка хуҗалыклардагы кебек, теплица эшчеләренең үз киеме, үз формасы.

Кыяр үстерүчеләр түтәл араларына куелган махсус җайланмаларның төймәләренә генә басалар да, сабакларны чистартып, арлы-бирле йөри башлыйлар. Шунсыз булмый, буй җитми.

Гомумән, цехта бөтен эш автоматка көйләнгән. Шланглар белән су сиптереп йөргән, баскычка атланып, кыяр сабаклары әйләндергән заманалар инде күптән артта калган. Исеме-даны республика чикләрен үтеп, илгә таралган бу коллектив инде хәзер үзе чит илләрдәге яшелчә үстерүчеләргә тәҗрибә бирерлек.

Йөри торгач, үсемлекләргә беркетелгән сары кәгазь кисәкчегенә игътибар итәбез. «Зарарлы бөҗәкләргә каршы көрәлә торган чараларның берсе». Агроном кыз шулай дип аңлата. Үлән бете, талпан ише зарарлы бөҗәкләрдән арындыру өчен инде бу дип, үзебезчә нәтиҗә дә ясаган булабыз. Бер очтан зарарлы бөҗәкләргә каршы файдалы бөҗәкләр дә барлыгын белеп калабыз.

– Комбинатның өмете, киләчәге булырга тиешле белгеч бирегә ничек килеп эләкте икән?

Энҗе Яшел Үзән районының Осиново бистәсендә урта мәктәпне тәмамлаган. Кем буласын, нинди һөнәр сайлаячагын әле укыган чагында ук белгән. Агроном була ул, кырлар-басулар – аның дөньясы! Казан Авыл хуҗалыгы академиясенә агрономлыкка укырга кергәч, «Майский» совхозына практикага кайта. Кайта һәм инде беркая китми. «Коллективны, җитәкчеләрен ошаттым, эшемне яраттым», – дияр ул соңыннан. Ул безгә дә шул ук сүзләрне кабатлый.

– Килгәч тә, башта 10 нчы цехта үсемлекләрне сугару һәм төрле чирләрдән саклау эшләре белән шөгыльләндем, – дип искә ала Энҗе Хәбибрахманова. – Аннары 3 нче цехка агроном итеп куйдылар.

Үзенә зур җаваплылык йөкләнгәнен ул яхшы аңлый. Ул җибәргән кечкенә генә хата да, игътибарсызлык та күз карасыдай кадерләп-карап, җаныңны бирердәй булып үстергән үсемлекләрне харап итәргә мөмкин. «Аллам сакласын!» – ди кыз бу хакта сүз чыккач.

Безнең республиканы гына түгел, күрше өлкәләрне дә үзенең экологик чиста продукциясе – кыяр-помидорлары, баклажаннары, җиләкләре, яшел салатлары, суган, укроплары һәм башкасы белән тәэмин итеп торган хуҗалыкның алга таба да абруен югалтмаячагына иманыбыз камил. Энҗе шикелле: «Иң беренче эш, аннары тагын эш...» – дип һөнәренә мөкиббән китеп торучы белгечләре булган хуҗалыкның киләчәге, җырдагыча әйтсәк, «билгеле бит инде болай да»...

> *Ул җибәргән кечкенә генә хата да җаныңны бирердәй булып үстергән үсемлекләрне харап итәргә мөмкин.*

«Йөрәге ат башы кадәрле...»

Аның турында авылдашлары шулай ди. Әйткәннәре хактыр. Нинди генә эшкә алынса да, булдыра ул.

Яшел Үзән районы Казаннан кул сузымында гына булса да, «ВЗП – Заволжья» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең филиалы урнашкан «Сельхозтехника» бинасын эзләп бара торгач, шактый юл үтелде. Әнә ул үзе дә... Кочагын җәеп безгә каршы килә. «Үзе кечкенә генә, ә йөрәге ат башы кадәрле», – дигәннәр иде аның хакында. Соңыннан бу сүзләрне кайта-кайта исемә төшерермен әле.

Хезмәттәшләре өчен болай да иң шәп агроном булган Роза Габтулла кызы Саттарова грант-премиягә лаек булуын бик гади аңлата: «Эшләдем дә эшләдем, – ди ул. – Әмма болай ук булыр дип күз алдыма да китереп карамадым». Ул сәхнәгә чыгуын, министр кулыннан диплом алуын тагын бер кат зур дулкынлану белән исенә төшерә. «Кырларда йөрергә машинам искерде. Яңа машина алам. И-их, аннары элдереп кенә... Җәй көне килегез, мин сезне үзем алып чыгам, иркен анда», – ди ул, хыялга бирелеп.

«Мин – авыл баласы. Гомеремнең иң матур мизгелләре туган авылым белән бәйле», – дип сөйли башлый агроном. Аның өчен «матур мизгел» дигәне дә, бәлкем, меңләгән халкы булган авылның бер очыннан икенче очына хат, газета-журналлар ташучы әнисенә ярдәм итү булгандыр?! Ә бәлкем, колхоз елларында иптәш кызлары белән җыйнаулашып гектары-гектары белән бәрәңге-суган



утарга йөрүләр күңелендә кабатланмас хатирә булып калгандыр?! Ә бәлкем, авылыннан сигез чакрымда урнашкан Норлат мәктәбенә йөреп укыган чаклар сагындырадыр аны?! «Бер генә көнгә шәһәргә барсам да, шундук сагына башлыйм, очып кайтырдай булам», – ди Роза ханым.

Мин һавадагы кош сыман, ирек яратам!

Янәшәңдә сине аңлаучы әйбәт кешеләр, сиңа ышанып караучы җитәкчеләр булганда рәхәт шул ул. Эшләве дә рәхәт. Үзеңне кирәк итеп сизү дә рәхәт. Аңа эшендә гел шулай уң килеп тора. Урта мәктәпне тәмамлауга кызга беренче эшлекле тәкъдим ясала. Аны «Искра» колхозының комсомол оешмасы секретаре итеп куялар. Бер елдан «булган кыз»га кассир эшен тәкъдим итәләр. «Колхоз рәисе шулай дигәч, каушап калдым. «Куркам, – дим, – акча эше бит». «Кырга чыгасың киләмени?» – ди җитәкчем. Инде бик еракта калган шул елларны искә төшергәндә, ул канәгать елмаеп куя.

Аның хезмәт юлын бер генә җөмлә белән: «Кассир, бухгалтер, икътисадчы, агроном-технолог», – дип әйтергә дә булыр иде. Шул арада ул Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын да читтән торып тәмамларга өлгерә.

– Мин бүген – яраткан эшемдә, – ди агроном. Нинди була соң ул «яраткан эш»?! Язын, җәен, көзен басу-кырлардан кайтып кермәүме?! Җирнең җитмешкә төрләнгән йөрәк тибешен ишетеп яшәүме?! Җир белән бер сулышта яшәү җиңел түгел ул.

– Башта кыш буе орлыкларны «кәгазьдә» чәчәбез. Тегеләй дә, болай да итеп карыйбыз. Ничек чәчсәң, уңышны күбрәк алырга була? Үзәккә үткән бөҗәкләрдән, төрле авырулардан ни рәвешле котылырга мөмкин? Кайда ни чәчсәң, уңыш мулрак чыгар? Сорау арты сорау, кыскасы... Аннары яз җитә, – дип дәвам итә сүзен Роза ханым. – Карны сулышыбыз белән эретердәй булып, җир уянганны көтәбез. Кырга чыгып, көздән чәчеп калдырган бодайның тишелешен күзәтәбез. Басу-кырларны йөреп чykканчы, бер үлеп, бер тереләсең. Борчыласың инде: үсентеләр әйбәт сакланганмы, чирләмиләрме, барысы да тәртиптәме...

– Шуннан тынгысыз көннәр башлана. «Химикатлар белән эшлибез», дигән коры сүзләр артында бетмәс-төкәнмәс мәшәкать ятуын агроном үзе генә белә. Җирне сөреп, тырмалап, чәчүгә әзерләгәнче генә дә күпме чара күрелә. Кадерләсәң генә ул җир. Туфракка вакытында (нәкъ менә вакытында – бер көнгә алдан да, бер көнгә соң да түгел) гербицидлар кертү дисеңме, чүп-үләннәргә каршы көрәшү дисеңме... Бер уйласаң, никадәр җаваплылык агроном җилкәсендә! «Егетләргә химикат биреп җибәрәм дә, шундук артларыннан чыгып йөгерәм. Ничек салырга кирәклеген үзем күрсәтмичә тынычланмыйм», – ди Роза Саттарова.

Үзең эшләп күрсәтсәң генә, үзең юл ярсаң гына... Белгеч өчен эшнең «синеке», «минеке»се юк аның. Алар бодай, арпа, солы, көнбагыш, кукуруза ише иген культуралары игәләр. Өч зур комплекстагы унбиш меңнән күбрәк мөгезле эре терлекне тоту – алар җилкәсендә.

37 ел авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт итеп, эшләү дәверендә алты рәисне күргән ханымның: «Бернинди эштән дә курыкмыйм», диюенә гаҗәпләнмим. Шундый гайрәтле булмаса, ул бүген безнең каршыбызда җиңүче исемен күтәреп утырмас та иде. Шундый түзем-сабыр булмаса, артыннан бер-бер артлы куа килгән тормыш михнәтләрен «язмышым» дип, тыныч кабул итә алмас иде.

Ул 22 яшендә яраткан кешесенә кияүгә чыгып, 42 яшендә тол кала. «Күп итеп терлек асрадык. Савым сыерларыбыз гына да өчәү иде. Терлек, сөт сатып шактый акча тупладык. Ссуда алып, кирпечтән зур йорт салып чыктык. Бергәләшеп тапканның рәхәтен күрергә генә насыйп булмады», – дигәндә генә аның күзләрендә сагыну, сагыш чаткылары чагылып китә.

Ире вафатыннан соң ул бөтен көчен эти-әнисен тәрбияләүгә бирә. Ул вакытка алар инде икесе дә инсульт кичергән. Өйдә әле тагын I группа инвалид энесе дә бар. Роза төп нигезгә – алар янына әйләнеп кайта. Бер ел дигәндә, башта этисе, аннары әнисе бакыйлыкка күчә. Хәзер алар акылга зәгыйфь энесе белән икәү генә яшәп яталар. «Мәчеткә йөри, – ди ул энесен яратып та, үзенчә кызганып та. – Мәчетне калдырмый бер дә, күрәсең, үзенә шунда тынычлык таба. Барасы сәгатендә искәртә торган идем. Ә беркөнне оныткан-мын. Кичен эштән кайтсам, пальтосын киеп, ишек төбендә утыра».

Авылның үзендә генә дә ике мәчет. Халкы динле, иманлы, бер-берсенә ярдәмчел. Тикмәгә генә Муллаиле дип аталмый бит авыллары!

Китәргә җыенабыз. Роза ханым безне озата чыга. «Ничек булыр инде?» – ди, ул кар кочагында киңәнгән кырларга карап. Әйе, ничек булыр? Биш ел рәттән килгән корылык тагын кабатланмасмы? Уңдырышлы ел булырмы ул алар өчен? Әле кыш уртасы гына. Ә агроном инде күптән яз мәшәкатьләрендә...

Ул кырларга гашыйк

Зөбәрҗәт ханымның үз хезмәте үзенчәлекләре турында рухланып сөйләвен сокланып тыңладым, аңа ияреп үзем дә басуларны иңләгәндәй булдым. «Җир кешесе өчен һәр чорның үз матурлыгы бар», – дип әйтүче агроном-консультант Зөбәрҗәт ханым урынына үзебезне куеп карыйк әле.

Язгы кыр. Яңа гына кайнар табадан төшкән ипекәйдәй күпереп торган кап-кара җир. Әкрен генә пар күтәрелә. Сабыйдай иркәләп, кадерләп әзерләнелгән орлык өлгергән җир куенына төшә... Күктәге сабан тургае ашкынуына, шул орлыкның шытып чыгуын, аннары күкрәп үскән иген диңгезенең дулкыннар булып йөгерешкән мизгелен көтү рәхәтлеге ялгана. Инде менә басуга комбайннар чыккан, машина гөрелтесе, уңыш тузанының җанга якын исе һәм сары алтындай ашлык ташкыны... Эше җир белән бәйле кешеләрнең күбесе әнә шул мизгелләрне көтү белән яшидер...

«Механизатор, игенче – басуда, ә болар конторада гына утыралар, дисездер. Безнең дә йөрәк яна, иген амбарларга керми торып, җан тынмый», – ди Зөбәрҗәт. Артык тыйнак бу ханымның күңеленә саксыз кагылмаска тырышып, тел очымда йөргән сорауны бирергә ашыгам: «Агроном хатын-кыз сәеррәк инде, бу хезмәт ир-атка килешерәк төшә».



Зөбәрҗәт елмая да, үзен җиргә бәйләгән вакыйганы хәтерендә яңарта. Мамадыш ягындагы туган авылы Шәдче мәктәбендә укыган чагында ул аш-су остасы булырга хыялланa. Кулы аш-суга ятып торучы кызкай да, авылдагы һәрбер яшьтәше кебек үк, югары сыйныфта хезмәт дәресләрендә тракторчы булырга укый, бозау карарга һәм сыер саварга өйрәнә. Алары турында да тәмләп, яратып сөйләвен шаккатып тыңладым (сыер савучы буласым юк әле дип, сыер фермасына эз дә басмаган мәктәп елларым исемә төшеп, Зөбәрҗәт алдында оят булып китте)...

Әтисенең энесе – үз районнарында авыл-хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе булып эшләүче Фоат абыйсы Галәветдиновның киңәше аның хыялларын бөтенләй башка юнәлешкә борып җибәрә: «Син бит җирне яратасың. Кулың җиңел: нәрсә чәчсәң дә, үсеп китә. Агрономлыкка бар, үкенмәссең». Татарстанның атказанган агрономы Фоат абыйсының шул киңәшен тыңлап, мәктәптән соң, Зөбәрҗәт район үзәгендәге орлык тикшерү станциясенә лаборант булып урнаша, бер үк вакытта читтән торып Минзәлә техникумында да укый.

Язмышы Түбән Кама белән бәйләнгәч тә, яраткан эшеннән аерылмый. Басулардагы игеннәргә бөҗәкләр зарар салмасын өчен, үз вакытында тикшерү максатыннан, сөкә (сачок) күтәреп, райондагы колхоз-совхозларның басуларын да җәяүләп урап чыгалар. Ул елларда машиналар юк. Юл читендә кул күтәреп, автобуска утырып, көннәр буе йөриләр. Ире – шофер Гаяз үзе дә атна буе юлда булгач, хатынының өйдә юклыгы сизелми. Иң авыры, шимбә һәм якшәмбедә сабыйлары Гөлназ белән Алмазны болай да эшләп арыган әтиләренә калдырып чыгып китү була.

Хәзер инде ул авырлыкларның барысы да артта калган. Иртәнге алтыдан хезмәт көнен башлау һәм шимбә-якшәмбене эш урынында уздыру гадәте генә үзгәрмәгән. Район хуҗалыкларындагы уннан артык агроном һәм адым саен белгеч киңәшенә мохтаҗ илле дүрт фермер белән һәрчак элемтәдә торырга кирәк аңа. Райондагы «Бәхетле-Агро», «Союз-Агро» («Прикамский»), «Химокам-Агро» һәм «Нефтехим-агропром» җәмгыятьләренең агрономнары белән үсемлекләрнең, уҗымнарның һәр үсеш фазасы вакытында бергәләп кырга чыгып, үзара киңәш-табыш итеп эшлиләр. Басуларга нинди ашлама кертергә, гербицидны кайчан һәм күпме кулланырга кирәген дә, басуның кайсы урынына ниндирәк орлык чәчү, бөртеклеләр, күпьеллык үлән өчен кайсы басуны сайлау һәм башкалар турында уртага салып сөйләшәләр.

Җир эше турында шулкадәр яратып сөйләүне ишеткәнем юк иде әле.

Фермерларның күпчелеге, терлекләргә ашату өчен күпьеллык үлән үстерергә, шулай ук бодай һәм арпа чәчәргә җыена, ди. Җирне кысыр калдырмау өчен янып-көеп йөрүче фермерлар, хөкүмәттән субсидия килсен өчен, элиталы орлыкларга өстенлек бирергә тиешләр. Көне-төне кырдан кайтып кермәүче, өстәвенә, мал-туар арасында күпме вакыты үтүче авыл кешесе ул үзенчәлекләрне каян белеп бетерсен соң?! Җитмәсә, аларның берсе дә агрономлыкка укымаган. Зөбәрҗәт ханымга аларның һәрберсенә субсидия юллашырга да, кырларында үсә торган игеннәрне даими рәвештә карап-тикшереп торырга да туры килә.

Узган елның декабрь уртасында Татарстан авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәрен хөрмәтләү тантанасында Түбән Кама авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе агроном-консультанты Зөбәрҗәт Фазыл кызы Габдрахманованың 2014 елның «Иң яхшы агрономы» буларак җиңүче дипломына һәм 100 мең сумлык махсус грантка ия булганын ишеткәч, булдыклы якташыбыз өчен чиксез шатландык. Татарстандагы өч агроном-консультантның берсе безнең Зөбәрҗәт ләбаса!

«МИН БҮГЕН ЯШӘРГӘ ТИЕШ»



Ап-ак карга басып... юк, Алсу түгел, Айгөл килә. Үзе бертуктаусыз шалтыраган телефонын алып, тиз генә нәрсәләрнедер хәл итәргә дә өлгерә. «Телефон белән кочаклашып йоклаган чаклар да күп булды, хәзер дә тынып торганы юк», – дип елмая ул яныма килеп җиткәч. Аннары «ярдәмчесе»н сүндереп, сумкасына ук салып куя. Димәк, иркенләп сөйләшәчәкбез. Саубуллашканда гына ул телефонын кабат кабызачак, шалтыратуларга җавап бирәчәк, үзе дә кирәкле номерларны җыячак. Ә хәзергә без җылы кафеда утырабыз. Яшәү рәвешенә әйләнгән эш, беренче һәм соңгы мәхәббәт, җиде кат тир түгеп яуланган бәхет турында сөйләшәбез.
Мөхәррир Айгөлне мин күпләрнең яраткан телеканалына әйләнгән «Мәйдан»ның «йөрәге» сыманрак кабул итәм. Тапшыруларны эфирга әзерләгәндә ул һәммәсен үзенең күңеле, җаны аша үткәрәдер, мөгаен. Аннары иң кирәклеләрен генә сыгып чыгара! Ниләр бирсәң, халык дөньясын онытып караячак, ә нәрсә аның гайрәтен чигерәчәк – ул инде аны барометр кебек шундук тоя. Безнең халык җырсыз яши алмый – «Мәйдан» да тәүлек буе эшләп, җырлап тора! Татар эстрадасының иң популяр, тамашачы яратып кабул итә торган җырчылары көн буена «өеңә кереп» җырласын әле! Һава торышы, мультфильмнар, мәзәкләр, яшьләр өчен тапшырулар, концерт язмалары, җанлы әңгәмәләр, котлаулар... Телеканалның хит-парадларын һәм плей-битләрен тамашачылар үзләре төзи ди әнә Айгөл. Татар телевидениесе тарихында беренче күңел ачу каналы ул. Гаилә белән карыйлар, шәп кәеф, күңел күтәренкелеге өсти, тормышны ямьли. Тапшыруларын кабель, «спутник», мобиль челтәрләрдә рәхәтләнеп карый алалар. Татарстанда гына түгел, бөтен Россия буенча 42 шәһәрдә «Мәйдан» халыкны зәңгәр экраннар янына җыя. «Көн саен шулай: яңа телепродукт аның белән программаның директоры танышканнан соң эфирга чыга», – ди Айгөл. Һәм аның сөйләме контент, промоушн, рейтинг, фокус-группа, тагын әллә нинди сүзләргә чәчелә-сибелә башлый. Аннары кабат «җиргә төшеп», ир хатыны, әни кеше, хатын-кыз, кыскасы, гап-гади Айгөл булып кала да сорауларыма җавап бирүгә күчә.

Эшме, гаиләме дигән «юл чатында» калган чаклар булгандыр...

– (*Озак уйлаганнан соң.*) Мин эшсез яши алмыйм. Шөкер, андый сайлау алдында калганым булмады. Минем өчен эш белән гаилә тигез үлчәмдә. Матди байлык өчен түгел, күңел өчен эшлим мин.

Ә күңел тартмаган җирдә эшли алыр идеңме?

– Юк. Гомеремдә дә. Беренче ирем Фәнис үлеп, яшь бала белән тол калганнан соң, авылга кайтып сыер да саудым, идән юучы булып та эшләдем. Тик анысы тормыш таләп иткәнгә генә.

Институтның режиссерлык бүлеген читтән торып тәмамлаганнан соң, яшь тә 8 айлык Альфредны күтәреп, Арча мәдәният йортына эшкә барып кердем. Җырчы Рөстәм Закиров мине күргән саен: «Нишләп ятасың монда? Югаласың бит, Казанга кил», – дия иде. Кечкенә бала белән мин анда кемгә кирәк, монда, ичмасам, баланы күршегә калдырып торып була, дим. «Әйдә, «Казан» милли мәдәният үзәгенә методист кирәк, шунда кил әле, Ринат Закиров белән үзем сөйләшәм», – диде бервакыт Рөстәм. Шуннан Казанга килдек. Милли мәдәният үзәге тормыш дәресе дә бирде, бик зур таяныч та булды миңа. Бөтен нәрсәгә шунда өйрәндем. Ринат Зиннурович, тырышканымны күреп, башта мәдәният бүлеге мөдире итеп куйды, аннары Казан шәһәр филармониясенә директор итеп билгеләде. Аңа бик рәхмәтле мин.

Филармониядә эш күп иде. Төнге 2-3 тә дә шалтыраталар. Эшнең төгәл башкарылганына үзем ышанмыйча, тынычлана алмыйм, шуңа күрә бөтен нәрсәне үз өстемә ала идем. Тормышымның иң нәтиҗәле ун елы «Казан» милли мәдәният үзәгендә узды, шуның алты елы – Филармониядә.

– Эш дип сулаган кешенең рәхәтләнеп ял итәргә түгел, авырырга да вакыты юк инде анысы.

– Авыру дигәннән, бер елны таудан чаңгы шуганда егылып, кулым сынды – сөякләр чәрдәкләнеп беткән иде хәтта. Илизаров аппараты куеп, ярты елга «больничный» бирделәр, сыңар кулым белән машина йөртеп булса да эшләдем! (*Көлә.*) Операциядән соң 20 көн тирәсе генә өйдә яттым, анда да телефоным кулымнан төшмәде. Чыгып йөри башлаганда өстемә кием дә кия алмый идем. Кулга куелган аппарат кабарып чыгып тора, аңа бернәрсә дә тидерергә ярамый. Ирем Илдарның 56 нчы размерлы курткасын иңемә элеп йөрдем. Өч айдан соң аппаратны салдырдылар, тик кул беләктән бөгелгән килеш катып калган, турайтып булмый. Шул хәлдә концерт та алып бардым әле. Тураймый торган кулга папканы кыстырып, икенчесенә микрофонны тотып...

Әминәне тапкач, ел ярым декрет ялында утырдым. Ул вакытта да эшсезлектән тилмердем. Гел каядыр йөгереп, нindидер мәсьәләләр хәл итеп яшәмәгәч, мин буламмыни ул!

Ә шулай да яраткан эшеңнән киткәнсең...

– Улыма ана назы җитеп бетмәде, кызыма да шулай булмасын дип, тынычрак эшкә күчәргә ниятләдем. «Мәйдан» телеканалы ачылгач, Дамир Дәүләтшин белән Эдуард Үтәгәнов шунда эшкә чакырдылар. Үзе тыныч булмаган кеше өчен бер җирдә дә тыныч түгел икән лә! (*Көлә.*) Читтән генә карап тора алмыйм бит мин. Вакыйганың эчендә кайнамасам, үземне кирәксез итеп тоя башлыйм. Мин һәрвакыт иң кирәкле кеше булырга тиеш.

«Мәйдан»да, танылган җырчылар белән беррәттән, моңарчы исемнәре ишетелмәгән яшь җырчыларның җырлары да еш әйләндерелә. Редактор буларак, эфирга чыга торган җырларны нинди иләктән үткәрәсез?

– Чыннан да, безнең телеканалда азау ярган профессионалларны гына түгел, яшь башкаручыларны да, хәтта һәвәскәрләрне дә күрергә була, махсус сәхифәбез дә бар. Бәлки, кайбер җырлар камиллектән ерактыр да, тик без берәүне дә кире бормаска тырышабыз. Бөтенләй начар дигәннәр генә төшеп кала. Минем гел әйтә торган бер сүзем бар: яшьләр бозык юлда йөргәнче туган телендә җырлар яздыра, клиплар төшерә икән, моңа сөенергә генә кирәк.

Җәмгыятьтә дә, өйдә дә кирәкле булырга тырышам.

Синеңчә, уңышның сере нидә?

– Тырышлык, күңел биреп эшләү кирәк. Кайберәүләр югары үрләргә ирешүләрен уңышның елмаюы дип аңлата. Кул кушырып утырып кына үрләр яуланмавын яшьли аңладым мин. Шуңа күрә һәр тапкан тиенем, һәр уңышым өчен җиде кат тиремне чыгарырга туры килә. Уңыш миңа бер генә тапкыр елмайды: беренче курста ук төркемдәшләрем арасыннан үземне генә телевидениегә сайлап алдылар. Тик бу уңыш ничек җиңел килсә, шулай ук җиңел генә китеп тә барды – анда озак эшләү насыйп булмады.

Эш, гаилә, дуслар, хобби... Барысына да җитешү өчен вакытны ничек дөрес итеп бүләргә, Айгөл?

– «Болай да эшең күп, тагын спорт залына да йөрергә ничек өлгерәсең?» – дип сорыйлар миннән. Өлгерәм, чөнки анда теләп йөрим. Кирәк эшкә һәрчак вакыт табып була.

Хәзер мәхәббәткә күчмәсәк, ул үпкәләр кебек. Тәүге тапкыр гашыйк булган чагыңны хәтерлисеңме?

– Хәтерли-им. Гыйшык уты йөрәгемә алтынчы сыйныфта укыганда керде. Рафис исемле малай иде ул. Озак кына очрашып йөрдек, армиягә дә озатып калдым. Тик ул бала-чага яратуы булган, күрәмсең.

Хатын-кыз яраткан ире ышыгында итәк тотырып бала үстерү, гаилә учагын сүндерми яшәтү турында хыяллана, диләр...







– Без гаиләдә дүрт бала үстек. Әти-әнием төзегән гаиләгә карап, мин дә алар кебек тыныч оя кору турында хыялландым. Тик тормыш без теләгәнчә генә бармый бит ул. 19 яшемдә үк кияүгә чыктым. Фәнис белән кыш көне таныштык та, җәй ахырында кавышып та куйдык. Мәдәният институтының актерлык осталыгы бүлегендә Шамил абый Бариев белән Ренат абый Әюпов төркемендә укып йөргән чагым. Көтмәгәндә Шамил абый вафат булды. Бу вакыйга бик тетрәндерде, укырга дәртем калмады. Өченче курска укырга барып тормадым, Фәнис белән гаилә корып, Чаллыга күчеп киттек.

Тик, минемчә, тырышлык булмаса, уңышка салынып ятып кына бернәрсә дә барып чыкмый.



Улыбыз Альфред туды. Ә тагын бер елдан язмыш тез астыма китереп сукты: Фәнис кинәт кенә юкка чыкты, бераздан аның үле гәүдәсен таптылар. Күкрәгемә сабыемны кысып, берьялгызым калдым.

Бер көйгә генә аккан тормышыма көтмәгәндә... Илдар килеп керде! Аллаһка шөкер, бүген мин бик бәхетле. Илдар белән гаилә корып яши башлавыбызга сигезенче ел китте. Кызыбыз Әминәгә 6 яшь. Альфред инде 19 яшендә, Икътисад, идарә һәм хокук институтында укый.

Илдар белән ничек таныштың?

– Альфред таныштырды! Улым белән минем дә, Илдарның да тулай торакта яшәгән чагы. Кредитка алган компьютерыбыз ватылгач, Альфред төзәтергә Илдарны табып алып кергән. Шуннан ул безгә кергәләп йөри башлады, башта улым белән дуслашты, аннары минем күңелемә дә юл тапты. Кесәсендә акча булмас, үзе барыбер бүләкләр алыр, күңелне күрергә тырышыр. Бик романтик кеше ул Илдар. Миңа күрсәткән игътибары белән алдыргандыр да инде. Хәрби кеше булса да, ул иҗаттан ерак түгел. Балалар бакчасындагы Яңа ел бәйрәмендә Кыш бабай булды әнә. Булдыра алмас дигән идем, менә дигән итеп «ерып» чыкты. Шаккатып карап тордым.

Мин өйдә бер аякта сикереп, әтәч булып кычкырып йөри алам. Илдар да миңа кушылырга мөмкин. Бүген дә Альфредны уятыр өчен паровоз роленә кердек. Илдар, мин, Әминә, тагылышып, пу-пу дип кычкырып йөрдек. Менә шундый инде без *(көлә)*.

Тагын бер охшаш ягыбыз бар: икебез дә озак үпкә саклап йөри белмибез. Әле генә ут чыгарып кычкырышсак, биш минуттан инде чөкердәшеп сөйләшәбез.

Сезнең гаиләдә кем баш?

– Белмим. Мөгаен, икебез дә баштыр *(көлә)*. Ике тәкә башы бер казанга сыймый, дисәләр дә, без сыябыз.

Берегез – музыкаль телеканалда баш редактор, көнетөне артистлар белән кайнаша торган кеше, икенчегез – хәрби. Балаларга игътибар каламы соң?

– Улым үскәндә, аңа игътибарым җитеп бетмәде – шунысы гына үкенечле. Хәзер гаиләм белән күбрәк булырга тырышам... Альфред үскәч әйтте инде: «Әни, кайда идең соң син?» – диде. Хатын-кызның төп миссиясе гаилә учагын саклау, балалар үстерү булырга тиеш тә бит, тик безнең җәмгыять башкача корылган, эшләмичә яшәп булмый.

Син кемгә охшаган, Айгөл?

– Җитезлегем белән әнигә охшаганмындыр, ә оештыру сәләтем – әтидән. Әни бик йомшак безнең, мин



■ **Тулы исеме:**
Айгөл Вәлиәхмәт кызы Нәбиуллина.
■ **Туган көне:**
14 февраль, 1975 ел.
■ **Туган урыны:**
Теләче районының Олы Мәтәскә авылы.
■ **Эш урыны һәм вазыйфасы:**
«Мәйдан» телеканалының баш мөхәррире.

катырак. Тормыш катырак булырга өйрәткәндер, күрәсең.

Нәзакәтле нәфис Айгөлнең әйтсәң кеше ышанмаслык «кычкырып торган» берәр сыйфаты юкмы тагын?

– Экстрим яратам! Махсус дәресләр алып, атка атланып йөрергә өйрәндем. Парашют белән сикерергә теләгем бар иде, Илдар гына тыеп калды. Әле тагын су мотоциклын йөртеп карыйсым килә. Артта утырып йөргәнем бар, анысының бер кызыгы юк. Менә үзең йөртсәң – бөтенләй башкадыр ул.

«Тимер ат»ны да иярләгәнсең...

– Рульдә 9 ел инде. Хәзер бишенче машинамда йөрим, беренче «тимер ат»ымны алган көн һаман хәтердә. Филармониядә эшләгән елларым. 100 мең сум акча җыйдым мин. Кредит алып, шул булган акчама кушып, салоннан машина алып кайттым. Берүзем! Әле ул вакытта йөртү таныклыгым да юк, укып кына йөрим. Машинаны Филармония ишегалдына тәки кайтарып куйдым. Ул юлда туктап калулар, кабызалмый азапланулар... Белгән кеше белән алырга кирәк бит инде югыйсә. Шулай бервакыт Теләчедән туйдан кайтып барабыз. Баянчы белән тавыш операторы да бар, бөтен аппаратура минем «Нексиа»га төялгән. Кисәк «тимер ат»ым сүнде дә калды. Сәгать төнге ике, урамда декабрь, юлда бер җан әсәре юк. Тегеләр дә, мин дә машинаның «м» хәрефен дә белмибез. Әле ярый бер машина очрап, безне тарттырып кайтты.

Тормышыңда югалтулар күп булган. Сынаулардан сынмаска нәрсә көч бирә?

– Дөньяны гел үзем тартырга өйрәнгәнгә, ир җилкәсенә салынып яшәргә күнекмәгәнгә, эчемдә ачу сакламаганга бирешмим бугай мин.

Кайсы заман кешесе син, Айгөл? Үткәнгә карап яшисеңме, бүгенге тормышыңны гына уйлыйсыңмы, әллә, вакыт пәрдәсен ачып, киләчәккә күз салырга яратасыңмы?

– Үткән тормышны онытып булмый. Элек: «И Ходаем, яшәргә бер почмак бир», – дип сорый идем. Баракта да, тулай торакта да, кешедә фатирда да тордык бит. Эшен дә табам, эшлим дә, яшәргә почмак кына бир, диюемне Аллаһ ишетте. Шөкер, бүген җылы куышыбыз бар. Яшәр урыны булмаганнарга хәзер дә кызганып карыйм. Ялгыз гына бала үстерүче хатыннарны жәллим. Чөнки үзем шул киртәләр аша үттем. Юлда балалы хатын торса, машинамны туктатып, утыртмый калганым юк. Күпме шулай кул күтәреп юлда басып тордым. Тормыш миңа җиңел генә бирелмәде. Кемгәдер бәхет бик тиз елмаерга мөмкин, миңа ул җиде кат тиремне чыгаргач кына килде.

Бөтенесен дә үзем сынап, тотып, йөреп, сикереп карарга кирәк миңа.

Бүгенге көн белән яшим мин, ерак китеп уйлаганым юк. Мин бүген яшәргә тиеш, өч елдан соң булачак тормыш өчен түгел. Киләчәктә дә барысы да яхшы булыр – мин моңа ышанам.

Фәнзилә МОСТАФИНА





АНЫҢ БЕЛМӘГӘН ӨЛКӘСЕ, ЭШЛӘП КАРАМАГАН ЭШЕ ЮК. ҮЗЕ ИКЪТИСАДЧЫ, АШЧЫ, ТЕГҮЧЕ, ЧИГҮЧЕ, БИЮЧЕ, ҮЗЕ ФОТОГРАФ, ДИЗАЙНЕР, БИЗНЕС-ЛЕДИ, СПОРТЧЫ, ӨСТӘВЕНӘ, ҮЗЕ ЯШЬ, ЧИБӘР. ИСЕМЕ – ЗӘРИНӘ.

БЕЗ БУЛМАСАК, КЕМ?



Лилия ГӘРӘЕВА

Зәринә Калменова Казакъстанның Актүбә шәһәреннән. Казакъстанда туып-үссә дә, чып-чын татар кызы ул. Татар әти белән татар әнидән туганга гына түгел, ә җаны, рухы белән дә татар кызы. Нәсел төбе Татарстанның Әтнә районы Кече Әтнә авылыннан. Әтисе Габделфәт абзый – шул авыл егете.

Зәринә белән ничек таныштыкмы? Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы уздырган кызыклы бер мастер-класста очраштык без аның белән. Төрле төбәкләрдә сибелеп яшәүче актив татар кызларын җыеп, калфак белән изү чигәргә өйрәткәннәр иде ул чакта. Зәринәне әнә шунда күреп алдык. Ул үзенә тиешле-сен әллә кайчан чигеп, эшен бетергән дә, күршесенекен чигешә иде. Өстендә җыйнак кара күлмәк, коңгырт чәчләренә чигүле калфак кадап куйган. Әллә шул калфагы белән җәлеп итте инде... Гап-гади күлмәк белән энҗеле калфакны шулай матур итеп яраштырып киюе күңелгә кереп калды бугай.

Туйлар

– Төп эшем – туйлар оештыру. Бу өлкәдә мин инде ун еллап. 2003 елда туйлар уздыру белән шөгыльләнүче бер фирмага эшкә урнашырга килдем. Атна буе очрашуга йөрттеләр, әмма ахырдан эшкә алмадылар. Миннән кайтышларны алдылар, ә мине юк. «Ни өчен?» – дигән соравыма: «Киләчәктә безгә конкурент булуыңнан куркабыз», – дигән җавап ишеттем. Минем ише кыюсыз кыз өчен бу бер этәргеч булды. Мине эшкә алудан баш тарткан шушы ханым аркасында үз-үземне сынап карарга ният иттем. Үз көчемә иң элек үземнең ышануым кирәк иде. Беренче мәлләрдә дус кызым белән икәү эшләдек. Буш урында булдырылган бизнес иде бу. Акчабыз юк югын да, әмма бездәге идея һәм хыял!.. Шуның белән алдырдык та. Әлбәттә, ялгышулар да, күңел кайтулар да, күз яшьләре дә булмады түгел, кая инде алардан башка?! Мин баштарак бәйрәмнәрнең фәкать күңел ачу ягын гына кайгырта идем, тора-бара кичәнең сценариен төзеп, үзем үк алып бара башладым, зал бизәү нечкәлекләрен үзләштердем. Безнең татар туйлары казакъ туйларыннан күңеллерәк уза. Татарлар җырбию, кызыклы уеннар ярата. Казакъларның туйлары башкача – алар борынгы йолаларга зур игътибар бирә, уен-көлкегә күп урын юк. Кунакларга сүз биреп, озаклап аларны тыңлыйлар. Казакъ туйлары ике көн бара. Беренче көнне кәләшнең туганнары, дуслары бәйрәм итә. Кияү ягыннан катнашучы аз. Икенче көнне исә киресенчә, кияү яклары бәйрәм итә. Никах бу көнне загста теркәлә, аннан яшьләр мәчеткә керәләр. Татар кәләшләре заманча туй күлмәкләренә өстенлек бирсә, казакъ кәләшләре борынгы милли үрнәктә тегелгән киемнәрне кия.

«Тырышлык һәрвакыт җиңеп чыга», – дияргә яратам мин хәзер. 2010 елда үземнең бию студиямне һәм фитнес залымны ачтым (дөрес, ярты елдан соң фитнес залын ябарга туры килде). «Махаон» дип аталган шоубалетыбыз эшли башлады. Аның ачылганына быел биш ел була. Корпоратив кичәләрдә, туйларда, төрле бәйрәмнәрдә чыгышлар ясыйбыз. Төркемдә биш кеше – өч кыз, ике егет. Биюләрне бергә куябыз, күнекмәләрне (аның модалы яңа сүзе бар – стретчинг, диләр) үзем үткәрәм. Әле менә икенче запас состав туплый башладым. Кастинглар уздырабыз. Берләттән балалар өчен бию студиясе дә ачмакчы булам.

Зәринәнең тарих дәфтәре

Аның шактый калын тарих дәфтәре бар. Ул дәфтәрнең барлыкка килүен Зәринә болайрак дигән иде. Көннәрдән бер көнне башында кинәт туган уй хәйран иткән кызны: нәсел чылбырының фәкать өч кенә буынын белә икән бит ул! Ерак әби-бабалары кем булганнар, ничек яшәгәннәр, бу дөньядан ничек киткәннәр? Нигә алар хакында берни белми ул?! Бүгенге көндә Татарстанның Биектау районында гомер итүче Рәшидә әбекәе, әти-әнисе исән чакта алардан бар белгәннәрен сөйләтеп калырга тырыша хәзер. Сөйләгән һәр сүзләрен дәфтәренә терки. Нәсел агачын – шәҗәрәне җиде буынгача torгызу өчен, ай-һай, тырышырга кирәк әле. Әмма торгыза алган кадәре дә балаларына, оныкларына нинди зур ядкарь булачак бит. Татарстанга бер кайтуында авылдан авылга, йорттан йортка йөреп борынгы әйберләр дә җыйган әле ул. Узган гасыр башында ук чигелгән ул калфак-кәләпүшләр, каюлы читекләр, намазлыклар (кемнәрдер хәтта ефәк шәлләренә кадәр биргән) хәзер «Шатлык» берләшмәсе музеенда саклана.

Зәринәнең тормышында бәйрәмнәр күп. Чөнки... ул үзе шул бәйрәмнәрне оештыручы.

«Шатлык»лы еллар

Тарих белән кызыксына башлавына да «Шатлык» гаепле. Хәер, «Шатлык»та гына түгел сәбәп. Урам ташларына кадәр тарих сеңгән Татар бистәсендә яшә дә, тарих белән кызыксынма, имеш. Кайчандыр бу бистәдә татар мәктәбе дә эшләгән. Җәлилчеләрнең берсе – Гайнан Кормаш, армиягә алынганчы, аның директоры булып торган. Хәзер «Шатлык» милли-мәдәни берләшмәсе каршында эшләүче якшәмбе мәктәбе һәм Актүбәнең бер урамы аның исемен йөртә, һәр елны яшьләр, җыелып, бу урамга агачлар, чәчәкләр утырталар икән. Актүбәдә Гайнан Кормашның сеңлесе Дания апа Гыйззәтуллина яши. Татар-башкорт яшьләрен үз тирәсенә туплап, татарлыкларын онытырга юл куймаучы «Шатлык» милли-мәдәни берләшмәсе 1999 елда оешкан. Зәринә аңа сукмакны 2008 елда салган. Татар теле дәресләре җәлеп иткән аны. «Бер дәрестә утызар сүз өйрәнә идек. Дәресләр уен рәвешендә узганга, бар да истә кала торган иде», – ди ул. Соңрак аның үзен дә биргә укытучы итеп чакырганнар. Балаларга татар халкының борын-борыннан күчә килгән кул эшләрен өйрәтә ул. 2004 елда «Шатлык» берләшмәсенең бер бүлеге сыйфатында «Мирас» яшьләр оешмасы барлыкка килгән. 14 кеше йөри башлаган булган, хәзер инде «Мирас»лы яшьләр саны илледән арткан. Зәринә аларның әйдәманы. Татар яшьләре дөньяның кайсы өлкәсендә зур очрашуга җыела, алар – шунда. Шигарьләре: «Без булмасак, кем?» Бурычлары зурдан – татар-башкорт яшьләренең милли үзаңын үстерү, телне, әдәбиятны өйрәнү. «Татар телен белгәннәр тагын ундүрт телдә аралаша ала, диләр бит, – ди Зәринә. – Казакъ яшьләре барысы да үз телләрендә сөйләшә, аларда туган телен белмәүчене очратмассың. Без алардан киммени? Безнең дә үз телебезне онытырга хакыбыз юк!»

Сүз дә юк, хәзерге яшьләр бик актив. Үзләренең кайсы нәселдән булуын беләселәре килә, тарих белән кызыксыналар. Тарих ул – без, шушы дөньяга килеп киткән кешеләр. Яшьләр, безнең Зәринә кебекләр – тарих агачының яңа яфраклары. Тарих елъязмасына яңа юлларны инде алар терки.



БЕЗ БУ ҖИРДӘ КУНАК КЫНА



Роза КАМАЛЕТДИНОВА

АВЫЛДА БЕР ЧИБӘР БУЛЫП БУЙ ҖИТКЕРГӘН УЛ. СУГЫШ УТЫ КИЧЕП, КҮКРӘГЕНӘ ОРДЕН-МЕДАЛЬЛӘР ТАГЫП КАЙТКАН ВЗВОД КОМАНДИРЫ ӘБЗАЛ АК КҮҢЕЛЛЕ КЫЗНЫ СӨЕП, БЕРДӘНБЕР ЯР ИТКӘН.

Кайнанага Аккилен, каен сеңелләргә – Акҗиңгә, дүрт кызына Акъәни, оныкларга Акъәби, милләт өчен бик күп игелекле гамәлләр кылган энесе хаҗи Гыйльмулла хәзрәт Хәлиуллинга (рәсемдә алар бергә) фикердәш-сердәш булган ул.

Туган җир яме

Бола буендагы Ташкичү авылында якты дөньяга сигезенче кыз булып аваз салган ул. Бәбидән котылган Бибигалия апаның хәлен белергә кергән күрше хатыны саксызлык күрсәткән, әллә чынлап, әллә юри: «Ни хикмәт бу, кыз туа да кыз туа сездә. Инде монысы үлсә дә бик елама, Галия аптый. Бер малай кирәк бит әле Зәкиулла абзыйга кулалмашка», – дип ычкындырган. Ике сабыен – бер кыз белән улын җирләргә өлгергән хуҗа, шулчак ярсып, күршесенә чак кына салып җибәрмәгән! Күрше хакын, кеше хәтерен саклап яшәүне гадәт иткән итагатьлелеге генә усаллыктан тыеп калган. Әмма авыр сүз күңелендә төер булып укмашкан. Шуңамы, бу кызына иркә-наздан өлеш мулрак та чыккан. Хәер, ике елдан соң дөньяга аваз салган төпчек улын – Гыйльмулласын да бүтән балаларыннан ким яратмагандыр Зәкиулла абзый. Атасының теләк-васыятен үтәп аның дин-исламны торгызу юлында армый-талмый эшләячәген, авылларда гынамы, хәтта ки Казан каласының уртасында агачтан бер дигән искитмәле «Мәдинә» мәсҗеден төзеп куячагын, авылда, районда 9 мәчет салуны башлап йөриячәген дә әйтсәк...

«Бәхете белән туган булсын!» дигәндер дә, шул заманда киң таралган җырдагыча, кызга Өммегөлсем дип исем куйгандыр әти кеше. «Бас әйдә, Өммегөлсем, / Идәннәре бөгелсен. / Басуында зур бәхетнең / Чаткылары күренсен!» Бию көенең сүзләре кызның мәңгелек юлдашына әйләнгәндер шул, яшьтән үк оештыру сәләтенә ия Гөлсем Зәкиуллина туган ягын агарту, мәдәниятне күтәрү, авыл яшьләренең ялын ямьлерәк, күңелле һәм файдалырак итеп оештыру хасиятенә баш-аягы белән чумган. Клуб мөдире, режиссер да ул, сценарист, китапханәче, агитатор, пропагандист та...

«Кешедән ким дә, артык та түгел, бүтәннәр ничек яшәсә, шулай яшәдек», – сиксән бишне тутырган Гөлсем апа ил белән уртак шатлыкларны бәхет санаган. Кайгы-хәсрәтләр аларны да читләп үтмәгән.

Урланган балачак

Бердәнбер абыйлары – Газизулланың тальян гармун тартып: «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз, / Сау булыгыз, туганнар» дип җырлап урам әйләнгәне үсмер кыз хәтеренә онытылмаслык булып уелып калган. Кара мөһерле кәгазь – Смоленск янында улының һәлак булу хәбәрен алган әнкәсенең ачы күз яшьләре үзәк-бәгырьләргә үткән. Күкрәк баласын кочып, Нәгыймулла җизнәләрен фронтка озаткан иң олы апалары Бибиһәдиянең дә газиз гомере сугыш кырында ятып калган ирен көтеп узган бит әнә. Юанычы – улы Гомәрне яхшы кеше итеп үстерү хасияте, әлбәттә, тол хатынның ялгыз тормышын күркәм сабырлык белән баеткан.

– Колхоз эшенә җигелгәндә унбер яшь кенә иде миңа, – дип хатирәләр яңарта Гөлсем апа. – Әтиәни, апалар һәммәсе кырда. Өйдә бер мин дә, җиде яшәр Гыйльмулла туганым кала. Ашарга пешерү дә, өй җыештыру да минем өстә. Өчәрдүртәр оя каз-үрдәкне энем белән икәүләп күлгә куу, басуга кермәсеннәр дип, каз көтү... Керсәләр, беттең, штраф дип кот оча.

«Эшкә ник чыкмыйсыз?» – дип безнең ише бала-чаганы кәнсәләргә чакырттылар да бер бүлмәгә ябып куйдылар. Тоткын булдык, елашабыз. Кая ул башка колхоз эшеннән калу! Утауга йөрү, печән әйләндерү, ындырда ашлык җилгәрү – берсе дә калмады. Уку башланганчы дәвам итә иде бу хәл. Сугыш елларында уку да онытылды. Ашлыкны кырып-себереп көз көне хөкүмәткә тапшырып бетерәләр. Язын, чәчүлек орлык калмагач, район үзәгеннән кул арбасына төяп, чәчәргә ашлык ташыйбыз. Ирләр, хәтта атлар да фронтта. Буадан безгә кадәр утыз чакрым юл үтәсе. Һич онытмыйм, яз башы иде, җир туң. Үзле балчык аякка, тәгәрмәчкә сылана. Апа арбаны көч-хәл белән сөйри, мин арттан этәм. Аяк тая, туң җиргә үкчәне тери-тери этәргә тырышкан булам. Апа борылды да, рәнҗеп: «И сеңлем, бер дә этмисең бит, бигрәк авыр ич», – дип елап җибәрде. Ул елый, мин елыйм.

Ару да җиткән, нахак сүз бигрәк тә үзәккә үтә икән. Ул чакта бер сүз әйтмәдем. Еллар узгач, җитмеш елдан соң, михнәт чиккәнне искә төшереп утырдык та: «Апам, тырыша-тырыша уфалла арбасын эткән аркылы, миңа: «Булышмыйсың» дип әйткән идең», – дидем. «И бәгърем, шулай дидемме? Кичер инде мине, гафу ит!» – дип тагын елаштык.

Сау-сәламәт озак яшәү табигать сереме, әллә могҗизамы?!

Ат тарта алмаслык йөк тарткан-быз ич. Ачлык. Хәл юк. Яшәргә, эшләргә кирәк. Кырда арыш йә бодай уып тамак ялгарга азапланганга закон аяусыз – төрмә. Әле дә оныта алмыйм, Сафиулла абзый кызы Саҗидә күкрәкчәсенә борчак тутырган икән. Районнан вәкил бар дип безне тентиләр. Сафиулла абзый – бригадир, Саҗидәне ярды гына. Көчкә хатыннар аралап алды. Кем белә, мәҗбүр булгандыр, бәлки – бүтәннәргә дә сабак булсын дигәндер. Кырдан, ындыр табагыннан эштән кайтканны саклап кына торалар иде ич. Берсендә Хәтимә исемле кызыбыз яулыгына төйнәп арыш уып алган. Вәкил белән бер укытучының качып торганын күреп, чабарга тотынган бу. Ул чаба, тегеләр чаба. Төенчеген арыш арасына ыргытып качкан. Табылдыкны тотып ындырга килгән болар. «Кем яулыгы?» Яулык та кадерле заман бит, артында бүтәне юк. Әнисе Маһибәдәр апа: «Хәтимә яулыгы бу», – дип әйтеп ташлый. Ундүрт яшьлек кызны бер кило да ике йөз грамм арыш урлаган дип, биш елга хөкем иттеләр. Унтугыз яшендә генә кайтты. «Андагы хәлләрне сөйләсәң, кеше ышанмас, – дияр иде. – Мине олы апалар – тоткын хатыннар бик нык саклады. Ярты адым артка калсаң беттең, ирләр тартып кына ала. Ә аннан... Сине мәсхәрәләү берни тормый», – дия иде. Бәхете булмады бахырның, ире эчә торган кеше туры килде. Ике баласы бар иде, яшьләй харап булды шул.

Күңелле чаклар

Уйлап утырам менә, эш белән узган гомер. Эш бәхете язган икән безгә. Әллә мактауларга исебез киткән, алны-ялны белми чапканбыз. Хезмәт көне юк, мактап газетага язалар – шуңа тырышканбыз, ахры. Холык шундыймы, белмәссең. Ясмык, борчак кишәрлекләрен бүлеп бирәләр, кара тиргә батып эшлисең, кайтып мунчада коенып-юынып чыгасың да – клубка! И безнең замандагы авыл!

«Кешедән артык йә ким җиребез юк, алай да өлге булып яшәдек, шөкер».

Сугыштан соң яшәүнең кадерен белеп, гөр килеп, уйнап-көлеп, һәр мизгелне күңелле итеп яшәргә тырышканбыз бит. Яуга киткәннәр, кайтмый калганнар өчен дә яшәлгән әллә... Чынлап, нинди генә спектакль, концертлар куймадык, нинди генә кичәләр оештырмадык! Театр куябыз дип, сыер савучы, тракторчы, һәммәсе атлыгып тора. Миндә эшең булмасын диюче юк, шигырен дә ятлыйлар, җырын да өйрәнәләр. Биюне әйткән дә юк. Клуб шыгрым тулы була, диспутәңгәмәләр үткәрәбез: «Нәрсә ул бәхет?», «Мәхәббәтне ничек сакларга?» – олы-олы апалар килеп утыра, сорау бирә, сөйли. Үземә утырырга урын да калмый. Берсендә күрше апага әйтәм, бала-чагаңны ияртеп йөрми, үзең генә килсәң булмыймы, ичмасам, дим. «Ничек, кемгә калдырыйм, миннән алда киенеп куялар, күңелле ич монда», – ди. Үзем дә өч балам булгач, Алабугага мәдәни-агарту училищесына укырга кереп, читтән торып белем алдым. Курс эшләремне үрнәк итеп күрсәттеләр.

Бәхеткә, кайнанам да бик яхшы кеше булып чыкты. Дус яшәдек. Балалар ялгыз кала дигән уй башка да кермәде. Шуңа күрә генә кырык дүрт ел буе һәр көн кич чыга торган шундый эштә эшли алганмындыр да инде. Югыйсә эш-мәшәкать дигәне хәттин ашкан, кунак-төшемсез, кешесез торган көн юк. Әтиләре Әбзалетдин данлыклы агроном иде. Казаннан да, районнан да кем генә килми. Бүтән җирдә берәр әбидә аш-су көйләтеп кунак сыйлыйлар. Кем генә килсә дә, безнеке өйгә чакыра. Пешер-төшер, өлгер генә. Бәләкәй генә өй тулы кеше, ник бер тапкыр ызгыш-гауга купсын. Алай да, үзебезгә йорт җиткермәкче булдык. Идәне-түшәме әзер, кершәндәй ап-ак миче кукыраеп утыра. Сүз уңаеннан, әтиебез Зәкиулла тирә-якка билгеле мичче иде. Сугыш елларында, хәер, сугыштан соң да ятим-җилпе, ярлырак гаиләләргә бушка мич чыгарганын хәтерләүче байтак. Шуннан – шул, йорт әзер.
Ә без күченүне сузабыз. Берәү әнкәйгә «акыл бирә»: чыгып китә белмәсәләр куып чыгар син аларны, ди икән. Кайнанам шуны сүз итеп кайтып сөйләгәч, күчендек. Бик авыр булды. Ярты сәгать үттемеюкмы, бер бөтен ипи, бер шешә керосин тотып әнкәй кереп җиткән. «Нәрсә елап утырасың? Чәй куй, бергә яшәдек, моннан соң да бергә яшәрбез», – ди. Аннан үзе дә шушы йортка, безнең янга күченде.

Һөнәрле гәүһәрледән артык

Гөлсем апаның төпчеге – Яшел Үзәндәге «Алчәчәк» балалар бакчасында рус балаларына татар теле укытучы Гүзәл Мифтахова сөйли:

– Үз әнисе һәркемгә бик кадерле. Сүз дә юк. Әмма безнең әни кебек уңган-булганнар сирәктер ул. Миңа шулай тоела. (Ялт кына тора да гаҗәеп матур итеп бәйләнгән бишмәт киеп чыга.) Күрегезче, сәнгать әсәре түгелмени бу? Оекбаш, бияләйләрне әйткән дә юк, күпме күлмәк, кофта, итәк, бишмәткә кадәр бәйләп кидерде ул безгә. Шаккатып, ничек болай бай яшисез сез, дия иде дус-иш. Ә ул, берсе кечерәйсә, сүтә дә икенче төрле итеп бәйләп бирә. Кулы кулга йокмый, бизәген отып ала да, карап та тормый, бәйли дә бәйли. Күз нурлары бизәккә әйләнгән шәлләрен генә күрегез! Сиксәнне ваклагач, төсем булыр дип, дүртебезгә дә бертөрле бизәкле шәл бәйләвенә әле дә ис китә.

– Шөкер, зиһен дә көчендә әле. Саулыктан да зарлану гөнаһ булыр. Иң кирәге – күз генә начарайды, – дип офтанып куя Гөлсем апа.

– Күзлек өстенә лупа куеп, һаман шигырьләр укый әле ул. Әллә ничә төрле газета-журнал яздырып ала. «Сөембикә»не ярата. Бер ел калдырмый алдырган. Ышанасызмы, кырык биш ел буе җыеп, төпләтеп, саклап тота ул аларны. Татар теле укыткач, миңа эшемдә кирәк чаклары була. Кистерми, бөкләтми. «Күчереп ал да кире үз урынына куй», – дип кенә тора.

– Укымаган, китаплардан гыйлем җыярга атлыгып тормаган яшьләрне кызганам мин. Зиһенне баета, күңел офыкларын киңәйтә бит уку. Китап-журнал бик кадерле чакта яшәдек шул без. Ташкичүдә чакта әле, кайсыдыр елга кадәр басылган китапларны списать итәргә куштылар. Ни генә юк, дөнья әдәбиятыннан тәрҗемәләр бар иде. Келәткә бикләп әсир иткән китапларны җәлләп eладым. Гүя җанлы алар. Рәнҗеп яталардыр сыман тоелды.

«Карагы шәп иде»

– Безнеке кебек бакча авылда бүтән юк иде. Әнинең розалары күз явын алырлык. Ал, кызыл, сарыларына кадәр үсә, чәчәк ата. Җәннәт бакчасымыни! Туйга, туган көннәргә чәчәк сорап киләләр, кызганмый әни, бирә дә җибәрә.

– Гөлфинур исемле үсмер кыз Казанга укырга китәргә, биолог булырга хыялланды. Серен сөйли: «Кеше арасына киярлек күлмәгем генә дә юк шул...» – ди. Бер дә кимәгән күлмәгемне сандыктан алдым да кидердем. Кызлар – Мәскәүдә, әллә нинди яңа модалы киемнәр җибәреп торалар. Җәлмени яхшы кешегә. Укыды, биолог булды. Селекция белән шөгыльләнде. Яңа сорт роза үсентеләре, мәк, тагын әллә нинди чәчкә-гөл орлыклары алып кайтып куандыра иде. Әни дә тәрәз төбе тутырып гөл үстерергә яратты. Мин дә маһирланып киттем. Күңел биреп караганны ярата нәзберек чәчәкләр дә.

Бер елны эре чәчәкле мәкләр басты бакчаны. Су сибеп йөрим, әзмәвердәй өч егет койма янында тукталды. «Мәгегезгә зыян китерми генә сутын суыртып алыйкчы», – ди берсе. Наркоманнар истә-оста юк чак әле бу. Кем белгән аларның холык-фигылен. Китегез, кит, димен. Таң алдыннан кыштырдау ишетеп тәрәзәгә килсәм, төбе-тамыры белән йолкып яталар мәкләремне. Тәрәзә төям, куркытам, имеш. Җыеп чыгып киттеләр. Теге спектакльдәгечә: «Караклары шәп иде», – дияргә генә калды. Тәрәзәңә таш атсалар да, берни эшли алмас идең. Карак дигәннән... Роза-гөлгә кызыгучы азмыни? Берсе, сындырып җыймакчы булган, энәле бит, чәнчи. Кибәргә элгән җирдән Ләйсәннең күлмәген йолкып алган. Мәскәүдән апасы җибәргән затлы күлмәк тишкәләнеп беткән. Үкереп елый онытым. «Ярар инде, кызым, елама. Берәү кызы янына ашыккан, чәчәк биреп куандырасы килгәндер. Кибетләр ябык. Юк та әле затлы роза кибеттә. Сөйгәнен сөендергән», – дип юатырга тырышкан булам. Чәчәктән бигрәк күлмәге жәл шул оныгыма.

Әллә нинди ел булды ул, берсендә Казан кунаклары белән әтиләре бакчада төн ката кәеф-сафа корып утырган. Абзар ишеген кемдер ачык калдырган. Сыер саварга чыксам, һушсыз кала яздым, каз-үрдәк, сарыклар җирне «сөреп» чыккан. Кишер-чөгендер, кыяр үсентеләре җир өсте тулып ята, розалар сынып беткән. Иремнең: «Әллә елап утырасыңмы шулар өчен?» – дигәне бик авыр ишетелде. Шулай язган Ходай, дидем дә бетердем.

– Кайчак без алай түгел, болай, дип яшьләрне гаепләргә яратабыз. Төрле кеше бар бит. Ләйсәнгә кыйммәтле телефон алып бирдек, – дип сөйли Гүзәл. – Берсендә дус кызы белән паркка китте бу. Күп тә үтми, телефон шалтырый. «Кызым, ни булды?» – дим. Ир-ат тавышы: «Ләйсән телефонымы бу? Килеп алыгыз», – ди. Коелып төштем, сүз дәшә алмыйм. Әйткән җирләренә барырга куркам. «Ярый, монда тагын бер сан бар, шунда шалтыратабыз», – дип сүзен бетерде. Ничә үлеп ничә терелгәнмендер. Бераздан кызым хәбәр бирә: телефонын ялгыш төшереп калдырган булган. Ике егет тапкан. «Китереп бирделәр», – ди. Телефоннарын да аласың бар ие. Күчтәнәч илтер идем, дим. «Иптәш кызымда мең тәңкә бар иде, бирмәкче булган идек. «Сез, нәрсә, саташтыгызмы әллә?» – дип кул селтәп китеп бардылар», – ди.

Сандык кыйссасы

Әбзалетдин кызларын үскән чакта да, хәтта хәзер дә ил-көнгә үрнәк итеп сөйләүләре хак. Булдыклы, тыйнак, ярдәмчел дүртесе дә. «Олысы Гөлшат унны бетергәч тә Мәскәүгә китте. Һөнәр алды, фабрика укытты аны. Башта контролер иде, аннан үзләрендә баш бухгалтер иттеләр. 62 яшьтә, әле дә эшли. Флерам шәфкать туташы, Коми Республикасына китеп озак еллар эшләде, йөрмә читтә, дип, чакырып кайтардык. Бик сагына дусларын, эшләгән җирен. «Мин анда командир идем», – ди. Хәер, монда да яраталар үзен. «Дельфин» шифаханәсендә ул хәзер. Венерам да шәфкать туташы. Мәскәүдә гинекология бүлегендә эшли. Ил-көн күзендә хөрмәт казанды. Ире бик башлы кеше булып чыкты. Киявебезне әйтәм. Нижгарлар тырыш халык бит. Аш-су остасы – повар иде. Илдә үзгәрешләр башлангач, бәләкәй генә бер ашханәне арендага алып, кафе ачты. Җан тырмашып үз эшен көйләде».

Һәм шул Рәфикъ кияү, Гөлсем ханымның хаҗга барырга хыяллanганын белеп, хаҗ сәфәренә җитәрлек акча бирмәкче була.

– Хикмәт юмартлыкта гына түгел, җизнинең әнисе бик иртә вафат булган. Үз әнкәсенә күрсәтә алмаган кадер-хөрмәтне Акъәбигә күрсәтергә теләве табигый. Аламы соң әни, фәкать үзең җыйган хәләл акчага гына фарыз хаҗ гамәле, дип, шунда ук баш тартты. Тиенләп җыйса җыйды, изге Мәккә туфрагына баш орырга ашкынды, – дип сүз җебен ялгап җибәрә Гүзәл.

– Гыйльмулла хәзрәт Мәскәүдән очсаң сәфәр арзанрак дип киңәш итте. Кызым озатып калды. Шөкер, авыр, җаваплы бурычым үтәлде. Ходай кабул итсен!

Әмма кияү дә әйткән сүзен үтәми кала торган зат түгел. Изгелек эшлим дигән кешегә җае чыга ул. Яшел Үзәнгә күченгәч, картын җирләгән әбисенең иске йортта яшәве аңа да тынгы бирми. Сугыш елларында фидакарь хезмәте өчен медаль алган ветеран әбигә фатир алу мөмкинлеге туа. Ләкин бүленгән акчаның бер бүлмәле яңа фатир өчен җитенкерәмәве ачыклана. Кияү җитмәгән сумманы бер сүзсез үзе түли. Бик әйбәт ремонт ясата, өр-яңа җиһазлар сатып ала. Ә кызлары йорт ачкычы белән бергә әбигә үгет-нәсыйхәт бирмәкче була. «Әни, өең җиһазлы, бар дөньяң ялт иткән. Рәхәтен күр. Искемоскыңны алып йөрмә, калсын». «Сандыгымны алам!» – ди әби, ике сөйләшмәслек итеп. «Анда сандык сыймас шул». «Сандыгым сыймаган җиргә мин дә сыймам!» Өй түренә иң әүвәл әбинең сандыгы килеп кунаклый.

Белгән-күргән аны яратып, Акъәбиебез ул безнең ди икән, монда хикмәт бар.

– Ничек калдырыйм, үлемтекләрем ич анда, – ди гади генә. Өсти:

– Без бу җирдә кунак кына. Хак Тәгалә каршына баргач расланыр кемлегебез. Әти васыятен үтәп һәммәбез намаз-ниязлы булдык.

Күңелемнән озын гомернең сере нидә дигән сорауга җавап эзлим.

- Озын гомернең сере – татулыкта, билгеле.
- Хәрәкәттә – бәрәкәт.
- Ачуланма. Кешегә явызлык теләмә.
- Елмай. Кыен хәлгә калганда да күңелеңне төшермә. Үз-үзенә тәнкыйть күзе белән карый белгән кеше зирәк, акыллы.
- Игелек эшлә дә суга сал, балык белер, балык белмәсә Халикъ белер.



ТАТАР КЫЗЫН ӘГӘР ТАНЫЙМ ДИСӘҢ...

МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕНЕҢ «ПЛАНЕТА КВН» СӘХНӘСЕНӘ КҮТӘРЕЛГӘНЧЕ «ТАТАР КЫЗЫ-2014» ФЕСТИВАЛЕ БАШТА РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕ БУЙЛАП УЗДЫ: ТҮБӘН НОВГОРОД, ПЕНЗА, ПЕРМЬ, ЧИЛӘБЕ, ЕКАТЕРИНБУРГ, САНКТ-ПЕТЕРБУРГ, САМАРА...

Туташларның иң-иңнәрен генә сайлап алдылар: милли гореф-гадәтләребезне, йолаларны, тарихи мирасны, мәдәният-сәнгатьне, телне... белгәннәрне. Бәйгене оештыручылар өчен (РФ Дәүләт Думасының милли эшләр комитеты, Федерация Шурасының фән, мәгариф һәм мәдәният комитеты, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе, Татарстан Республикасының мәдәният министрлыгы, «TATProject» милли-мәдәни берләшмәсе) шартларның соңгысы – туган телне камил белү – барысыннан да мөһимрәк иде.

Фестиваль, алдан вәгъдә ителгәнчә, бөтен татар дөньясын шаулаткан зур вакыйгага әйләнде. Җиңүче таҗын Алинә Гыйззәтуллинага (Уфа) кидерделәр.

– Алинә, титуллы «Татар кызы» булу ничегрәк?

Хис-тойгылары ташып торса да, ул татар кызларына хас тыйнаклык, тотнаклылык белән җавап бирде:

– Бәйге тормышымны тамырдан үзгәртте, димим. Анда алган тәҗрибәне дә көндәлек тормышымда кулланам, дип әйтә алмыйм. Ул минем тормыш картинамның бер сурәте булды. Мөһим сурәте. Ә болай... мине таный башладылар! Яхшымы бу, начармы – анысын әйтә алмыйм әле, ләкин миңа ошый.

Күрәсең, мин Алинәнең җавабыннан пафос көткән булганмындыр, янәсе, хәзер бөтен татар кызларының тәрбиясе өчен җаваплылык аның җилкәсендә яисә планетаны явызлыктан коткару минем кулда дигән кебегрәк, мәсәлән. Алай димәде Алинә. Гомумән, башка «мисс»ларга кебек, «Татар кызы» җиңүчесенә таҗ белән бергә мәҗбүри бурычлар кидертмәгәннәр. Бүгенге көндә – ул КФУ студенты, модель һәм «Мин – волонтер» хәрәкәтен оештыручыларның берсе. Күптән түгел аны спортның су төрләре буенча Казанда үтәчәк Дөнья чемпионатының илчесе итеп билгеләгәннәр. Саный китсәң, иҗтимагый бурычлары да шактый җыела икән.

Гомумән, узган 2014 ел Алинә өчен уңышлы булды: башта ул Уфада үткән «Нәүрүз гүзәле»ндә Гран-при алды, аннан соң Мәскәүдә узачак «Татар кызы»ның сайлап алу турын узып, финалистлар исемлеген ачып җибәрде. Җиңел генә үтелгәнме бу сынаулар?

– Иң кыены – костюмнар, туфлиләр һәм хатын-кыз өчен кирәк булган шундый вак-төякне төянеп йөрү булды, – дип искә ала Мәскәүдә үткәргән көннәрен чибәр туташ. – Оештыручылар калган уңайлыкларны тудырган иде: вокал, сөйләм теле буенча репетиторларга, режиссерларга, кураторларга һәм ике атна эчендә бер команда булып оешкан кызларга рәхмәт!

Истә калырдай мизгелләр күп булган анда: сынауларның берсе – токмачлы аш пешерү дә, ЛДПР лидеры Владимир Жириновский белән очрашу да, «Останкино»га кунакка бару, яучы ханым Роза Сябитова белән аралашу да...

«Кияүне... җитешсез якларына карап сайларга кирәк», – дигән Роза ханым булачак кәләшләргә. «Ул безгә бик күп киңәшләр бирде, монысы иң истә кала торганы булды», – дип елмая Алинә дә.

Шулай да Алинәнең Россия күләмендә үткән Гүзәлләр бәйгесендә җиңү сере нәрсәдә булды икән соң? Бәйгедә катнашу өчен төп таләпләрнең берсе – татар телендә сөйләшә белү генә түгелдер, әлбәттә. Монысы, Каюм Насыйри сүзләре белән әйткәндә, үрдәк бәбкәсен суга ыргыткач, бәбкә җиңел генә йөзеп киткән кебек халәт. Башкортстанның Туймазы районында туып-үскән кыз да туган телендә иркен сөйләшә. Алинәнең кечкенәдән сәхнәләрдә җырлап-биеп йөрүеме? Алай дисәң, һәркайсыбыз – авыл сәхнәсенең йолдызы.

– Җиңүгә ихлас ышануымдыр, – диде Алинә.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА









Альбина Ситдыйкова
Татарстан



Ландыш Гыйбадуллина
Киров өлкәсе



Алинә Гыйззәтуллина
Башкортстан



Эльнара Тихомирова
Новосибирск



Юлия Акчурина
Саратов өлкәсе



ГЫЙНВАР

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	31
Я	4	11	18	25	

ФЕВРАЛЬ

Д		2	9	16	23
С		3	10	17	24
Ч		4	11	18	25
П		5	12	19	26
Җ		6	13	20	27
Ш		7	14	21	28
Я	1	8	15	22	

МАРТ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

ИЮЛЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

АВГУСТ

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

СЕНТЯБРЬ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

сөембикә

2015



Гүзәл Хәсәнова
Ульян өлкәсе



Диләфрүз Баһавиева
Санкт-Петербург



Камилә Якубаева
Мордовия



Римма Маринова
Марий Иле



Лилия Итенова
Омск өлкәсе


Резеда Галиева
Мәскәү


Гөлназ Ганиева
Свердлау өлкәсе


Алисә Арангулова
Төмән өлкәсе


Равилә Хәйрзаманова
Чиләбе өлкәсе


Регина Хаҗиева
Удмуртия



«Татар кызы-2014» Бөтенроссия гүзәллек фестивалендә финалга чыккан сылулар.

АПРЕЛЬ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	

МАЙ

	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31

ИЮНЬ

1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	
7	14	21	28	

ОКТЯБРЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	

НОЯБРЬ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

ДЕКАБРЬ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	


Эмине Хәйруллина
Кырым Республикасы


Лилия Гарипова
Түбән Новгород өлкәсе


Гөлнара Вяльшина
Пенза өлкәсе


Айгөл Галиева
Самара өлкәсе


Мәдинә Дасаева
Әстерхан өлкәсе



БУ ЙОРТКА МИН ИКЕ ЕЛ ЭЛЕК – ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ ДИГӘН МӘРТӘБӘЛЕ ИСЕМ РАБИГА СИБГАТУЛЛИНАНЫ ЭЗЛӘП ТАПКАН КӨННЕ КИЛӘСЕ БУЛГАНМЫН.

Ләкин сукмагым бүген генә төште. Соңарган визитым да нәкъ вакытында, нәкъ көнендә булып чыкты.



Асия
ЮНЫСОВА

САФ АЛТЫН

Кышның гаҗәеп матур бер көне. Мул итеп яуган карлардан соң күк йөзенә саф алтыннан коелган олы тәңкә сыман кояш кунаклаган. Яшь кар күзне чагылдырып җемелди. Мондый көнне өй эчендә сүзгә алданып утырасы түгел дә соң... Ләкин кирәк. Ике халык артистын – җырчы Рабига Сибгатуллина белән композитор Фәрит Хатиповны – татар эстрадасының ике бурлагын инде хәзер дә якты кояш нурына күммәсәң...

Алар да кышны ярataлардыр дип уйлыйм. Чөнки икесе дә, хәер, уллары Илнур да гыйнварда туганнар. Бүген, җитмәсә, аларның кавышканнарына да кырык ел икән. Нинди туй була соң әле? Якутмы? Нәкъ көне дигәнем шушы датага ишарә иде.

– Юк, мин кышны яратмыйм. Егерме алты ел дәвамында гастрольләрдә йөргәндә кышның газабын күп татыдым. Аякка олтанлы итек, өскә тун киеп, одеял ябынып төн үткәргән, ишегеннән буран бәреп торган кунача урыннарын, аларны кунакханә диярга тел әйләнми, онытырлык түгел... Ат арбасында, трактор чанасында барулар, өшегәч, чана артыннан чабулар... Мин күп җырчылар белән эшләдем. Илһам Шакиров белән дә, Эмиль Җәләлетдинов белән дә... Беренче бригадам Габдулла Рәхимкуловныкы иде. Мәрхүм җырчыбыз, җитәкчеләргә залның салкын икәнлеген төшендерү өчен, сәхнәгә бүрегенең колакчыннарын төшереп чыга торган иде.

Багажга электр плитәсе, үтүк, табак-савыт төяп чыгып китеп, яз кузгалып, көз кайтулар михнәтнең иң олысы түгел әле. Иң олысы – малайны калдырып китү! Инде үзе әти булган Илнур көтмәгәндә җитди итеп сорап куясы итте: «Кайда булдыгыз соң сез мин үскәндә?» Ярый әле 10 нчы интернат-мәктәп коткарган. Шул мәктәп Илнурдан менә дигән татар егете үстергән. Әлбәттә, җәй айларында малай да гастрольләргә кушыла. Кая барсын! «Бер җәйдә генә дә 110 концерт бирдек», – дип, Рабига ханым кабат гастрольләр дәверенә әйләнеп кайта.

Хәзер шулай «тирләсәләр», бу гаилә юл буендагы йортның бер фатирында түгел, бәлки, шәһәр читендәге виллада яшәр, иң шәп машинада йөрер иде. Юк шул, аларның чәчәге артистлар «таякка» эшләп йөргән елларның юлына сибелгән.

Кибәнне уртадан ишә башладым бугай. «Алар» дип сөйләргә дә иртәрәк. Әле бит Рабига гына. Тукай-Кырлай авылы кызының мәктәпне бетереп, тормыш юлын сайлыйсы бар. (Бу урында Рабига ханым Тукай-Кырлай мәктәбендәге укытучысы Рәисә Насретдинованың исемен язмага кертүне үтенде. Игътибарлы укытучының ядкарен ата-ана ядкаре белән янәшә куйды ул.) Музыкаль белем бирә торган уку йортыннан башлар бит инде ул, әлбәттә. Бик шулай да бит. Тик алты балалы гаилә баласы җырлап йөрүне табигый бер күңел халәте генә дип белә. Җырлап йөрүнең һөнәр икәнлеген, аның өчен әле укыйсы да барлыгын башына да кертеп карамый. Рабига Казанга апасы янына килеп урнаша. Резина-техник эшләнмәләр (РТИ) заводына эшкә керә. Озын-озын торбаларны күтәреп кую, аларга резина муфталар кигерү – кыз баланың вазыйфасы. Өч сменалы авыр эшкә авыл кызы чыдар дигәннәрдер. Чыдый да инде – сыер саумаганмы, утын ярмаганмы әллә ул?



■ Сара ханым Арча кызын бер күрүдә ярата. «Булса да булыр икән моңлы бала. Самородок син», – ди ул Рабигага. Ягъни саф алтын. «Мин түгел, минем әнием Гөлчирә ул саф алтын, – дип җавап бирә кыз остазына. – Сез аның нәүрәп куышында кешедән качып, тальянда уйнап җырлаганын ишеткәнегез юк әле!»

Менә шундый ул «зато без артистлар, халыкка хезмәт итәбез!» дип йөрүләрнең сәхнә арты.

Эшче яшьләр салган сукмактан килә ул Сара Садыйкова җитәкләгән татар хорына. Шунда бергә хорга йөргән иптәшләр белән дуслык әле дә дәвам итә икән.

Ул Гөлчирәгә еллар аша мин дә сокланам. Чыннан да, менә ул «самородок» булгандыр. Нота белү түгел, радио да юк заманда шундый һәвәслек аңа каян килгән? («Зәйнәп Фәрхетдинова репертуарындагы «Яратам-яратам» дигән җырны да минем әни чыгарган иде», – дип тә гаҗәпләндерде әле җырчы ханым.) Рабиганың әтисе – ире Миндияр белән икесе ике тальянны алып утырган сәгатьләр – менә шул инде балаларның музыка мәктәпләре!

Беркөнне репетициядән соң Сара ханым Рабиганы алып кала да үгетләргә керешә: «Кызым, Мәскәүгә

барырсың. Төркем җыялар. Теләүче күп, әмма мин сине сайладым. Артист булырсың. «И-и, Сара апа, бармыйм ла мин. Артист та булмыйм. Аларны бозык була дип әйтәләр», – ди беркатлы Рабига. Шунда Сара ханым кызып китмәсенме! «Артист түгел, кеше үзе бозык була. – Рояль яныннан сикереп тора да, 33 нче үлчәмле туфли кигән аяклары белән идәнгә тибә-тибә, кызны ачулана башлый. – Талантың синеке түгел, ул – халыкныкы! Барасың, укыйсың! Кайтасың, җырлыйсың!»

Вокзалга яшь талантлар төркемен озатырга бөтен хор җыелып төшә. Шөкер, ялгызы түгел. ВДНХ мәйданында урнашкан «Яшел театр» дип йөртелгән, Ипполитов-Иванов исемен йөрткән эстрада сәнгате уку йортына татарларга Римма Ибраһимованы, Клара Хәйретдинованы, Зиннур Нурмөхәммәтовны, Рабига Сибгатуллинаны, Хәния Фәрхине тәрбияләп биргән өчен генә дә рәхмәтле без.

Кыз чыннан да саф алтын икән. Мәскәүгә килеп бер ел укуга Чайковский исемендәге концерт залында Татарстан Республикасының 50 еллыгына багышлап уздырылган зур концертта «алтынга» ялтырап алу өчен форсат та чыга. Аның «Гөлҗамал»ы тамашачыны тетрәндерә. Ике тапкыр чакырып җырлаталар. Менә бу тавыш, ичмасам! Үзе куәтле, үзе киң сулышлы, үзе тыгыз! Бер олау көмеш кыңгыраулар чыңы татар кызларының мең еллык сагышын залга түгә дә сала. Алкышлар, әлбәттә, аягүрә! Рабиганың андагы җырын сәнгать белгечләре хәзер дә онытмаган әле. Мин дә яшь җырчының авыл клубында моннан 44 ел элек җырлаган «Гөлҗамал»ын бер кадерле, татлы төш сыман итеп күңелдә саклыйм.

Авыр эштән арыган татар баласын гомер-гомергә җыр юаткан.

Авыл өйләренә Рабига Сибгатуллина «Назлы гөлкәем» җыры белән килеп керде. Тәрәзәләрне бәреп ачты, һәр өйдән урамнарга түгелде ул җыр. Элек заман җыр авторы җырчы белән бергә йөри иде. Шулай итеп, халыкка онытылган шагыйрь Ярлы Кәрим исеме кайтты. Аннары «Актаныш таңнары», «Туган җиремә». «Бер тауда ун чишмә» дигәнен шагыйрь Сибгат Хәким гел дә менә Рабиганың чишмәләрдән су алып кайтканын карап торып язгандыр кебек.

Гел аныкы гына булган җырларны аңа Фәрите – композитор Фәрит Хатипов язар әле. Инде аларны кавыштырсак та ярыйдыр. Теләче егете кыз канат җәйгән арада Теләче, Саба клубларында эшләп, армиядә булып, Халык иҗаты йорты каршындагы баянчылар курсын, аннары Казан музыка училищесын тәмамлап өлгергән. Әллә ничек кенә алгысып, җырлар язып карыйсы да килеп йөргән чагы. Радиодан бер Рабига исемле кызның җырлаганын йотлыгып тыңлый. Их, шул кыз син язган берәр җырны җырласын иде дә иртәгәсен мәшһүр булып уянсаң иде ул! Мәшһүрлеге бер хәл, кызның тавышы, андагы тыенкы дәрт әсәрләндерә егетне. Туганнарына кергәч, бер ят кызны күреп кала егет. Чибәр, ягымлы. Рабиганы онытырса, шул кыз гына оныттырыр!

– Кем бу кыз?

– Җырчы Рабига Сибгатуллина.

Дәвамы аңлашылса кирәк. Юк, шундук туй түгел. Мәдәният һәм сәнгать университеты тулай торагының тугызынчы катындагы бүлмәдә бер гаилә булып яши башлаганчы Рабиганың әле татар дөньясында хитка әйләнәчәк «Һаман яратам»ны җырлыйсы бар. Шул көннән башлап ул Фәрит Хатипов язган һәр җырны беренче булып җырлап караучы. Аннары гына аларны Илһам Шакиров, Фидан Гафаров кебек җырчылар алып китә торыр.

Ире язган 700 җыр арасыннан Рабига ханым «Моңлану» (Фәннур Сафин сүзләре) җырын аерым бер ярату белән ярата икән. Фәрит Хатипов үзе «Һаман яратам»ны (Зөлфәт сүзләре) йөрәк түрендә саклый. Ул җыр авторны баетырга тиеш иде. Мексика кызы Консуэло Веласкес бер мәртәбә үбешеп тә карамаган килеш иҗат иткән «Бесамо мучо» («Үп мине») дигән җыр, әнә, 120 телгә тәрҗемә ителеп, авторын гомер буе рәхәт яшәтерлек гонорар китереп торган. Фәрит Хатиповның җырларын рәхмәткә алып китеп торалар. Хәер, мин килгән көнне бер җырчы егетнең өч мең акча биреп китүенә хәйраннар калып утырган көне иде. (Җырчыларның табышы, яшәү рәвеше белән чагыштырганда – көлке сумма, әлбәттә.) Ул үзе исә гаиләсен яшәтерлек әҗерне баян тартып таба: «Менә илле ел күтәреп йөрим инде шушы потлы баяннарны. Монысы бишенчесе!»

Бишесен дә үзе сатып алганын беләм. Югыйсә кыйммәтле уен коралы аңа халыкка хезмәт итү өчен кирәк. Рабиганың, Филармония кризис кичергән елларда пенсиягә озатылган җырчының, күлмәкләре дә үз хисабына тегелгән. Хәер, алар инде хәзер шкафка бикләнгән. Хәтер менә альбомнарда. Анда Рабига Сибгатуллина дәрәҗәле, кадерле һәм үзен сөйгән кешеләр арасында. «Пенсиягә озатылуның» үз тарихы бардыр. Югыйсә яше әле дә җырлый торган.

– Рабига кышкы юлларда йөреп, ачык һавада җырлап өзлекте. Өйдә тора башлагач, тавышы элеккедән дә җетерәк булып ачылып киткән иде. Сәламәтлеге какшады бәгырькәемнең. – Бу сүзләрдә күпме наз, күпме кайгырту! – Кеше түгел, баяннар да туза бит. Әле бер баяным элекке Советлар Союзын әйләнеп, ярты елдан соң гына кулыма кайтты. Багажны ялгыш озатканнар.

Баян табыла ул. Җыр да табыла. Язылмый торганда музыка төшемә кереп уята. Уйнап та карамаган килеш ноталарын кәгазьгә төшереп куям.

– Димәк, иң мөһиме илһамны һәм бер-береңне югалтмау! Инде алтын туйны, иҗатта да алтын дәверне котәбез!

КАЯ БАСКАНЫҢНЫ КАРАП ЙӨР!
БУ КИҢӘШНЕ ЕШ ИШЕТӘБЕЗ. ТИК МЕНӘ КАРАП ЙӨРЕРГӘ ОНЫТАБЫЗ. БЕР АШЫГЫЧ АДЫМНЫҢ, КАУДАРЛАНУНЫҢ НӘТИҖӘСЕ, АЙ-ҺАЙ, ҮКЕНЕЧЛЕ БУЛА.

Асия ГАЛИУЛЛИНА

САКЛАНГАННЫ САКЛАРМЫН



Кадрияне күреп белмим. Әмма күреп белсәм, аны һичшиксез кисәткән булыр идем. Кайнап кына чыккан чәйгүнне плитәдән алганда сак бул, кеше өстеннән йөртмә, ялгыш төшереп җибәрә күрмә, дип. Шулай бәйләнергә, хәвеф ихтималын алдан күрергә гадәтләнгәнмен.

Кадрия менә төшереп җибәргән чәйгүнне. Үз аягына! Әле ике айлап йөрисем бар дип йөргән җирдән көмәнле хатынның тулгагы башланган. Көчле авыртуга организмның җавабы инде бу. Баулыдан авылга «Ашыгыч ярдәм» машинасы тиз килеп җиткән үзе. Әмма Баулы табиблары аяклары коточкыч пешкән яшь хатынга фәкать Казан табиблары гына ярдәм итә алыр дип уйлагангамы, әллә сабыйларга әле дөньяга аваз салырга иртәрәк дип тапкангамы, әллә кайчандыр көчле медицина бар дип саналган Баулының бу җәһәттән егәре бетеп киткәнгәме, җаваплылыкны Казан табибларына йөклиләр. Тулгакны басып тору чаралары күрелүгә Кадрияне 380 чакрымлык юлга чыгарып җибәрәләр. Бармак кына пешсә дә, уаланасың. Озын юлга, сызлануга ничек түзгәндер ул хатын?! Анысы – бер хәл. Туам дип юлга кузгалган бала ничек тыелып торгандыр?!

РКБ хастаханәсенә имин барып җитәләр. Тулгак яңадан башлана. Ананың аяклары чи җәрәхәт бит. Димәк, үзе бәбили дә алмый. Ярып алалар. Дөньяга ике игез малай аваз сала. Авырлыклары бер килодан ерак китмәгән балалар ана карынынннан кювезга күчерелә. Алар шунда түл җыярга, тиешле нормага кадәр үсәргә тиеш. Әйдә үссеннәр, аларның әле бүтән хәсрәте юк. Кадриянең генә хәле мөшкел. Балалардан ике-өч адымда гына иркенләп савыгасы да бит.
Юк, ярамый. Өеңә кайтып дәвалан, диләр. Сөт төшмәсенгә шатырдатып бәйләнгән күкрәкләре башта бераз сызлагандыр инде. Хәзер ул яктан тыныч. Корсактагы җөе дә ялганып килә. Аяклар гына менә бик әкрен төзәлә. Әле шул килеш тә Баулы–Казан арасын тагын үтәргә әзер дә ул. Тик менә табибларның: «Җәрәхәтле аяклар белән килеп тә йөрмә, балалар янына барыбер кертмибез», – дигән сүзләре тыеп тора.

Ахыры хәерле булсын. Түзәргә булгач, түзәргә инде. Кадриянең өлкән улы, дүрт яшьлек Самат, Замир белән Закирны (малайларның исемнәре бар инде) бик тилмереп көтә. Чанага курчаклар – «энекәшләрен» утыртып көннәр буе тартып йөри. Энекәшләр өйгә кайткач башланыр әле мәшәкатьнең әнигә дә, әтигә дә, әбигә дә, абыйга да җитә торганы. Әле аларның имезлеккә калган сабыйларга өй борынча сөт эзләп йөдәр көннәре алда. Авылда сабыйлар өчен «Сөт кухнялары» юк бит ул. Сыер асраучысы да берән-сәрән генә. Сыер сөтенә чыга торган диатезны, күкрәк сөте имеп үсмәгән балаларның чирләшкәрәк булуын да искәртсәң, бу гаиләгә Алла ярдәм бирсен, дими хәлең юк. Барысына да шул ашыгу гаепле. «Ашыккан ашка пешкән» дигән теге хәерсез мәкаль искә төшә дә тора.

Алай да барысын да яхшыга юрыйк әле. Ни дисәң дә, бер нигездә өч малай үсәргә тора бит әле!

Бәхеттә адашасыгыз, түгеләсегез, сибеләсегез киләме? Әллә инде җылы сүзгә, якты хискә сусаган мәлегезме? Сагынасызмы, саргаясызмы?.. Юк, илгизәк күңелегезне алгысытып, рәхәт бер халәттә күктә очарсыз, хыялларга тотынып чабарсыз, бәлки? Нурия Измайлова шигырьләрен укыгыз әле...



Нурия
ИЗМАЙЛОВА

МӘХӘББӘТЕМ – БУРАН...

Адашкан

Ашыгулар ялгышуга була.
Юк шул минем сабыр канатым...
Ялгышларым – урман,
язмышларым – буран,
Йөгерә-йөгерә кереп адаштым.
Ашкынулар үкенечкә була.
Ашкыну ул – минем канатым!
Үкенечләр – урман, өметләрем –
буран,
Көлә-көлә кереп адаштым.
Шашынулар һәлакәткә була.
Һай, мин сине шашып яраттым!
Күңелең – серле урман,
мәхәббәтем – буран,
Җырлый-җырлый кереп адаштым...

Урман – моңлы, буран шомлы була.
Әй, шуларны бигрәк яратам!
Юлым – кара урман йә ак буран,
Хыялларым шунда адашкан.
Мин – бәхетле, буран ера-ера,
Хыялларга тотынып чабалсам!
Мин – бәхетсез,
гомеремнең бер көнен
Ашкынусыз яшәп карасам.
Мин бәхетле –
гомергә бер булсын, –
Урман-күңелеңә багалсам...
Рәхмәт, усал буран, – горур иттең,
Рәхмәт, моңлы урман, –
җыр өйрәттең,
Мин бәхетсез, җырлый алмасам.
Мин бәхетле, егылып калмасам,
Мин бәхетле, ялгышлардан туган
Язмышларны җиңеп баралсам.
Китмәм, ахры,
шушы язмышымнан –
Мин бит бәхетем белән адашкан!
Моңлы урманымны – буш яланга,
Буранымны җилгә алмашмам.

* * *

Җыр шәп була, шәп җирендә бетсә,
– Тагын, тагын җырла! – дисәләр.

Төш шәп була, инде уянгач та,
Төшнең дәвамында йөрсәләр.

Кунаклар шәп булса, хушлашканда,
– Калыр идем монда! – дип тора.
Алар бизеп һәм биздереп китми,
Сагындыра алар, көттерә.

...Мин шәп кунак булсам иде
җирдә,
Яки – шәп җыр.
Һич булмаса – бер шәп төш кенә...

Хатын-кыз чак

Күңелләрем уйнап тора –
Бик алгысыган чагым...
Җылы сүзгә, якты хискә,
Назга сусаган чагым!..

Күңелләрем сыкрап тора –
Нечкәреп җиткән чагым.
Бик авыр сүз күтәрсәм дә,
Өзелеп китәр чагым!..

Күңелләрем сызлап тора –
Җанның яралы чагы:
Текә таудай рухның, егылып,
Нидер ялварыр чагы...

* * *

Күңелем тулы сагыш –
Шуңа күңлем киң.
Тик юк кара кайгым –
Соң, гашыйк ич мин!

Күңелемдә моң тулы –
Шуңа күңлем киң.
Тик күз яшем татлы –
Соң, гашыйк ич мин!

Күңелемдә сер тулы –
Шуңа күңлем киң.
Тик мәкер юк анда –
Соң, гашыйк ич мин!

Кемгә ярдәм кирәк? –
Һәрчак күңлем киң.
Мин – бик әйбәт кеше –
Соң, гашыйк ич мин!

Авылда соңгы кич

Йөгрә-йөгрә судан кайткан чакта,
Чиләгемдә суым чайпалды...
Ай төште дә чумды чиләгемә –
Күңелем минем шуңа таң калды...
Ай бии дә бии сикреп-сикреп,
И шатлана, итә тантана!
«Дусларны мин оныта белмим, –
дидер, –
Таныйм сине судан кайтканда!
Син ташлама мине ятларга!»

Ә мин аңа бер сүз әйтәлмәдем...
Баскан җирем куйды чайкалып...
Китеп булса икән туган яктан
Чемоданга тулган ай салып!..
Әй, түгелде суым! Ай күмелде...
Күңлем күле тулды, айкалды!
Тугрылык һәм хыянәткә шаһит,
Сарыларга сабышып, ай калды...
Ятка калды... Судан кайткан чакта
Чиләкләрем шуңа чайпалды...

Соңгы хат

Бәхет өчен алтын таулар
Кирәк микән, кирәк микән? –
Сезнең яктан ай туса да,
Мин бит синнән хатлар көтәм.
Дулкын-дулкын хат юллары –
Бу бәхеттән бөгеләм инде.
Дулкын саен – синең күзләр –
Түгеләм инде, сибеләм инде!..
...Ә бу хатта – сукыр күзләр,
Кыеп ала кылыч-сүзләр:
«Ант бирмәгән, ант бозмаган,
Кичер, – диләр, – оныт!» – диләр!
Утлар төрттең, сулар сиптең,
Җаннарымны җансыз иттең.
Юк, онытмам, гафу итмәм,
Тик ант итәм: хатлар көтмәм...
Дулкын-дулкын зәңгәр юллар –
Соңгы кат бу, соңгы кат бу.
Үткәннәрдән, көткәннәрдән
Соңгы хат бу, соңгы хат бу...
Соңгы хат бу, соңгы хат бу.

Дөнья нигә киң икән?!

Әнкәй әйтте: «Җиләк җыйсаң,
Бер җирдән җый тырышып.
Алан сайлап урман чапсаң,
Буп-буш кайтыр тырысың».
Тик – кайсы алан минеке?
Эзлим, сайлыйм йөгереп.
Ә кояшны берәү диләр,
Берәү диләр гомерең.
Яңа кояш юллап йөрсәң,
Бәхетең иртә тузар...
...Ах, белмисез, таң атканда
Шаулап уза поездлар!
Көннең чыгышларынамы,
Әллә баешларына? –
Кулым болгап йөгереп чыгам
Поезд тавышларына!
– Тукта! Тукта!
– Китәм! Тотма!
Ах, илгизәк, ах, күңел!..
Тик: «Исәргә – көн узар», – дип
Әйтергә генә җиңел:
Туган йортның чирәмнәрен
Үксеп эзлим төшемдә...
Ә уята поезд тавышы! –
Нәрсә җитми кешегә?..
Сагынамын, саргаямын,
Кем гаепле, кем икән?
...Нигә шулай күп соң юллар,
Дөнья нигә киң икән?!
Ә сагынмый, саргаймый да,
Саргаймый да, сайланмый да,
Сайланмый да, эзләнми дә,
Ялгышмый да, төзәлми дә,
Яшәү мөмкинме икән?..

Рәхмәт сиңа

Яшерен янарга өйрәттең,
Хатлар ягарга өйрәттең,
Җырлар язарга өйрәттең,
Гөлләргә шигырь сөйләттең...
Оялчанлыкка өйрәттең,
Олыҗанлыкка өйрәттең.
Өйрәттең матур күренергә,
Өйрәттең очып йөрергә,
Тотынырга яшеннәргә
Һәм биек, биек меңәргә!
Күккә мендем. Рәхмәт сиңа!
Хисне уч белән болгаттың,
Хыял сарайларын ваттың.
Шигъриятне ботарлаттың,
Күкләремне каһәрләттең!..
Төштем җиргә... Ләкин мин бит,
Мин бит күктә очкан идем –
Үз-үземнән биек мендем!
Биеклекнең серен белдем...
Һәм һичкайчан үз-үземнән
Түбән була алмамын мин.
Менә шуңа – рәхмәт сиңа!

Сөеклемнең исеме

Карамагыз бер генәмә!
Әйтмәгез исемнәрен!
Ул сандугачлар ярата,
Сандугач, кит син, бәгърем!
Ул йөргән урамнарга да
Кертмәс идем һичкемне...
...Ах, көнләде, язмыш-явыз,
Минем көнчел гыйшкымны!
«Ул күргән офыкларны да
Күрмәсен» дигән микән?
Мин көнләгән сандугачны
Кемнәргә биргән икән?..

Тамчы суга зар елаган
Чүл юлчысы төсле мин –
Кемнәр күрә сөеклемне,
Кемнәр ача ишеген?
Кемнең исендә? – Әйтегез –
Бик сагындым исемен!
...Тик һаман да көндәше мин
Исемен әйткән кешенең...

Яшәү-сагыну

Сагынам җирнең
китәр-китмәс карын,
Йөрәгемнең җитәр-җитмәс язын.
Бәхетемнең сагынам оялчанын,
Көләр-көлмәс кенә торган чагын.
Янар-янмас ак балкышны сагынам
Дәшәр-дәшмәс күзләр ягыннан...
Ал хыялның гади чынбарлыкка
Ашар-ашмас чагын сагынам.
Күпме яңгыр яуган болытларсыз
Һәм төтенсез утлар ягылган!..
Болыт салкын, төтен ачы диеп
Белер-белмәс чакны сагынам.
Минем гомер күпме кабатланган,
Минем уйлар күпме язылган!
Бу дөньяның ачылмаган китап,
Серле утрау чагын сагынам.
...Ә дөньяның кайчан ачылганы,
Кайчан сагынмаслык чагы бар?!

Кеше турында кешегә

Ямьсез күреп, ямьсез дия күрмә –
Һәр чәчәкнең аның төсе бар.
Сөйкемсез сөяк буламы? –
Һәркемнең әнисе бар.

Бәләкәйне бәләкәй ди күрмә –
Һәр җимешнең аның төше бар.
Кеше бәләкәй буламы? –
Кешенең әнисе бар.

Баласына сүз тидермәс өчен,
Газиз җанын бирер кеше бар.
Бер бәләкәй генә адәмгә дә
Берәүләрнең таудай хисе бар!..
«Мәрхәмәтле бул балама!» – диеп
Дога укып торган кеше бар.
Кимсетә күрмә кешене –
Кешенең әнисе бар!



Айдар ХӘЛИМ

КАЙТАРЫЛУ СЕРЕ

(Хикәя)

Мин Гали абзабызның авылдан чыгып ычкынган көнен анык хәтерлим. Кайчан, ничек, нинди вакыйгалардан соң – бөтенесе хәтергә уелган.

Абзабыз вафат. Моннан ун ел чамасы элек бакыйга китеп барды. Ташкенттан алтмыш чакрым чамасындагы Ахангаран дигән зур кышлакның кызыл комлы зиратында ята ул. Мин аның дәфененә баруым хакында «Урта Азиядәге уртакларымда» дип язган да идем.

Абзам темасына әйләнеп кайтуымның бүтән сәбәбе бар. Кайчанрак, ничегрәк чыгып качты соң әле ул сугыштан соңгы ач-ялангач, әмма җырлы-моңлы авылдан, колхоз кешесенә паспорт бирү, авылдан чыгу тыелган заманда? Һәрхәлдә, мин моны үземнең исәпләвемчә, 1948 елның кышыннан да иртәрәк булмагандыр дип уйлыйм. Ул чакта паспортыңны учлап, туры айгырлы тарантас үрәчәсеннән аякларыңны салындырып, гомеребез булса, кайчан да бер кайтырбыз әле дип, артыңа да борылып карамыйча, илдән чыгып китү турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Гомер иткән чокырыңнан башыңны да чыгарып карый алмаган сталинчыл заманда, кешелексез заманда авылдан чыгып таюның нинди әмәлен тапкандыр ул!

Бездә, минем якын-тирәмдә, бу чор нечкәлекләрен аңлатырлык кеше дә калмады бугай инде. Әмма мин бу юлы сөйләргә җыенган очрак абзабызны эчке сызу-сыкранудан туктап, юк, болай ярамый, мондый мал-колга хас түзем зынҗырын өзеп, ничек кенә булса да, илдән чыгып ычкынырга кирәк дигән хәлиткеч карарга китергән вакыйга булгандыр дип уйлый алам. Һәрхәлдә, вакыйганың миңа билгеле өлеше шуны раслый кебек.

Минем шул хакта сөйлисем, үзем күргәнне сурәтлисем килә. Мәктәптә укымыйм, укымасам да, күп нәрсәне хәтерли, бәяли башлаган чагым иде. 1948 елның җир өстенә туң төшә башлаган сентябрь төне булырга тиеш бу. Авыл кешесе белә: урак урылып, уңыш җыелып бетмәгән, җирләр сөрелеп җитмәгән, чәчеләсе көзге арышлар чәчелеп, табигатьнең, көмәненнән котылган ана кебек, җиңеләеп калып, җәйдән көзгә күчеп азапланган искиткеч серле мәле иде бу. Җитмәсә, Ай! Күк йөзендә тулган Ай!.. Җир өстендә – караңгы. Булса да булыр икән шундый каршылыклы кайтарылу: күк йөзе никадәр якты булган саен, җир йөзендә шулкадәр караңгы. Бер карасаң, ул караңгы да түгел, киресенчә, шундый алдаткыч якты, айлы караңгылыкта ат юлына ялгыш кына төшереп җибәргән йөзегеңне дә җиңел генә таба алырсың сыман. Күктә – җирдә караңгы булганы өчен якты, җирдә исә күктә якты булганы өчен генә караңгы диярсең.


Ә менә без эзләгәнебезне – караңгыда яктыны, яктыда караңгыны табарбызмы?

Безнең ул төнгә кереп барган кичебездә казларыбыз югалган иде.

Бу безнең – сугыш азагында – атасыз, үткән кыш ачлыгында уртанчы абзабыз вафат булып, биш җаннан дүрт җанга калган гаиләбез, бигрәк тә соңгы вакытларда гәүдәсе как сөяккә калган әнкәебез өчен фаҗига иде. Бәлаләр безгә, хәтердә калуынча, гел кышын килә торды. Әйе, үткән кышта бишенче сыйныфта укып йөргән һәм ачлыктан шешенгән абзам Нияз мәктәптән кайтты, эчен тотып аунады-аунады да, мәңгелеккә күзен йомды. Ул тешләрен шулкадәр кысып җан биргән, уртларын канаткан иде, мәрхүмкәй. Аны кәфенгә төрер алдыннан тешләрен ачтыра, авызын сыландыра алмаган килеш күмделәр. Шул ук кыштан язга чыгып барганда, бозаулый алмыйча, сыерыбыз зыянлады. Без малсыз калдык. Күпмедер вакыттан соң тагын кайгы: әнкәебез ахирәте Садыйка түтки белән Өршәкбаш-Карамалы базарына киткән иде. Гали абзабыз, инде егет кыяфәтенә кергән үсмер, кичен дус кызлары-егетләре өчен аулак җыены үткәрде. Алар кара-каршы басып, мине аптыраштa калдырып, бер-берсенә «кода-кодача» диешә-диешә, бик озак әйләнеп биеделәр. Шунда ишеткән бер җыр әле булса хәтеремдә: Сандугачлар да сайрамый, / Сандугачлар да сабыр. / Шулай янса яшь йөрәгем / Кылычтан нечкә калыр...

Йоклап киткәнмен. Бервакыт, янәшәмдә барыбыз суккан бер палас ябынып йоклаган өлкән бертуган абзаларымның, җырдагыча, «кылычтан нечкә калып», йөрәк ярып елаган тавышларыннан уянып киттем. Бозы суланып утырган тәрәзә туңы аша таң сарысы саркыла. Нindидер куркыныч күмәк ялгызлык, шом һәм зарелаш. Күз алдыгызга китерегез: балигъ булмаган бала кара төндә салкын палас астында абзаларының бертавыштан үкереп елауларыннан иңкә-миңкә уянсын әле. Тагын ни булган? Әткәсез калдык. Абзасыз-тугансыз калдык. Сыерсыз калдык. Ипи-бәрәңге юк, кием-салым юк. Әллә әнкәсез дә калганбызмы? Аларга кушылып, мин дә елый башладым. Баксаң, абзарыбыз түбәсен тишеп, бүреләр өч сарыгыбызны, ике кәҗәбезне бугазлап чыкканнар икән. Бүреләр, тупсабызга утырып, инде үзебезне кötәләрдер, дип, тышка чыгарга да куркабыз...

Әле күптән түгел, былтыр, урак кызып кына барганда, Гали абзабызның башын чак төрмәгә тыкмый калдылар. Дусты Әхнәф белән ындыр табагына көлтә ташыган җирләреннән өйләренә кайтканда аларны районнан килгән упалнамуч белән милитсия туктата, фурманнарына җәелгән чыпта төбеннән көлтәдән коелып калган ике-өч уч ашлык таба. Авылда шау-шу купты. Бурлар тотканнар!.. Тентегәннәр!.. Тапканнар!.. Өйдәге шомлы давылны инде әйтеп тә торасы юк. Егет булып җитешкән бердәнбер улыңны прқарулга алып китсеннәр әле. Әнкәй, мискинә, коелыплар төште. Ул, авыл сәвите «липутаты», фронтта үлгән иренең пахарун кәгазен күтәреп, тикшерүчеләргә чапты. Ничекләр ышандырган-



Рәсем: Наталья Васильева

Халык сөйләме: упалнамуч – уполномоченный; язгы-җәйге кыр эшләре чорында район җитәкчелегенең колхозларга җибәргән махсус вәкиле; фурман – фургон, печән, агач, көлтә ташый торган озын арба; липутат – депутат.

дыр, авыл советы яклап калдымы, эшне зурга җибәрмәделәр. Гауга шуның белән колаксыз тынды. Әмма абзыйның, үкси-үкси, йодрыгы белән өстәл төйгәнен хәтерлим: «Калмыйм мин монда!.. Башымны ашыйлар минем монда!..»

Һәм менә тагын яңа кайгы: бу төндә күз карасы кебек карап торган казларыбыз өйгә кайтмады. Алты каз бәбкәбез. Аналары белән җиде баш. Аларны бәбкә дип тә булмый, алар инде, сугым чорына керә барып, ит утырткаsuccessfully каннар, канатларын кага-кага һавада оча, аннан авыр гәүдәләре белән гөпелдәп җиргә төшә дә башлаганнар иде. Каян гына эзләмәдек без аларны: Җидегән тугаеннан да, Кырлыган буеннан да, Өязе үзәненнән дә, авыл буйлап та. Юклар тек юклар. Җитмәсә, җирдәге бар нәрсәне серле караңгыга күмеп, ай яктырта. Көтелмәгән казадан аптыраган-алҗыган, үзенә урын тапмыйча өзгәләнгән әнкәбез, үзе дә бәбкәләрен иярткән ана каз кебек, ай-вайга куймыйча, безне бөтенләй кире якка – авылның аскы очындагы Качаган тугае ягына алып китте. Өязенең Хафаса әбиләр янындагы күперенә җитәрәк, әллә кайлардан га-га-га тавышлары чыгарып оя-оя казлар каршылады. Әнкәй, үзләренеке дип куанып, күпердән казларын чакыра башлады:

– Гәз-гәз-гәз!..

Казлар каңгылдап җавап бирделәр. Әмма алар безнеке түгел икән шул. Тавышлары гына безнеке кебек иде. Кызык кайтарыла: тавышлары безнең казларныкы, әмма үзләре безнеке түгел. Гадәттә, буявы табылса, канатларына буяудан төртке төрткән, буявы-фәләне булмаса, чәлтерләренә чүпрәк бәйләгән бәбкәләрне әнкәй төнге караңгылыкта ак боз кисәкләре сыман Өязе суында йөзгән казларның, канатларын да, аякларындагы чүпрәкләрен дә күрмичә, үзенекеләр түгеллегенә инана алмагач, ачуы кабарып, күңел хакы өчен аларны ничек кенә булса да танырга, үзенеке итәргә тырышып газаплана иде. Элегрәк инде тән-тиякләре тазарып, бәбкәдән каз рәвешенә үтеп, каз малы, гадәттә, эттән, аттан кала иң акыллы һәм хәйләкәр мал булганлыктан, ияләрен тавышыннан танып, шундук очына-очына килеп җитә торганнар иде. Бу юлы алай булмады, чөнки, әйткәнемчә, бирегелеләр безнең казларга кода-кодагый да түгелләр иде.

Күңеле ярсыган әнкәй, түземе бетеп, безне әллә кайлардан агарып күренгән Акъяр тарафларына алып китте. Гомеребездә диярлек малыбыз түгел, үз аягыбыз да басмаган кире як – Акъяр тавына килеп җиттек тә, балалары суга төшкән кеше кебек, аптырап калдык: казларыбыз да күренми, ары баруыбызның мәгънәсе дә калмаган иде. Без кайтыр якка борылдык.

Каңгыл-коңгыл килеп күпер төбендә безне тагын баягы казлар каршылады. Мин үз гомеремдә беренче тапкыр шундый матурлык күрдем: Хафаса карчык күпере төбендәге карт өянкеләр айның сирпелеп төшкән көмеш яктысында аксакаллар кебек оеп калганнар да, суына барган төн һавасын зеңгел-зеңгел китереп, мандолинада уйнап утыралар. Бу газап та, ләззәт тә иде. Әйе, ышанасызмы, мин, киндер ыштанлы, яланаяклы алты яшьлек малай, ике абзам һәм әнкәм-бәгърем арасында казлар эзләвемне онытып, мандолиналарның оркестр моңнарын тыңлый идем! Ә казлар ай нуры ташкыныннан күзен югалткан җир өстендә караңгыланып, сукыраеп калган төнге тере һаваны ертып, суга салынган май йомарлаклары кебек җитди кыяфәттә, ашыкмыйча, үз дәрәҗәләрен белеп, вәкарь белән генә каңгылдап-сөйләшкәләп йөзәләр дә йөзәләр... Өязе ярларына кунаклаган бөдрә таллар, карт өянкеләр, елганың балыклары да үтәли күренеп торгандай дулкыннарында кайтарылганнар. Өянке шәүләләре арасындагы су көзгесендә казларның аккоштай сыннары да. Бөгәл муенлы гәүдәләре дә. Тере казлар һәм шунда ук шәүләләре кайтарылган казлар!.. Менә кызык!.. Моның сере нәрсәдә? Югалтыштамы, әллә табыштамы? Йомшак кына җил исеп куюга дулкыннарның бу очтагы вак чемeteме аргы очтагы чемeтеменә барып бәрелә, алар өсте-өстенә менеп шадралана, җил тына, нурдан күпер салынып, теге чеметемнәр бер-берсеннән яктылык алып ераклаша башлый... Күз алдыбызда кайтарылган бу матурлык югалтуларыбыз белән дә безнеке иде!.. Тукта, бәлки әле югалтып өлгермәгәнбездер? Әнкәй дә, шушы серне аңларга теләгәндәй, ярның упкындай текәсенә килде һәм кубыз зеңләгән тавышлар чыгарып, янә чакыра башлады:

– Гәз-гәз-гәз!..

Тере казлар да, аларның сурәтләре һәм кыңгыраулары да елгада кайтарыла, әмма берсе дә безнеке түгел иде.

– Гәз-гәз-гәз!.. – диде әнкәй тагын да ярсый төшеп.

Казларның үзләре, сурәтләре һәм каңгылдаулары һаман елгада кайтарыла, әмма алар бу юлы да безнеке түгел иде.

Елга көзгесендә без үзебез дә кайтарыла идек. Болар без дә, түгел дә идек.

Ай нурларының җирне биләгән караңгылыгына чумып, өйгә таба юнәлдек.

Кайтуыбызга, өйнең эчен сөремле төтен баскан иде.

Казлар белән мавыгып, өебездән чыгып киткәндә без өстәл өстендәге җиделе лампабызны сүндерергә йә булмаса аны бер читкәрәк этәреп куярга онытканбыз икән. Лампа куыгыннан чыккан очкыннанмы, әллә филтә өстендәге ялкыннан кызып китепме, Гали абзыйның бераз гына югарыдарак – чөйдә эленеп торган бердәнбер пинжәгенә ут капкан, һәм аның сул җиңе без кайтып кергәндә көйрәп, көлгә калган иде.

Беркем бернәрсә эндәшмәде.

– Монда калмыйм! – дип сукты йодрыгы белән имән өстәлгә абзый. – Калмыйк, инәй!.. Уф-алла арбаңны майла!..

Башкасын мин хәтерләмим.

Бу аның авылдан чыгып китәр өчен соңгы чик булгандыр. Күрәсең, казларыбыз югалган төн аны өнсез, пинжәген җиңсез, үзен илсез итте. Соңыннан төшенүемчә, шушындый кара төннәрдә янган пинжәк җиңнәре һәр татар авылын корыткан икән. Кансыз хакимият кылган гөнаһлар халыкта югалган сугым казлары булып кайтарылган.

Безгә, ниһаять, айнып, Өязе дулкыннарында кайтарылган ак казлар кебек, изгелектә кайтарыласы иде.



Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

УЛ БИТ КИЧӘ ИДЕ

(Хикәя)

Телефон трубкасының теге ягындагы елак аваз кырт өзелде. Хәер, Диләрә моңа артык гаҗәпләнмәде дә, ахирәтенең гадәтен белә ләбаса: аһ-зарына ияреп, беркадәр вакыттан соң үзе дә ишектә пәйда булачак. Зәкия алай юксындырып тормый, яңа кием алса да, кибеттә йөрергә иптәш кирәксә дә, иреннән зарланырга теләсә дә, ялт итеп килә дә җитә.

Диләрә үзалдына елмаеп, юеш чәчләренә урап куйган зәңгәр сөлгене сүтеп ташлады. Душ кабинасыннан чыкканда өстенә шактый искергән йомшак халатын элгән иде, аны җәһәт кенә ак җирлеккә сары ромашкалар төшкән кыска җиңле күлмәккә алыштырып куйды. Зәкия очрашкан саен:

– И Диләрәкәем, үзеңне гел курчак урынына карап кына торасың, бездән юк инде, юк. Эштән кайтсаң, өстән халат, баштан яулык төшми, ял көннәрендә чәч тә таралмаган чаклар була, малай, – дип, Диләрәнең чәчен-башын, күлмәген мактап, ахирәтенең күңеленә сары май сызып сала белә бит, шуннан соң аны ничек инде иске халаттан каршылыйсың, ди?!

Хатын, кияү каршыларга җыенгандай, бизәнеп-төзәнеп бетергән генә иде, ишектә кыңгырау чыңы яңгырады.

– Бер көн тормас идем шуның белән, бер генә көнкәйләр дә тормас идем! – Зәкиянең тавышы ике кат ишек арасындагы тар гына аралыкка сыймыйча, подъезд баскычыннан аскы катларга тәгәрәде. – Ир белән торып кем рәхәт күргән, ә? Диләрәкәем, илләмнәр дөрес яшисең син, малай, илләмнәр дөрес яшисең!

Коридорда Зәкиянең билсез гәүдәсе күренүгә, кәнәфидә үз көенә мырлап яткан Актәпи җәһәт кенә идәнгә сикерде, уттан качкандай җитезлек белән диван артына кереп тә посты. Күмәч кебек кабарынкы куллы, мимылдап торган гәүдәле бу хатынны песекәй өнәп бетерми иде. Үзенең язылмаган кануны диярсең: Зәкия килүгә, тота да шулай, гаебе бар шикелле, берәр почмакка шылу җаен гына карый.

Зәкия җылы курткасын салып элде, ялтырап торган кара сумкасын тумбочка өстенә куйды. Кайчандыр сарыга буятып, хәзер инде ала-кола төскә кергән, «химия»се чыгып барган кыска чәчен бармаклары белән тарагандай итте. Аның шактый мул гәүдәсе зал

ягына үткәндә, Диләрәнең бер бүлмәле фатиры тагын да кечерәеп, тараеп калгандай тоелды.

– Йә, бу юлы нәрсә инде? – Ишек яңагына сөялеп, үз-үзен кочаклап торган Диләрә елмаюын яшерергә тырышып, йөзенә борчулы кыяфәт чыгарды.

– Нәрсә, нәрсә... «Бүген өйгә кайтасы, күземә күренәсе булма!» – дип, ишекне шапылдатып бикләп калды... Вәт хайван, ә! Малай, синдә генә кунармын инде, яме. Үземне мыскыл иттереп, кайтып йөримме соң?! – Зәкия диван почмагында яткан пультны үрелеп алды, телевизорны кабызып җибәрде.

– Ни сабыр Динарыңны да чыгырыннан чыгара алгач... Хәзер кеше төсле итеп сөйлә, бая телефоннан берни дә аңламадым.

Диләрә бар көченә кычкырган телевизорның тавышын киметте, аякларын бөкләп, ахирәте янына менеп утырды.

– Маена чыдый алмый, шуңа котыра... – Зәкия мышык-мышык килеп еларга ук тотынды. – Базарда йөргәнемә ачуы чыккан... Йөрсә, шулпа утыртып чыгып киттем, бәрәңге-кишерен турап калдырдым, шул әзерне пешереп бетер дә аша бит инде. Обедларга кайтып җитәм дигән ием дә, базарга керсәң, сәгать кенә уйлап йөрисеңмени... Телефонына акча салырга кушкан ие, ул да онытылган, шуңа җене купкандыр инде. Малай, базар бикләнгәнче йөргәнмен! – Зәкия юан ботына учы белән шапылдатып алды да урыныннан кыймылдап, сумкасы янына ашыкты. – Алган әйбер дә булмады, бер җүнле нәрсә калмаган... Чыккан-чыккан дип кенә бер юка күлмәк алган булдым. Кая, рәтләп киеп карыйм әле. – Зәкия үтә күренмәле пакетны култык астына кыстырып, ялт кына ванна бүлмәсенә кереп югалды.

Диләрә кухняга кереп, чәйнеккә су агызды, аны газга утырткач, суыткыч ишеген ачып, бертын ярымбушлыкка текәлеп торды. Иртәсен-кичен кофе, ипи, сыр белән тамак ялгарга гадәтләнгән ялгыз хатынның сыгылып торырлык өстәл нигъмәтләре юк иде. Шулай да, чынлап еласаң, сукыр күздән яшь чыга дигәндәй, суыткычта өч йомырка, бер-ике помидор табылды. Шуларны кыздырып йөргән арада Зәкиянең көзге тирәсеннән:

– И-их! Менә бу майларның әзрәген генә сиңа бирергә! Күпме әйтәм үземә, ашавыңны кыс, Зәкия, әнә бит Диләрә, кырык яшендә дә кызлар кебек, дим... Юк, малай, булмагач булмый, әй. Ну күлмәге матур, чукынган! – дип шәрран ярып сөйләнгәне ишетелде.

Диләрә түзмәде, кухня ишегеннән башын тыгып, Зәкиянең яңа күлмәгенә күз ташлады. Ахирәте ялтыравык озын күлмәкне тегеләй-болай тарткалап, бил тирәсеннән бүселеп чыккан җирләрен үз күзеннән яшерергә маташа, тик нечкә билле җырчыларга гына атап тегелгәндәй әрфия күлмәк, хатынның тәненә бөтенләй сыланып бетеп, аны әллә нинди мәзәк кыяфәттә күрсәтә иде.

– Моны киям дисәң, точно диетага утырасың! – диде туры сүзле Диләрә артык төчеләнмичә. – Йә кире илтеп тапшыр, йә егерме-утыз килога ябык!

– Килешми дисеңме? – Зәкия ирен читен тешләп, кашларын җыерып, көзгегә текәлде.

– Синеке түгел. – Диләрә ашыкмыйча гына йомырка тәбәсен тәлинкәләргә бүлеп салды. – Минем халатны ки дә ашарга чык.

– Әл-ләй, көн буе ашамаган бит мин, малай! Хәзер!

Өстәл тирәсендә сүз әлеге күлмәк темасын дәвам итеп, базарга, Зәкиянең ашалмыйча калган тавык шулпасына, аның хатын кадерен белмәгән холыксыз иренә барып ялганды.

– Яшьлегемне әрәм иттем шул юньсезгә. Мәктәптән үк озатышып йөреп, яратам дигән булып... Кем уйлаган аның шулай өйдән куып чыгарасын... – Зәкия ипи катысы белән тәлинкәсен сөрткән җиреннән кул аркасы белән күз төпләрен сыпырып алды. – Бүген кайтма, күземә күренмә ди шул! Соң, обедка дигән җирдән кичке алтыда кайтып кергәч ачуы да килгәндер инде... Менә шалтыратмый бит әле, мужыт мин баскыч төбендә катып утырамдыр, мужыт мин трамвай астына ташланганмындыр, аны уйлау юк! Шулай, хәзер Зәкия кирәкми! Зәкия ямьсез, Зәкия юан... Кая, ак маең юкмыни соң синең, бөтен ипиеңне коры килеш ашап бетерәм бит, малай!.. И-и, сиңа рәхәт, Диләрәкәем! Дөрес эшләдең Шәүкәтеңнән аерылып! Үзең баш, үзең түш булып яшисең! Ир өчен дип, иртә-кич ашарга әзерлисең юк, монда булдым, тегене алдым дип отчет бирәсең юк. Илләмнәр дөрес эшләдең!

Диләрә керфекләренең тибрәнеп куюын үзе генә сизде...

Зәкиягә диванга, үзенә идәнгә урын әзерләгәч, хатын утларны сүндерде, ахирәтенә тыныч йокы теләп, башын ялгыз мендәргә салды. «Сиңа рәхәт, дөрес эшләдең», – ди дусты. Дөресме, ялгызмы – Диләрә Шәүкәтне үзе җибәрде. Унбиш ел бергә яшәп, иренә ата булу бәхетен бүләк итә алмаганын аңлагач, үз теле белән әйтте. «Башканы тап, Шәүкәт, бәхетле булырга тырыш», – диде. Әйтте дә тилмереп, өзгәләнеп, иренең күзләренә текәлде: йөрәгеңне үз кулларың белән күкрәк читлегеннән каерып алу җиңелрәк түгел микән? Гаҗәп, ир гомер буе шул сүзләрне генә көтеп яшәгән диярсең. Шулкадәр гади, шулкадәр ихлас һәм... шулкадәр коточкыч килеп чыкты аларның аерылышуы. Диләрәнең аяк астында җир убылды, баш түбәсендә күк гөмбәзе чатнап ярылды. Өйдән әйберләрен төйнәп чыгып китүгә, Шәүкәт күрше урамдагы ялгыз хатын белән оя корды... Аларның бала җитәкләп узганнарын күрмәс өчен генә Диләрә үзәктәге фатирын шәһәрнең икенче очына алыштырды.

Ялгыз хатын ялгызлыкның ни дәрәҗәдә «рәхәт» икәнен үзе генә белә... Елар урында елмайган чаклары күп, бик күп аның. Күз яшьләреңне җиде ятлар

йә булмаса ахирәтең белән уртаклашу гына язмышларны өр-яңадан язарга мөмкинлек бирми шул...

Диләрә үзе турындагы уйларын читкә куып, Зәкия өчен борчылып куйды. Өйгә үк кертмәслек булгач, тавыш-гаугалары зурга киткәндер инде. Динар болай холыксыз түгел кебек иде юкса. Хәер, кешене белер өчен бер пот тоз ашау гына да җитмәстер шул... Иртәгә нишләп бетәрләр? Иртәме-соңмы, Зәкиягә барыбер үз бусагасын атлап керәсе булыр лабаса... Аларны уйлый-уйлый, Диләрә урынында кырыкка бөтерелде, күзенә йокы төшмәде, төн буе җәфаланып кына чыкты. Аның каравы, Зәкия урынга ятуга изрәп йоклап киткән иде, иртән Диләрә эндәшкәнгә генә күзен ачты.

– Инде дә тәмле итеп йокладым, малай, төш күрергә дә вакыт булмады! – Юынып, чәйләр эчеп алгач та Зәкия киерелде-сузылды, янә мендәргә баш төртеп маташты. Бераздан гына йөзенә борчылган кыяфәт чыгарып, торып утырды.

– Диләрәкәем, син дә минем белән бар әле, малай. Икәү кайтып керсәк, синең алда кычкырып маташмас. Бер дә ачуланышасы килеп тормый, әле бит күлмәкне дә күрсәтәсе бар...

Ни дисен инде Диләрә, ял көне, эшкә барасы юк, ахирәтенә ияреп китүдән башка чарасы калмады.

Тугыз катлы йорт подъездын домофон ачкычы белән кыю гына ачып керсә дә, лифттан төшеп, үз фатирының ишек төбенә якынлашкач, Зәкия күзгә күренеп кечерәеп киткәндәй булды, ачкычын кире кесәсенә салып куйды, икеләнеп кенә кыңгырау төймәсенә басты.

Эчке якта шактый көттереп кенә аяк тавышлары ишетелде. Шоколад төсендәге тимер ишек бөтен буена ачылып китте, Динарның майка-шортик кына кигән арык гәүдәсе пәйда булды. Ял көннәрендә кырынып тормаган бугай: болай да ябык йөзе тагын да каралып, озынчаланып калган. Аяз күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзләре хатыннарга сораулы караш ташлады, ир Диләрә белән ияк кагып кына исәнләшкәндәй итте дә кашын җыерып Зәкиягә төбәлде:

– Мин сиңа ни дидем? Өйгә кертмим димәдемме?

Ахирәтенең янәшәдә булуы Зәкиягә ниндидер көч өстәде бугай, ул бер дә исе китмәгән тавыш белән чәтердәп җавап кайтарырга ашыкты:

– Алай димәдең, җаным. «Бүген кайтып күренмә!» – дидең!

– Ну? – Ир әле дә булса ике ахирәтне өйгә уздырырга ашыкмый иде.

– Нәрсә нулыйсың? Ул бит кичә иде, «бүген кайтма» дигәнең кичә иде. Ир сүзен тыңламый буламы? Ялгыз башым сыңар мендәрдә йокым йокы булмаса да, түздем, сүзеңне өстен калдырдым, кайтмадым. Ну анысы кичә иде! Кая, аркылы торма әле Диләрәне куркытып...

– Нишләп куркыйм, ди, син бигрәк, Зәкия! Динарының кулы алтын дип, сәгатемне төзәтергә алып килдем бит, борылып китмәм инде...

Бу сүзләрдән соң Динарга телсез калып кереп китүдән башка чара юк иде.

Өчәүләп гөрләшә-гөрләшә чәй эчкәч, Динар ә дигәнче Диләрәнең сәгать чылбырын рәтләп бирде. Ике ахирәт ике яктан ирнең уңганлыгын, сабырлыгын, кулыннан гөл тамуын кат-кат искәртә торгач, өйдәге киеренкелек тәмам эреп юкка чыкты. Зәкия тез өстеннән генә торган халатын киеп, диван култыксасына менеп утырды, йомшак куллары белән иренең тырпаеп торган калак сөякләрен сыйпый-сыйпый:

– Әй кичә талашып куйдык та, әйеме, әтисе! – дип бүлмә яңгыратып көлеп җибәрде.

– Кызып киткәндә әллә нәрсәләр әйтелә шул... – Динар, хатынының мут күзләренә текәлеп, гаепле кешедәй елмаеп куйды.

Диләрә бу икәү янында үзенең артык икәнен сизеп, тизрәк чыгып китү ягын карады.

Язны көтеп челтәрләнгән карны четердәтеп, сукмак буйлап ялгыз хатын атлый. Ашыгыр җире дә, көтеп торыр, куып чыгарыр, елатыр-юатыр кешесе дә юк аның. Зәкия әйтмешли, бүген нәрсә пешерим дип пошынасы да, соңга калдым дип хисап тотасы да юк. Һәр почмагыннан ялгызлык күзләре карап торган куышы һәм аның бар сагышын, бар күз яшен уртаклашучы мендәреннән гайре беркеме, берние юк. Ялгызлар күңелендәге дәрья суларыннан тирән хәсрәтне төнге тәрәзәдән баккан салкын ай күрсә генә инде... Ахирәте аның сылулыгына, зифа гәүдәсенә, килешле киемнәренә аһ итеп, «сиңа рәхәт, үзеңне генә кайгыртып яшисең», дип уфтана. Ап-ак туй күлмәге киеп, сөйгәненең култыгына сарылып, ак карда парлы эзләр калдырып атлаганда Диләрә шушындый «рәхәтлек» турында хыялланган идемени? Күлмәге һәм әйләнәтирә генә түгел, бар булмышы, өметләре, хыяллары ап-актан иде... Тик алар барысы да кичә иде, кичә иде... Сандык төбендә күз карасыдай кадерләп кенә саклаган туй күлмәге дә кершән аклыгын күптән югалтып, һәр җөенә сагыш төсе сарылды. Бер канаты каерылган кошның очарга талпынуын читтән кемдер кызганып, кемдер шаккатып яки... көнләшеп күзәтә... Ялгыз хатынның күләгәсе – аның ялгызлыгына ышыкланып атлаган ялган горурлыгы...

Диләрә кердели-чыктылы уйларын читкә куеп, башын калкытты да тирә-юньгә күз ташлады. Кичә генә юрган-юрган булып яткан кар катламы, яз кояшының нарасый елмаюына бил биреп, күгелҗемләнеп һәм челтәрләнеп калган да, үз аклыгы, яктылыгы белән елый-елый хушлашырга теләгәндәй, әле аннан, әле моннан моңлы гөрләвекләр булып йөгергән. Шулай, кичә һәм бүген арасында кешеләр дә, дөнья үзе дә кырыкмаса кырык төскә керергә сәләтле. Бары тик аклык белән өртелгән хыял һәм яшерен өмет кенә үз төсен җуймый икән...

2015 ел Казанда «Парклар һәм скверлар елы» дип игълан ителде. Шул уңайдан журнал битләрендә укучыларыбызны шәһәребез бакчалары һәм парклары белән таныштыру өчен яңа сәхифә ачып җибәрәбез. Ә таныштырыр, сезгә сөйләр мәгълүматлар бик күп.
2011 елда II социаль-мәдәни проектлар конкурсында ТР Милли музее тәкъдим иткән «Казан бакчалары һәм парклары» проекты «Экология» номинациясендә җиңүче булып танылды. Проект кысаларында ТР Милли музеенда XIX гасыр ахыры – XX гасырның беренче яртысындагы Казан бакчалары һәм парклары тасвирланган уникаль каталог тәкъдим ителде. Каталог Казанның тарихи мирасы белән танышырга мөмкинлек бирә. Анда Казан бакчалары һәм парклары турында кызыклы мәгълүмат һәм 200 дән артык фотоматериал тупланган, шуларның күбесе киң җәмәгатьчелеккә беренче тапкыр күрсәтелә.
Сәхифәне ТР Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.



КАЗАНДАГЫ





Беренче сәхифәдә сезне М. Горький исемендәге ял паркы – «Рус Швейцариясе» белән таныштырырбыз. Бу урынның исеме килеп чыгу белән бәйле ике фараз билгеле. Беренчесе Казан гимназиясе гимназисты Николай Панаев белән бәйле. Карамзинның «Рус сәяхәтчесе хатлары» китабы тәэсирендә, ул бу урыннарда беренче тапкыр булганнан соң, 1804 елда хикәя яза. Бу хикәядә үзе күргән искиткеч матур урыннар, шул гүзәллектән алган онытылмаслык тәэсирләрен дуслары белән дә уртаклаша. Бергә фикер алышканнан соң, алар бу урынны «Рус Швейцариясе» дип атарга булалар. Панаев үзенең китабын да «Казанда Швейцария» дип атый. Икенче фараз буенча, бу атаманың авторы – Цюрихтан килеп, 1806 елда Казан университетында физика укыткан Ксаверий Иванович Броннер. Табигать сөюче буларак, ул бу урыннарда бик еш була, аларны үз Ватаны белән чагыштыра. Казанда 1820 елга кадәр торганнан соң, ул яңадан Швейцариягә кайтып китә.
Бу урынның үсешенә 40 нчы еллар башында биредә губернатор Шиловның җәйге резиденциясе төзелү дә зур этәргеч ясый. Биредә агачлар утыртыла, ресторан ачыла, беседкалар, өстәлләр, утыргычлар куела, юллар түшәлә, җәяүлеләр өчен сукмаклар барлыкка килә. Җәяүлеләргә уңайлы булсын өчен, мондагы ермаклар аша агач күперләр салына, күп урыннар чәчәк клумбалары белән бизәлә.







«РУС ШВЕЙЦАРИЯСЕ»



«Рус Швейцариясе» тиз арада Казан халкының яраткан урынына әверелә. Ачык һавада биюләр, хор белән рус халык җырларын җырлаулар биредә ял итүчеләрнең күңелләренә хуш килә. Соңрак монда ачык сәхнә, трактирлар, павильоннар төзелә.
1837, 1866 елларда Казанга килгәч, «Рус Швейцариясе»ндә Александр II һәм Александр III тә булып, шәһәр халкы белән аралашалар.
1866 елда Казанның «Губернские ведомости» газетасы бу турыда менә нәрсәләр яза: «Рус Швейцариясе»ндә Бөек кенәзләр килү хөрмәтенә зур бәйрәм уздырылды. Губернатор дачасы янында кунаклар өчен аерым чатыр, ә гади халык өчен бәлешләр, бал, шәраб, сыра, башка төрле сыйлар тулы өстәлләр куелган иде. Шулай ук халык өчен гөр килеп таганнар, карусельләр эшләп торды, бушлай тамаша күрсәтү өчен махсус чакырылган эквилибрист чыгышын карау өчен 30 меңгә якын кешедән торган чират тезелгән иде (Казанда бу вакытта 63744 кеше яшәгәнен дә искәртеп китәргә кирәк).
Вакыт узу белән губернатор дачасы янында башка атаклы кешеләрнең дачалары да барлыкка килгән. Шәһәр үзәгеннән «Рус Швейцариясе»нә башта атларда, соңрак трамвай белән 5 тиенгә бик тиз килеп җитәргә мөмкин булган.



Элек Арча кырында уздырыла торган Изге Тройсын бәйрәмен «Рус Швейцариясе» бакчасына күчерүне дә билгеләп үтәргә кирәк. Бу бәйрәмгә халык матур киенеп, үз самоварлары белән килә торган булган. Самоварсыз килүчеләргә аны прокатка алу мөмкинлеге булган. Газеталарның берсе бу турыда менә нәрсәләр язган: «бәйрәм көнне самоварчы хатын самоварларын биреп торып кына да 100 сум акча эшләп алган. Бары тик «Рус Швейцариясе»ндә генә берьюлы 500 самовар куелып, чәй эчү күренешен күзәтергә була. Бәйрәм фейерверк белән тәмамлана». Бакча, шулай, бәйрәм көннәрендә дә, эш көннәрендә дә күңелле тормыш белән яшәгән.
«Рус Швейцариясе»нең М. Горький исемендәге ял паркына әверелүенә дә шактый вакыт узды. Паркның гөрләп чәчәк аткан заманнары да, ташландык хәлгә калган аяныч вакытлары да булды. Реконструкциядән соң парк танымаслык булып үзгәрде, һәм ул бүгенге көндә дә халыкның иң яраткан ял урыны булып дәвам итә.

Фотолар: ТР Милли музей фондыннан.

Һаман яратам

Һаман яратам

***Шик туса кинәт җаныңда әгәр,
Йә килсә сиңа куркыныч хәбәр
Мин йөргән яктан –
ерак-еракттан, –
Ышана күрмә, һаман яратам!
Ашыга күрмә, ялгыштан саклан,
Һаман яратам, һаман яратам!***

***Йолдызлы аяз күгеңне әгәр
Авыр болытлар каплап китсәләр,
Каршы искән
җил капланса тынга –
Нык бул: син генә,
тик син җанымда!
Берешә күрмә сагышка, моңга,
Җанымда тик син,
тик син җанымда!***

***Сакла сөюне, таплама берүк,
Олы хисләрне ваклама берүк.
Узар гомерләр аккан су кебек,
Гомер – бер генә, сөю – мәңгелек!
Узар гомерләр искән җил кебек,
Сөю – мәңгелек, сөю – мәңгелек!..***



Узар гомерләр аккан су кебе
Гомер – бер генә, сөю – мәң
Узар гомерләр искән җил к
Сөю – мәңгелек, сөю – мәңг

«ҺАМАН ЯРАТАМ»

Шундый җырлар була: еллар узса да, алар һаман популяр, алар һәрчак күңел түрендә, олысы-кечесе яратып җырлый. Искерми дә, онытылмый да ул җырлар. Дуслар җыелган җирдә, сабакташлар очрашканда, күңел кылларын тибрәтеп, әнә шул кадерле җырлар яңгырый. «Казан кичләре», «Чыгарсыңмы каршы алырга?», «Җидегән чишмә», «Кышкы романс»лар...

Безнең халык җыр ярата. Күңелләрне кузгатырлык бер матур җыр яңгыраса, аны шундук отып алалар, кичәләрдә, концертларда, мәҗлесләрдә җырлыйлар. Элегрәк кызларның җыр дәфтәрләре була иде. Һәм һәр яңа матур җыр анда урын ала! Хәзер андый популяр җырларны флешкага яздырып алалар, караоке итеп җырлыйлар, радиостанцияләрдә туктаусыз әйләндерәләр...

Ә ул матур җырлар ничек туа соң? Авторлары кемнәр? Кем башкара? Журнал битләрендә менә шундый онытылмас җырларның язылу тарихын сөйләргә булдык.

Редакциядәгеләрнең теленә килгән беренче җыр – ул, әлбәттә, «Һаман яратам» иде... Тикмәгә генә ул җырны мәхәббәт гимны, сөю символы дип йөртмиләр! Шагыйрь Зөлфәтнең «Һаман яратам» дигән тирән мәгънәле шигыре Фәрит Хатипов язган матур көйдә искиткеч яңгыраш таба! Өр-яңа җыр туа. Иң беренче булып аны Илһам Шакиров башкара! Рабига Сибгатуллина, Фидан Гафаров, аннары Зилә Сөнгатуллина белән Мирсәет Сөнгатуллин, бүген Филүс Каһиров кебек җырчылар репертуарында яңгырый ул.

Һәркемнең «Һаман яратам»га кагылышлы үз хатирәләре бардыр. Миңа ул, иң элек, студент елларымны искә төшерә. Без беренче курста укыганда чыкты да бөтенебезнең яраткан җырына әйләнде «Һаман яратам»! Экспедицияләргә барганда да, төзелеш отрядларына киткәндә дә, «Студентлар язы» фестивальләрендә дә гел шул җыр яңгырый!

Университетның атаклы 4 нче тулай торагы көннәрдән бер көнне шау итте: шагыйрь Зөлфәт килгән! «Һаман яратам»ның авторы! Без, төрле сәбәпләр тапкан булып, шагыйрьне күрер өчен баскыч мәйданчыгыннан әллә ничә кат урыйбыз. Бөдрә чәчле, зәңгәр күзле,

елмаеп кына тора. Үзе шундый гади!..

Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова сөйли: «1974 елның май ахыры. ВЛКСМ өлкә комитеты Татарстанның иҗат яшьләре өчен «Волга» яшьләр лагеренда семинарлар уздыра иде. Мине дә чакырдылар. Зачетларымны тиз генә тапшырып бетердем дә шунда ашыктым. Без – яшь рәссамнар, композиторлар, артистлар, шагыйрьләр – бер автобуска төялеп, «Волга»га кузгалдык. Бүгенгедәй күз алдымда: рус яшьләр театрыныкылар булса кирәк, «Тачанка»ны җырлый гына башлаган иде, безнекеләр көчле тавышка «Һаман яратам»га күчмәсенме! «Тачанка» әллә кайда күмелеп, югалып калды. Юл буе «Гомер – бер генә, сөю – мәңгелек» дип җырладык. Мәхәббәткә табындык. Безнең арада Батулла, Фаил Шәфигуллин, Гәрәй Рәхим, Шәмсия Җиһангирова һәм... Зөлфәт үзе дә бар иде...»

Җыр, һичшиксез, Зөлфәтнең хатыны Фирая апага багышлап язылган булырга тиеш. Бары аңа гына! Фирая апаның уңганлыгы, чибәрлеге, ягымлылыгы, яхшы күңеле хакында, бер-бер артлы тудырган уллары турында легендалар йөри. (Халык Зөлфәт белән Фирая апа малайларының исемнәрен үк белеп тора: Азамат, Илһам, Фазыл, көттереп кенә туган кадерле кызлары – Кадрия.) Ә Фирая – романнарда гына очрый торган идеал образ сыман. Озын кара чәчләр, нурлар чәчеп торган шаян күзләр, нечкә бил. Җитез хәрәкәтләр, җанны эретерлек ягымлы тавыш, яңгыратып көлүләре... Хәтта кайбер яшь шагыйрьләр, Зөлфәтнең шәкертләре, Фирая апа кебек кыз очраса гына өйләнәм дип йөргән, имеш. Ә җыр сүзләренә килгәндә исә, ул – Зөлфәт еракта, Мәскәүдә укып йөргән чагында, Фираясын сагынып өзгәләнгән минутларында туган, дип тә сөйлиләр.

...Фирая апа бу кыйссаларны елмаеп тыңлап торды да гаҗәпкә калдырып:

– Белмим, миңа багышланды микән инде ул? – дип көлеп җибәрде. – Беренче мәртәбә 1973 елның сентябрендә, бала табу йортыннан Фазылны алып кайткан көннәрдә ишеттем ул җырны!.. – диде ул бәхетле елмаеп. – Ә бит бу җыр тумый да калган булыр иде», – дип янә шаккаттырды, һәм еракта калган 70 нче елларга алып китте.

– Зөлфәт белән күптән түгел генә өйләнешкән чак. Классташлар белән очрашырга булдык. Парлап шунда киттек. Мәктәптә укыганда мин гашыйк булып йөргән егет тә килгән... Аны күрүгә, әллә нишләп киттем: каушап, кызарыплар беттем. Әйтерсең, унынчы сыйныфта укучы хыялый кыз! Сагындырганнар... Дөньямны онытып, сабакташлар белән түйганчы бер аралаштым! Ул арада Зөлфәт... үпкәләп чыгып киткән. Исебезгә килеп, аны эзләргә керештек. Коридорлар, мәктәп ишегалды калмады. Бер җирдә юк! Ул мине ташлап калдырган! Күңелдә утлар януын сиздермәскә тырышып, урам чатында озатып калган дусларым белән уйнап-көлеп саубуллашкан булам. Аннары иреннәремне тешләп, берьялгызым төнге урам буйлап атлыйм. Бөтерелеп-бөтерелеп кар ява. Күзләремнән яшь ага. Аяк астымда шыгырдаган кар тавышы үзе шомлы, үзе матур көй булып күңелгә уелып калган. Карынымда – әле генә җан кергән сабыебыз... Үзем дә инде яшь кенә! Нибары 22 яшь! Нишләргә, кая барып бәрелергә дә белмим. Куркыта да бит әле. Туңып беттем. Һәм, билгеле бер карарга килеп, өйгә кайтып кердем. (Олег Кошевой урамында кеше фатирында тора идек ул чакта.)

«Зөлфәт! Мин китәм!» – дидем яшь аралаш. Безне үртәгәндәй уйнаклап-бөтерелеп яуган кар аермачык күренә тәрәзәдән. Ул да озак итеп ябалак карлар яуган урамга карап торды. Аннары кәгазь битенә ашыга-ашыга нидер язды да миңа сузды. Яшьләремә йотыла-йотыла укыйм.

Юк, китмә, кирәкми... мин сине
Аралап алырмын кышлардан,
Бу ап-ак гарасат нигәдер
Нәкъ безнең сөюгә охшаган.

...Тетрәнде керфегең, болыттан
Ак карлар ычкынган шикелле.
Ачылды керфекләр, бу көннәр
Бураннан ачылган шикелле.

Ак бәхет калдырды бу йортны
Дөньялар агарган көннәрдә.
Ялвару төс түгел ирләргә...
Толымың җылысы – миндәрдә!

Нәкъ төнге урам күк күңелем,
Беркем юк... Кар ява – төнге кар...
Ишелер шикелле син мине
Калдырып киткән бу текә яр.

Мин торам язмышлар ярында,
Упкынга атларга әзермен,
Мин сине сөйгән күк, син дә бит
Башканы сөясең, кадерлем!

Артык зур булгандыр бәхетең,
Йә минем урамым тар булган.
Мин ярда, нәкъ шушы яр буйлап
Җир шары урталай ярылган.

Ялвару төс түгел ирләргә –
Сагыну төс икән шулай да.
Кар сыман язмышлар әйләнә,
Һәрвакыт әйләнми уңайга.

Ак булсын бәхетең урамы,
Яз көне шауласын яфраклар,
Кыш көне сибелсен биектән
Назларың шикелле йомшак кар.

Һай биек, бик биек син мине
Калдырып киткән бу текә яр!
...Мин торам язмышлар ярында,
Беркем юк – кар ява, төнге кар...

Бу – Зөлфәтнең гафу соравы да, чарасызлыктан бәргәләнүе дә, көнчеллек утында януы да, аңлашырга теләве дә иде... Бу – ярату иде!.. Калдырып китә аламмы соң! Юк! Юк! Мин кабат бәхеткә коенган идем инде. Язмышлар хәл ителгән әллә нинди серле кич булды ул. Шушы кич булмаса, «Һаман яратам» да язылмас иде...

Редакциядән: Беренче нотасыннан ук үткәнгә алып китә, хатирәләргә чумдыра, сагышка-моңга күмә, рәхәт чакларны, күңелле истәлекләрне яңарта торган җырлар сездә дә бардыр ул. Бәлки, шул хатирәләрегезне журнал укучылар белән дә уртаклашырсыз? Хатларыгызны сайтыбызда да урнаштырачакбыз.

Эльмира ЗАКИРОВА



«БЕРДӘНБЕРЕМ ДИГӘН ИДЕҢ...»



Өй тулы бала-чага. Кайсы дәрес әзерли, кайсы компьютер янында мәш килә... Һәркайсының үз шөгыле, кыскасы. Зәңгәр күзле, бөдрә чәчле 7-8 яшьләрдәге кызчык мине күрүгә каршыма килә, ике кулын биреп олыларча исәнләшә. «Шундый ул безнең», – ди минем елмаюымны күреп хуҗабикә. Ул бермәл ни әйтергә дә белми, югалып калгандай була. Әллә чакыруына үкенә инде. Чишенә башлыйм, тик ул мине шундук туктата: «Өйдә сөйләшеп булмас, әйдәгез, урамга», – ди дә, мине үзе белән җил чыгып, буран буранлап торган кышкы урамга алып чыгып китә.

Бөтен дөнья ап-ак карда. Без дә шул аклык эчендә, ишелеп яуган кар әсирлегендә. Шактый вакыт сүз ялганмый. «Бураннарга кереп адаштым...» – дип куя ул һич көтмәгәндә. Һәм әкрен генә сөйли башлый. Аның үткәне бер мизгелдә күз алдына килеп баса.

Алар өйләнешкәндә дә аяктан егарлык буранлы көн булган. Илдары Зөһрәне загстан туп-туры өч бүлмәле фатирына алып кайтып утырткан.

– Бердәнберем, – дия иде ул миңа, – ди ханым хатирәләргә бирелеп. – Гел шулай диде. Аннары бер-бер артлы балалар туа башлагач, аралар суына башлады. «Зөһрә шуны эшләмисең, Зөһрә моны эшләмисең...» Һаман ризасызлык, һаман канәгатьсезлек... Җиде бала карау ансат түгел. Безнең икебезнең дә әниләребез юк.

Шуңа бөтенесе минем җилкәдә. Илдар ул көн-төн эштә. Дөресен әйткәндә, балаларны күрми дә. Эштән өйгә кайтмый калган чаклары еш булгалады инде. «Кайда йөрдең?» – дип тә сорамадым шул чакларда. Ышана, чиксез ышана идем мин аңа. Кайдадыр, кем беләндер дип уема да китереп карамадым. Һәм менә...

Һәм менә... Ире аны иптәшенең туган көненә алып бара. Бер дә барасы килми Зөһрәнең, әллә нигә аягы тартмый. «Барабыз!» – дип кырт кисә Илдар. Бара ул баруын, тик соңыннан ник барганына үкенеп бетә алмый. Табын янында аларның урыннары янәшә туры килә. Зөһрә ул хатынны башта танымыйча тора, ә таныгач, хәйран кала. Карасана, сыйныфташы ич ул аның! Өйләнеп тә карамаслык бер бетәшкәнең күз алмаслык чибәр бер ханымга әверелүенә исе-акылы китә. Илдары аны биергә чакыра. Аннары алар бик озак каядыр юкка чыгып торалар. Тагын көлешә-көлешә биеп алалар. Ире хатынын оныта. Әйтерсең, ул бирedә юк та.

Өенә кайткач та сыйныфташы Рәхилә күңеленнән китми. «Кара син аны, – ди ул һаман бер сүзне кабатлап. – Үзгәргән кеше. Ә мин кем, мин нинди?» Ул көзге каршына килеп баса. Көзгедән аңа маңгай тулы җыерчыклы, чигә чәчләренә чал куна башлаган, зур күзләренә тирән сагыш кереп оялаган бәхетсез бер хатын карап тора иде. Бизәнү, үзен карауның ни икәнен белми дә белми инде ул. Нигә шулай булгач үпкәләргә ирenә? Күз бит ул, ә күз чибәрләрне, матурларны күзли.

Хатын үзен шулай дип тынычландыра. Үзе гаепле ул, күршесе Сания апа әйтмешли, бер-бер артлы бала тапмаска иде. Шулай ди дә, шөкер әле, алар бар дип, куанып куя. Аларның һәркайсы аның өчен бердәнбер бит. Илдары да балалар өчен җан атып тора анысы, сабыйлары өчен барын да эшли. Ярата ул балаларны, әйбәт әти. Ә аны? Хәзер аңа – ире белән егерме ел гомер кичергән хатынга – мәхәббәт турында сөйләп торуы да оят. Билләһи, оят. Әмма ир белән хатын арасында хәтта пыскып янган учак җылысы да калмаса, ничек яшәргә?

Бу сорауга җавапны ир күптән тапкан булып чыкты.

Зөһрә, Фатыйма, Гөлчәтәйләр...

Әллә сез аларны – ирләре уртак, түшәкләре уртак хатыннарны кинофильмнарда гына күрергә була дип уйлыйсызмы?! Юк икән. Тормышта, чынбарлыкта, кызганычка каршы, дип әйтимме, ул еш була торган күренешкә әйләнеп бара. Әйе, безнең дин рөхсәт итә күп хатынлылыкны. «Берничә хатын белән гомер кичерү ир кешенең гадел булуын таләп итә. Һәм матди яктан ир кеше хатыннарын тигез карарга, торыр-ятар урыннар, ашау-эчү, бизәнү, кием-салым, бүләк-санак тигез булырга, икәүдән-икәү генә калу вакытларын да ир кеше тигез бүләргә тиеш...» диелә Х. Караман тәфсирендә (Ниса сүрәсе). Күп хатынлы бер дин әһеленең сылтавына гына игътибар итик: «Ялгыз хатыннарны дөм ялгыз калдырмас өчен, мөселман балалары күбрәк тусын өчен...» – дип аңлата ул үзенең өч хатын белән яшәвен. Белмим, хатыннар моңа ничек карыйдыр, нинди мөнәсәбәттәдер, ничек түзәләрдер... Җил ачысыннанмы, күңелендә давыл булып күтәрелгән кичерешләреннәнме, бөрешеп-кечерәеп калып янәшәмнән атлаган хатынга тел очымда бөтерелгән сорауны бирәм: «Ничек түзеп торасың?»

Ул җавап бирергә ашыкмый. Бая салмак кына башлаган сүзен дәвам итә.

– Илдарның ни өчен сыйныфташым янында бөтерелүен, бер алдына, ике артына төшеп, мине кеше алдында адәм көлкесенә калдыруының сәбәбенә соңыннан төшендем. Тик эш узган иде инде. Атна-ун көн үтүгә әйтә бу миңа: «Син миңа үпкәләмә, рәнҗемә инде. Мин Рәхилә белән никахлаштым», – ди. Баскан җиремнән чак кына авып китмәдем. Ул тотып калды. «Бердәнберем», – дигән идең, дип кенә әйтә алдым. «Син дә бердәнбер, ул да...» – ди. Күземә туп-туры караган, ник бер читенсенү әсәре булсын. Ул көнне шуның белән сүз бетте. Миңа барын да уйларга, ныклап уйларга кирәк иде. Елаганымны балаларга күрсәтмәдем. Эчтән сыздым: төн уйладым, көн уйладым да карарымны җиткердем: «Ярый, синеңчә булсын, дидем. Балалар хакына риза мин. Тик аны күземә күрсәтмә, миннән ерак йөрсен». «Дөрес уйлагансың, – диде Илдар. – Мин бит сезнең икегезне дә тигез күрәм». Тигез күрәм, диде. Ә тигез яратам, димәде. Бертигез яратып булмый шул ул.

Хатыннарының һәркайсы ире өчен – бердәнбер.

– Ничек ризалаштың соң, газиз иреңне ничекләр бүлешергә була? – дим, хатын өчен гарьләнеп. Һәм шундук соравыма сискәндергеч җавап ишетәм: «Мин дә башта шулай уйлаган идем, – дип дәвам итә ул сүзен. – Ике көн – минем янда, ике көн – аның янында. Күпләр фаҗига дип кабул иткән бу хәлнең сине хәрәкәткә китергән, йокыдан уяткан өстенлекле бер ягы бар – хатын-кызда камилләшү, көндәшеңнән матуррак, шәбрәк күренү теләге уяна. Мин үземә үзем шаккатам. Хәзер мин көзгегә ешрак карыйм, салонга йөри башладым, киемнәремне алыштырдым. Эшкә чыгарга җыенам менә. Кеше арасында җиңелрәк булыр дим. Сер итеп әйтәм, аны элеккегә караганда да ныграк яратам хәзер.

Чарасызлыкмы, чын яратумы шулай итә хатын-кызны?! Чарасызлыктыр... Үзенә хыянәт иткән кешегә мөнәсәбәт башкачарак була бит ул. Ире генә моны хыянәткә санамый. «Мин сиңа ачыктан-ачык әйттем. Яшертен йөрсәм дә, берни белми идең. Мин сиңа хыянәт итмәдем. Икенче хатын алып кайттым. Син беренче һәм беренчесе булып калачаксың да», – ди. «Бер уйлаганда, шулаен да шулай, – ди Зөһрә, ирен аклагандай итеп. – Йөреп интектергән, сөяркәсе булган ирләр азмы? Китмиләр дә, калмыйлар да. Ике арада йөриләр шулай. Хет болай җанашыңның кем кочагында булуын белеп торасың. Шуннан сиңа җиңел булып китәме, дисез инде. Җиңел булмый, баштарак ул аның янында чагында мендәргә капланып елый торган идем. Аннары күнектем. Болай да яшәп була икән, дидем. Барыбер очы-кырые чыга аның. Тынычланыр бер.

Фото: Газинур Хафизов

Өченчегә – яшь хатын...

– Тынычландымы соң? – дим.

– Тынычланыр, бар, – ди язмышына тәмам буйсынган хатын. – Ике еллап яшәгәннән соң, Рәхиләсе кыз бала тапты. Миннән, гәрчә беренче хатыны булсам да, бик көнләште. Аңа шуны алгансың, моны алгансың дип, сатып алган һәр яңа нәрсәгә, хәтта вак-төяккә дә ирне талады. Ул үзе дәшми, күршеләре җиткереп торды. Көннәрдән бер көнне Илдарым болай ди: «Ачулансаң ачулан, гаепләсәң гаеплә, мин – гашыйк, кешем бар», – ди.

– Тагынмы? – дим.

– Тагын артыңа егылып киттеңме?

– Юк, бу юлы тыныч кабул иттем. Үзем дә гаҗәпләндем. Әйтерсең, вакыйгалар миңа кагылмый. Әйтерсең, янымда ирем түгел, якын бер туганым басып тора.

– Йә, дим, тагын никахмы?

– Әйе, – ди бу, – миннән 20 яшькә яшьрәк.

– Беләме соң синең ике хатынлы икәнлегеңне, дим. Рәхиләгә әйттеңме?

Күпме түзәргә була. Сабыр канатлары да бер сына, бер каерыла бит...

– Белә. Ә Рәхиләгә әйтмәдем. Аңламас ул мине, ул синең кебек түгел.

Рәхиләсе белгәч, зур тавыш куптарган. Илдарны өеннән куып чыгарган. Адәм баласы кылган һәр гамәл – яхшымы ул, яманмы, кире үзеңә әйләнеп кайта. Үзе, мин бар дип тормады, өстемә килде. Ә мәнә үзенең өстенә килүне ошатмый.

Зөһрә Илдарының яшь хатыны Гөлназ белән сирәк кенә булса да күрешкәләп тора. Беренче хатын өченче хатынга баласы сыман карый. Яшенә караганда, чыннан да шулай килеп чыга бит.

– Көнләшмисеңдәме?

– Көнләшәм, ник көнләшмәскә, өчебез бер ирне бүлешәбез ич... Тик миндә хәзер хискә караганда, күбрәк зирәклек өстенлек итә. Риза булдым ич, үзем килештем. Әлеге дә баягы, кая барыйм, мин кемгә кирәк?.. Балалар турында уйлыйсың, алар, ичмасам, әтиле үсә. Әтиләрен бик ярата алар. Әтием дә, әтием генә, күрсәгез...

Олыраклары әтиләренең чит хатыннарга мөкиббән, мәхәббәткә бай булуын аңлыйлар бугай. Ләкин әниләре аларны: «Анда сезнең эшегез юк, әти-әни арасына тыгылмагыз», – дип өйрәтә. Шуңа балалар кемнедер гаепләүдән ерак тора.

– Олы улыбыз өйләнде, хатыны иремнең өченче хатыны яшендә, – ди әрнеп Зөһрә. – Оят инде, бер уйласаң. Ирем белән улым бер тирәдәрәк никахлаштылар. Кыз сорарга баргач, булачак кодагыем улыма: «Син дә әтиең шикелле өч хатынга өйләнерсеңме?» – дип мәсхәрәгә калдырды. Улым ык-мык килде, ни әйтергә белми торды да: «Ата-ананың кылганы өчен бала җавап бирми. Мин әнинең нинди ут эчендә яшәвен күреп үстем. Никахым да, өйләнүем дә бер генә булыр», – диде. Кистереп әйтә алуына горурланып та куйдым. Шул чагында Илдарның уңайсызлануын күрсәгез...

«Кызымны... икенче хатынлыкка»

– Нәрсә? – дим аңламыйча, – бу ни дигән сүз?

– Инде хәзер кызымны икенче хатынлыкка сорап яталар, – ди Зөһрә кызы өчен кимсенеп. Кем биргәндер инде аның телефонын. Әтисе дип тә уйладым. Кызым минем бик үткен. Очрашкач әйткән: «Син минем әтием шикелле кеше. Ничек мине оялмыйча икенче хатынлыкка сорыйсың? Мин булачак иремне беркем белән дә бүлешергә җыенмыйм», – дигән. Ә тегесе: «Бай кеше мин, ни телисең, шул булыр», янәсе. Менә бит ниндигә китте дөньялар.

– Балалар дисең ич, бәлкем, алар үсеп җиткәч...

– Юк. юк, – дип туктата ул мине, аерылышмыйм. Гомер юлы көзләргә борылганда нинди аерылу ул.

Өметсезлекме, хәсрәт-борчу шулай итәме кешене, нинди әле 45 кә якынлашып кына килгән хатынга гомер көзе? Әле барысы да алда, тормышны яңадан башларга була дип, аны ышандырырга тырышуның да мәгънәсен күрмим. Бөтен хикмәт шунда ки, ул инде бу тормышка ияләшкән. Аның берни үзгәртәсе килми. Аңа шулай уңай. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

– Әтисе кызыгызны икенче хатынлыкка сорауларын ишеткәч ни диде соң?

– Кызыбыз дөрес әйткән, – диде. Кызганыч, дим, сиңа заманында шул сүзне әйтә белмәделәр. Өйләндең дә бетте түгел бит әле ул. Хатынны аны тәрбияләргә кирәк. Бүген ул көчле, гайрәтле, иртәгә нинди булыр? Үзе минем янымдарак булырга тырыша. «Яшьләргә ышанмыйм» кебегрәк сүзләр дә ычкынып куя кайчак. Белә минем тугры, сабыр булуымны.

«Тугры, сабыр...» – ди. Күпме түзәргә була икән ул, ә?! Сабыр канатлары да бер сына, каерыла бит. Хатын-кызны тикмәгә генә көчлеләр затыннан димәгәннәрдер. Безнең көчлелек – сабырлыкта анысы. Зөһрә бу сүзләргә: «Үз сәгатеңне сабыр гына көтеп алуда», – дип тә өстәр иде әле. Сабырлык ул миндә дә бар. Әмма моның ише сабырлык миңа кирәкми. Ходай үзе сакласын! «Бураннарга кереп адаштым» көненә калырсың аннары.

Мәдинә АВЗАЛОВА

ЯҢАЛЫК

Яңа елдан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте шәригать буенча никахларны теркәү өчен дәүләт билгесе белән хупланган бердәм рәсми документ кабул итте. Шуңа таянып, республикадагы никахлар турындагы белешмә базасы булдырылачак. Бу яңалык яшьләрне ислам кануннары буенча никахлашуга җитди карарга өйрәтер, булачак кәләшләрне аферист кияүләрдән саклап калырга ярдәм итәр дип көтелә.



Ирек ШӘРИПОВ

Казан дәүләт университетының журналистика факультеты (1993), Урал дәүләт хезмәте академиясе (2003)

Өйләнгән, өч ул үстерәләр.

Карьера:
Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның «Халыклар дуслыгы» йорты директоры.

Кредо: «Яхшылык эшләү – ул кимчелек түгел».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Татарстаныбызны таныйлар!

Үткән ел Россиядә милли сәясәт өлкәсендә зур алга китеш булды. Яңа милли сәясәт буенча дәүләт стратегиясе кабул ителде. Беренче тапкыр дәүләт милли сәясәте өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр арасында Бөтенроссия конкурсы үткәрелде. Без Россиядәге иң яхшы «Халыклар дуслыгы» йорты булып танылдык! (Мондый йортлар хәзер утызлап төбәктә эшли.) Конкурстан үзебезнең коллективтан бигрәк, Татарстан өчен канәгатьлек хисе белән кайттык. Республика милли сәясәт белән 20 елдан артык әзлекле рәвештә юкка гына шөгыльләнми!


Гади фәлсәфә генә түгел


Кризис башлана дигәч, Ижаудан энекәш килде – икенче машина алырга. Автосалоннан кайтышлый заправкада яңа машинага бензин салып, сөйләшеп торабыз. «Кризис белән нишләрбез, нәрсә булыр?» – дибез. Сүзгә заправщик кушылып китте. «Барысы да әйбәт булыр – сезнең бит президентыгыз яхшы, – ди. – Мин менә Луганскидан. Без ни өчен мондый хәлгә калдык? Чөнки безне саттылар: президент, җитәкчеләр... Алар ил, халык турында уйламады. Ә сезнең Президент сезне сатмаячак». Күңелгә ничектер җылы йөгерде... Әйе, бәлки, тыйнаграк яшәрбез, әмма иң мөһиме: бер-береңне сатмау.

Читтән яхшырак күренә!

«Татарстан мирасы» дигән эмблеманы кабул иткәндә Мәскәү журналисты Сергей Брилев бер фикер әйтте: «Татарстан өчен бүген мирас саналган күп нәрсәләр – безнең өчен әле киләчәк кенә», – диде. Татарстаныбызның илдә һәм дөньяда тоткан урыны ихластан сөендерә. Минем кебек күптән түгел читтән кайтып урнашкан кеше күзенә ул бигрәк тә нык ташлана. Без хәзер инде нефть түгел, ә нефть продуктлары сатабыз. Кайдадыр халык газ турында хыяллана гына, ә без инде күптән газлы. Юлларны башкалар белән чагыштырып карау да – республика файдасына.

сөендерде








көендерде

сөендерде








көендерде

сөендерде







көендерде

Иңдәге йөкне... күршегәме?!

Бер атна эчендә өч җырчы килде. «Концертлар бармый, булышыгыз әле», – диләр. Уенын-чынын кушып: «Бәлки, җырларга түгел, эшләргә кирәктер», – дидем... Узган ел гына республика чит илләрдән 60 мең мигрант кабул итте. Аларның берсе дә ял итәргә килгән кешеләр түгел... Районда участковыйга коттедж салып куйганнар, машинасы тора, ә эшләргә теләүче юк! Авылларда күп функцияле үзәкләр төзелә – җитәкләргә кеше тапмыйлар. Минем өйгә күрше кереп минем эшне эшләргә тиеш түгел бит инде. Хәлләр болай барса, безгә әле бик күп «Халыклар дуслыгы» йортлары ачарга туры киләчәк.

Кызганыч, кимибез...

Районнарда очрашуларда йөргәндә бик затлы, зыялы татар кешеләре белән күрешергә туры килде. Зур урыннарда эшлиләр. «Ничә балагыз бар?» – дигәнгә, күбесе: «Бер», – дип җавап бирә. «Сез бит бер бала белән генә калырга тиеш түгел!» – дим. Районда балалар бакчасы ачабыз. Мөдире яшь кенә ханым. «Балам берәү», – ди. Икенчесен табарга җыенмый... Җитди мәсьәлә бу. Киләчәктә, димәк, татарның саны кимиячәк. Милли сәясәтне аны Президентлар, җитәкчеләр түгел, халык та хәл итә. Кешенең төп бурычы исә карьера ясау, байлык туплаудан бигрәк, җирдә үзеннән соң лаеклы дәвам калдыру.

Дөнья ялгыш юлдан китмәсен иде

Без, кызганычка каршы, кабат кризис чорына кереп барабыз... Тарих шуны күрсәтә: авыр чорда гаепләне эзләү башлана. Гаепне, гадәттә, чит кешедән эзлиләр. Ә чит кеше дигәнең еш кына башка милләт вәкиле булып чыга. Ишетеп, күреп торабыз: Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдә скинхедларниләр кыланып йөри әнә. Минем карашым, гомумән, шундый: гаепне иң беренче һәрвакыт үзеңнән эзләргә кирәк. Хәтта син гаепле булмасаң да.

РЕКЛАМА

БЕЗ КЕШЕЛӘРНЕ КИЕНДЕРЕП КЕНӘ КАЛМЫЙБЫЗ. БЕЗ ОБРАЗ ТУДЫРАБЫЗ.

ЛЮКС BOUTIQUE

Казан, Калинин ур., 37
+7(843)264-51-61
luxkazan.ru

ЗАТЛЫ ХАНЫМ ЗАТЛЫ КИЕМ САЙЛЫЙ



«Киенгәннәрне» киендерү нинди катлаулы. Зәвыклы кешеләргә затлы, брендлы киемнәр тәкъдим итүне күздә тотып әйтүем. Өстәвенә, хәзер күп кеше фешн индустриядә кием тудыручыларның үзләренә караганда да яхшырак «йөзә».

Мода, никадәр генә кодрәтле, мавыктыргыч нәрсә булмасын, кыска гомерле. Кыска гомернең сәбәбе — кеше табигатенең гел яңалыкка, төрлелеккә омтылуы. Моданың яңаруы, тормыш сулышы сыман, билгеле бер ритмга буйсынулы. Нәкъ менә шуңа күрә дә модада әллә нинди заман үзгәрешләрен тоемларга мөмкин. Модалы кием-салымга сәнгати агымнар да, модадан әллә кайда торган гуруларның кыланышлары да, сәяси вакыйгалар да, милли хасиятләр дә, текстиль белән эш итүчеләрнең икътисадый хәйләләре, буыннар арасындагы аңлашылмаучылык та, үткәннәрне сагыну да тәэсир итә.

Туташ-ханымнар бүген җаннары ни тели, шуны сатып ала. Шулай булса да, Казанның шундый бер аулак почмаклары бар ки, монда сезгә килешле киемне генә сайлашып калмыйлар, ә сезнең, фәкать сезнең генә стильне дә табарга ярдәм итәләр. Бу стильнең никадәр сезнеке булуын, бәлки, әле үзегез дә белмисездер.

Сүзебез теләсә нинди гәүдәле, теләсә нинди буй-сынлы ханымнарга килешле кием образы тудыру хакында. Теләсә кайсы яшькә, теләсә кайсы бәягә...

Мода индустриясе вәкилләре белән эш иткәндә еш кына бер нәрсәне искәрәм: илгә-көнгә исемнәре билгеле дизайнерлар иҗат иткән образлар күп очракта модель сынлы кызларга тәгаенләнгән. Безнең туташханымнарыбызның гәүдә, буй-сын рәвешләре ул озын һәм нечкә буйлы кызларныкы кебек түгеллеген, хәтта Европа ханымнары буй-сыннан да бик нык аерылып торганын онытып җибәрә шикелле алар.

Кайчак үз-үзеңне карарга вакыт та, көч тә җитеп бетми. Безнең хатын-кызлар өчен гаилә, балалар, эш – беренче урында. Үзенә вакыты калса кала, калмаса юк. Бизнес белән шөгыльләнүче ханымнар да, гәрчә үзләрен карауга күбрәк вакыт сарыф итсәләр дә, үзләренә акча тотмау ягында. Кызганычка, безнең дизайнерларыбыз үзләре иҗат иткән киемне хатын-кызның бизәге сыйфатында күрә, киресенчә булырга тиеш югыйсә. Үзен матур, затлы итеп күрсәтерлек кием кигән хатын-кыз аны үзе бизәргә тиеш. Наталья Бардаеваның югары классллы тәҗрибәле белгечләрдән тупланган командасы – нәкъ менә һәрбер хатын-кызның үзенчәлекле, бүтән беркемдә дә кабатланмас, бердәнбер образын тудыру, аңа гына хас нәзакәтлелекне, аңа гына хас затлылыкны аерып күрсәтү өстендә эшлиләр.

Бу – яхшы стилистка юлыгу белән бер. Гаҗәеп, кайвакыт бөтенләй көтелмәгән образ сезне бөтенләй башка яктан ачарга мөмкин, хәтта дусларыгыз, туганнарыгыз танымас дәрәҗәдә.

Зәвыгы булган, әйбер таный белгән, үз образын тудырганда эчке сиземләвенә таяна алган ханымнарның эше уңай. Мисалга, чәченә гел күбәләк тасма тагып йөргән Татьяна Михалкованы әйтә алам (ул элеккеге модель). Инде менә ничә еллар ул үзенең стилен үзгәртми, һәм Татьяна үзенә күрә бер бренд сыман.

! Хәзер нәфислек модада — күлмәкләр киегез. Күлмәк хатын-кызны һәрчак мөлаем, нәфис итеп күрсәтә.

Фасоны дөрес сайланган күлмәк гәүдәнең килешсез төшләрен яшерә, ә матур төшләрен, киресенчә, ача.

Әмма ни кызганыч, бу стильне йолдызларыбызның да сирәгә генә үз итә, республикабызның асыл ханымнары арасында да күлмәк киючеләр сирәк.







Үз образыңны эзләп табу никадәр авыр һәм катлаулы! Әле бит бу образ тормышның һәр өлкәсендә – эштә, ял иткәндә, кеше арасына чыкканда, өйдә йөргәндә дә ярашлы булырга тиеш.

Шәһәребездә модалы бутиклар (кечкенә кибетләр) бик күп булса да, анда үзеңә килешле киемне тиз генә табып алырмын димә. Берничә тапкыр шундый күренешнең шаһиты булганым бар: сатучы, мактый-мактый, сатып алучыга килешсез кием алдыра. Аларга соң... тауарлары гына тизрәк сатылсын!

Ә менә «Люкс» бутигында сезгә генә, бары тик сезнең үзегезгә генә туры килә торган образ тәкъдим итү белән чикләнеп калмыйлар, бәлки, сезнең өчен кием ярдәмендә тудырылган образны тулыландырырга, ныграк ачарга булышачаклар.

Затлы кием-салым белән сәүдә итүче кыйммәтле бутикларның барысы да гомер буена җитәрлек образ тәкъдим итә алмый!

Чибәр булу хакында гына хыялланмый хатын-кыз, аның яратыласы килә, кемнеңдер аңа карап соклануын тели ул. Ә моның өчен көн саен үз-үзеңне карарга, тәрбияләргә кирәк. Бу, әлбәттә, кием-салымга да кагыла.

! Моданы ике нәрсә китереп чыгара. Беренчесе — кемнеңдер яхшы зәвыгына иярергә тырышу; икенчесе — җәмгыяви алгарыштан калышмаска тырышу.

Миңа бер кызыклы ханым белән танышу бәхете насыйп булды. Бу ханым үз эшен, үз бизнесын ачып, шушы эше белән бүгенгәчә илһамланып, янып яши.

Наталья Бардаева – искиткеч нечкә зәвыклы ханым. Бу зәвыгын ул клиентларына да йоктыра белә. Хәер, аларны клиент дип кенә дә булмый, «Люкс» бутигының дуслары дисәң, дөресрәктер.

«Киемеңә карап каршылыйлар, акылыңа карап озаталар» дигән гыйбарә беркайчан да асылын югалтмас, мөгаен. Гәүдәсенең, буй-сынының нинди үлчәмдә булуына карамастан, хатын-кызның образын таба белү бик зур талант һәм бик зур хезмәт ул. Тулы гәүдәле хатын-кызлардан: «Матур кием табып булмый, зур үлчәмле кием-салым сатучы кибетләрдә капчык сыман асылынган-салынган киемнәр генә эленеп тора», – дигәнне бик еш ишетәм. «Люкс»та 76 нчы үлчәмгә кадәр тегелгән киемнәр бар. Әйе, әйе, дөрестән дә 76 нчы үлчәм, һәм бу киемнәр рәвешен аңлап булмый торган пончолар түгел, чалбарлы костюмнар, затлы кичке күлмәкләр, яхшы тукымадан тегелгән классик жакетлар, итәге идәнгә тиеп торган асыл күлмәкләр һәм башка матурдан-матур киемнәр.







Өске киемнәрдән тыш, «Люкс»та сезгә Европаның иң яхшы фабрикаларында тегелгән эчке кием дә сайлашырлар. Бу кием гәүдәгезне матур күрсәтәчәк, аны кигәч, сезгә уңай булачак.

«Люкс»та тәкъдим ителгән аксессуарларны сез бүтән беркемдә дә очратмассыз. Алар берәр генә данәдә сатыла. Төрле фасонда, төрле тукымадан тегелгән баш киемнәре, букчалар, бармакчалар... Искиткеч сыйфатлы бу тауарлар берничә данәдә генә. Образны тулыландыру өчен нәфис һәм затлы детальләр өстәлергә тиеш – образ тудырганда кулоннар, йөзекләр, каптырмалар, муенсалар бик мөһим роль уйный.

! Быелгы сезонда кара төс өстенлек итәчәк, ди кайберәүләр, кемдер кара төскә яшел яки зәңгәр төс тә өстәргә куша.

Әмма бөтен кеше өчен дә уртак киңәш – сез чибәр күренергә тиешсез. Шунысы бәхәссез: сезнең күңелгә хуш килгән теге эшләпәне беркайчан да дус кызыгыз яки танышыгыз башында күрмәссез. Мода өлкәсендә итальяннар алда бара. Нәкъ менә алар мода өлкәсендә буыннан-буынга күчә килгән сыйфатларны кадерләп саклый һәм үз стильләрен яратарак төшүләрен яшерми дә. Кызыгы шунда: итальяннарның бу милли үзенчәлекләре безнеке – татарларныкы белән бик тә охшаш.

! «Люкс» бутигының көзге һәм кышкы киемнәр тупланмасында татар кызларының милли калфагына бик тә охшаган баш киемнәре бар.

Дизайн өлкәсендә кайнаган яшь талантлар арасында Наталья Николаевнаны хөрмәт иткән, аның сүзенә колак салган кешеләрнең барлыгын беләм. Наталья Николаевна – мода дөньясындагы үзгәрешләрне бик тиз тоемлау сәләтенә ия кеше. Ул, остаз кебек, яшьләргә дөрес юнәлеш бирә белә.

«Дөньяны матурлык коткара!» дигән шигарьне элегрәк еш әйтәләр иде. Чынлап та, матурлык безне күңел төшенкелегеннән, боеклыктан, җандагы бушлыктан коткара. Хатын-кызның нәфис иңнәренә таянып, илебез икътисадый тотрыксызлык һәм үзгәрешләр чорын кичте. Зур-зур капчыклар белән чит илләрдән тауар ташып, шуны базарларга алып чыккан хатын-кызлар таныштырды бит безне шул көнгәчә тимер пәрдә артында булган матур кием-салым дөньясы белән. Әйе, ул күлмәкләр начар сыйфатлы һәм тоташ синтетикадан тегелгән иде, әмма алар, түбән сыйфатлы булсалар да, безне чит ил модасы белән таныштырды.

Әйдәгез әле, хөрмәтле хатын-кызлар, матур булыйк, уңышлы булыйк. Тормыштан зарланмыйк, куанып яшик. Бернәрсәгә карамыйча – кризиска, кырыс ирләр дөньясына үч итеп, иң-иң матуры, иң-иң нәфисе булыйк. Кабатланмас, үзенчәлекле образ тудырырга безгә «Люкс» бутигы белгечләре ярдәм итәр.

Рәмзия КАШАПОВА







ГӨЛНАРАДАН ТӘМЛЕ СЮРПРИЗ



«Сөембикә»дә яңа проект — быел тәмле ризыкларны татар дөньясында танылган артистлар пешереп күрсәтәчәк. Сәхифәбезне җырчы Гөлнара ТИМЕРҖАНОВА башлап җибәрә. Гөлнара Башкортстанда туып-үскән кыз. Аш-суга бик оста. «Әнинең безне нәрсәгәдер өйрәтеп утырырга вакыты булмады. Авылда эштән бушап буламы соң? Якыннарым, ашарга тәмле пешерәсең, диләр икән, ул — тормыш өйрәткән тәҗрибә», — ди җырчы кызыбыз. Тамашачы күңелен «Йолдызлар яңгыры», «Өйдә буран булмасын», «Ике яр» һәм башка җырлары белән яулаган Гөлнара Казанга 16 яшендә чыгып китә. Нияте — музыка училищесына укырга керү. Аны уңышлы тәмамлап, укуын консерваториядә, Татарстанның халык артисты Әлфия Заһидуллина классында дәвам итә. Бүгенге көндә Гөлнара өч айлык кызы Айзифаны үстерү белән мәшгуль. Ә инде берәр җирдә концерты булса, бәләкәй Айзифа әтисе Ильер яки абыйсы Идел кулына күчә. Менә бу ризыкны әзерләгән арада да Айзифа әтисе кулында сабыр гына утырып торды.

Кирәк:

- 500 г фарш;
- 2 йомырка;
- 3 аш кашыгы сохари оны;
- 1 чәй кашыгы горчица;
- 1 чеметем төелгән кориандр;
- 1 бәрәңге;
- 30 г каты сыр;
- 2 аш кашыгы майонез.

Эчлек өчен:

- 300 г шампиньон;
- 1 баш зур суган;
- 1 кишер;
- үсемлек мае.

Эш барышы:







■ Фаршка бер йомырка сытып, сохари оны, горчица, тоз-борыч һәм кориандр кушабыз. Барысын да яхшылап болгаткач, 20 минутка суыткычка куеп торабыз.

■ Ит фаршын фольга өстенә юка итеп җәябез. Эчлекне җәемнең уртасына буйдан-буйга салып чыгабыз. Фаршны ике ягыннан фольга ярдәмендә өскә таба күтәреп, төрәбез.

■ Пешеп җитәргә 20 минут кала, фольганы ачып, ит өстенә эре угычтан уылган сыр түшибез. Кабат мичкә тыкканда фольганы ачык килеш калдырабыз.







■ Ул арада эчлек әзерлик. Шампиньонның бер кат элпәсен салдырып (юсаң, гөмбә су сеңдерә дә, кыздыруы читен була), ваклап турыйбыз. Табага үсемлек мае тамызып, гөмбәне кыздырабыз.

■ Чи бәрәңгене кабыгыннан әрчеп, вак угычтан уабыз. Шуңа бер йомырка сытабыз, майонез салабыз. Барысын бергә яхшылап туглап, ит өстенә ягабыз. Төргәкне фольга белән томалап, 1 сәгатькә мичкә тыгабыз.

■ Турамый калдырган гөмбәнең ике ягын да табада кыздырып алабыз. Табынга биргәндә төргәкне 3 см телемнәргә телеп, кыздырган гөмбә белән бизибез. Янына яшелчәләр тезәбез.



■ Гөмбә бераз кызгач, аның янына ваклап туралган суган, угычтан уылган кишер өстибез. Берничә гөмбәнең урта бер өлешен турамый гына кырыйга алып куябыз. Аларны соңыннан майда кыздырып алырбыз. Болар ризыкны табынга биргәндә бизәр өчен кирәк.



Бу матур «читекләр»не бәйләргә безне Ания ГАТАУЛЛИНА өйрәтә. Ания Марий Иле Бәрәңге районының Мазар Башы авылы кызы. Татар дәүләт педагогика университетының татар филологиясе факультетын тәмамлап, дүрт ел мәктәптә укыткан. Хәзергә биш яшьлек уллары Йосыфны үстерә. Аниянең әнисе дә бәйләргә бик оста, күп нәрсәне ул аңардан өйрәнгән икән. Ания бәйләгән киемнәр өйдәгеләрне генә җылытып калмый, ул әле башкаларга да бәйли. Шул арада төрле күргәзмәләрдә катнашырга да вакыт таба.





ӨЙ «ЧИТЕГЕ»

Кирәк:

(37 нче үлчәмле «читек» өчен)
• шул үлчәмдәге киез аслыклар (базарда сатыла);
• дермантин яки ясалма күн (тукыма кибетләрендә бар);
• 100–150 г ак төсле йон җеп (100 м = 100 г);
• 100 г зәңгәр төсле (100 м = 100 г);
• 4–5 нче номерлы ыргак;
• кара төсле бик нык тегү җебе;
• камыт энәсе.








Эш барышы:

■ Киез аслыкны дермантин өстенә салып, эзен төшерәбез һәм кайчы белән шул эздән кисәбез. Камыт энәсенә кара җеп саплап, дермантин белән киезне элмәк җөе белән тоташтырабыз. Дермантинның шома ягы аста булсын. Безнең җөй 76 элмәкле булып чыкты.

■ Ак йон җебен ыргак белән шушы элмәк аша тартып алып, чалусыз багана (столбик без накида) белән бәйләп чыгабыз. Бәйләмне арткы яктан уртадан башларга кирәк. Дүрт рәт бәйләгәннән соң, җепне өзеп, очын яшерәбез.







■ **«Читек»нең йөзен бәйлибез.** Алгы якның кыл уртасыннан дүрт күзне чалусыз багана белән бәйлибез, бишенче күзне сикертеп кенә үтеп, алтынчы күзне тоташтыручы элмәк белән бәйләп алабыз. Бәйләмне борып тотып, кирегә бәйләп китәбез. Бишенче күзне бу юлы да сикертеп үтеп, алтынчысын тоташтыручы элмәк белән бәйлибез.

■ Өченче һәм дүртенче рәтләрне бәйләгәндә, бишенче күзне исә чалусыз багана, алтынчысын тоташтыручы элмәк белән бәйлибез. Алдагы рәттә алты күзне бәйлибез, җиденчесен тоташтыручы элмәк белән бәйләп алабыз, шул рәвешле һәр рәтне чыкканда берәр күзгә арттыра барабыз. Барлыгы егерме рәт бәйлибез.

■ Егерменче рәтне чыккач, бәйләп килгән уңайга тубык кырыйлап бәйләп китәбез. Йөзлеккә килеп җиткәч, андагы беренче күзне тоташтыручы элмәк белән бәйләп, икенче күзне чалусыз багана белән бәйлибез. Бәйләмне борып тотып, кирегә таба бәйләп китәбез. Йөзлеккә килеп җиткәч, янә беренче күзне тоташтыручы элмәк, икенчесен чалусыз багана белән бәйлибез. Шул рәвешле дүрт рәт бәйләнә.

■ **Куныч.** Ул бизәк белән бәйләнә. Рәт башында 3 күзле чылбыр үреп (күтәрү баганасы), беренче күз аша чалулы өч багана бәйлибез. Икенче күзне сикертеп үтеп, ыргакны өченче күзгә кертәбез һәм янә чалулы өч багана бәйлибез. Шулай, рәт беткәнче бәйләнә. Рәтне тоташтырабыз һәм өч күзле чылбыр үреп, беренчесе кебек үк, икенче рәтне бәйлибез. Бу юлы чалулы баганалар сикертеп киткән күзләр өстенә бәйләнә.

■ Өченче һәм дүртенче рәтне зәңгәр җеп белән бәйлибез. Ак җепне өзеп торабыз. Бишенче-алтынчы рәтләр ак җеп белән бәйләнә. Бизәге шул ук: рәт башында өч күзле чылбыр, бер күз аша чалулы өч багана, икенче күзне сикертеп үтәбез... Калган өч рәтне зәңгәр җеп белән бәйләп, бәйләмне төгәллибез.

КИНӘШ.

■ Йоннан бәйләнгән әйберләрне 30-35 градус җылылыктагы суда махсус порошок белән юалар. Артыгын ышкымаска, сыкмаска тырышырга кирәк. Чайкаганда да шул ук җылылыктагы суда чайкыйлар, югыйсә кием утыра.

■ Нык керләнгән әйберне башта сабынлы суга салып, 3-4 сәгать тоталар. Әмма төрле төстәге җептән бәйләнгән киемнәрне суга озак салып тотсаң, төсе йогарга мөмкин, шуңа күрә сак булыгыз. Бәйләнгән свитерлар да суда озак торганда җәелә.

■ Әгәр юганда әйбер киезләнсә, аны 10 л суга 3 аш кашыгы нашатырь спирты, 1 аш кашыгы скипидар һәм 2 аш кашыгы аракы кушылган эремәдә тоталар.

■ Йон әйберләрне юу өчен яңгыр яки кар суы әйбәт. Яңгыр суы булмаса, суны нашатырь спирты салып йомшарталар. 10 л суга 5 аш кашыгы нашатырь салына. Нашатырь спирты йонның сыгылучанлыгын, ялтыравыгын кайтара.

■ Йон киемнәрне көя күбәләгеннән саклау өчен шактый тырышырга кирәк. Көя күбәләге зәһәр исләрне яратмый. Сабын, әрем, яңа газета, лаванда, борыч, эрбет, сары мәтрүшкә, канәфер исләренә якын да килми ул.

■ Киемдә көя күбәләге кортын күрсәгез, аны беразга салкынга чыгарып элү дә җитә. Кояш нурлары да бик тиз юк итә аларны. Киемгә ияләнгән көя күбәләгеннән котылу өчен, шкафка ике көнгә «Антимоль» ише төймәләр куеп торалар. Бу вакытта шкаф ишеген ачмый торырга кирәк.

■ Шәл бәйләүче апалар йон киемнәрне оннан, шикәр комыннан бушаган капчыкларда сакларга киңәш итә, аларга да көя күбәләге керми икән.

Теләсә нинди терек җисем таркалуны яңару җиңеп барган чакта гына яши ала. Шушы тигезлек бетеп китсә, җисем әкренләп «сүнә» башлый. Чынында, бөтен тигезлек әчетү-тергезү реакцияләренең балансына бәйле. Әмма әчету реакциясе тизрәк үтә, чөнки ул энергия бүлеп чыгару белән бара. Ә тергезү реакциясе үзе энергия таләп итә. Җимерү һәрчак җиңелрәк бит ул. Димәк, авыруны җиңү, шул рәвешле гомерне озынайту өчен җисемнең энергиясен арттырырга кирәк. Моның өчен антиоксидантлар бар. Әчетүне һәм таркалу, картаю процессын көчәйтә торган ирекле радикалларга каршы шулар көрәшә дә инде. Безнең сәламәтлек сагында тора торган яшерен «көчләр» турында сөйләшеп алырбыз.



ЯШЬ КАЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Инсулинны тәртиптә тоту

Альфа-липой кислотасы (АПК), суда яки майлы мохиттә эри торган башка кислоталардан аермалы буларак, бик универсаль яки тиз эрүчән. Ул ирекле радикалларны организмның теләсә кайсы җирендә юк итә ала. АПК теләсә кайсы күзәнәккә, хәтта баш миендәге күзәнәкләргә дә үтеп керә ала. Ә аның төп тәэсир итү кыры исә – нерв чирләре, бигрәк тә диабетка бәйле нейропатия. Бу хасталык аяк авыртулар һәм аларның сизгерлеге кимү рәвешендә чагыла. Канда глюкоза күбәйгәндә нерв күзәнәкләрен ирекле радикаллар зарарлау сәбәпле килеп чыккан бу хасталыкны дәвалаганда да липой кислотасының антиоксидант үзлекләре диабетлы кешеләрнең беренче ярдәмчесе.

! Гәрчә липой кислотасын кешенең үз күзәнәкләре җитештерә алса да, без аны ризыктан — шпинаттан, иттән, бавырдан, чүпрәдән алабыз.

Күзәнәкләрдәге яшьлек

Коэнзим Q10 матдәсе бавырда ясала. Тик менә утыз яшьтән соң аның микъдары кими башлый. Һәм 70-80 яшьләргә сабый баланыкы кадәр генә кала. Ә бит ул өлкән яшьтә дә бик кирәк. Чөнки ул җитәрлек микъдарда булган чагында атеросклероз, йөрәк-кан тамырлары авырулары, гипертония баш калкытмый тора. Безнең организмда коэнзим микъдары нормадагының 75 проценты кадәр генә калса, без авырый башлыйбыз икән. Ул бигрәк тә симез кешеләргә файдалы, чөнки артык майны энергиягә әйләндерә. Шулай ук битне шомарта, тирене яхшырта.

! Иттә, сөттә, сояда, күкәйдә, балыкта, шпинатта, арахиста, җиләк-җимештә бар. Тик ризык аша кеше норманың бик азын гына ала. Нибары — 5-15 миллиграмм, ә кимендә 30 миллиграмм кирәк.

Баш мие өчен азык


Дозагексин кислотасы озак яшәү өчен гаять тә кирәкле майлардан санала. Ул нерв күзәнәкләренең яңарышын тәэмин итә, хәтерне яхшырта, зиһенне көчәйтә. Баш миенә җиңел үтеп керә торган дозагексин кислотасы Паркинсон авыруын кисәтү, инсультны булдырмау өчен кирәкле күзәнәкләрнең үсешен тоткарлый. Ул шулай ук баш мие формалашу һәм акыл үсеше өчен кирәкле, балаларның зиһен үсешен яхшырту өчен зарур матдә булып тора.

! Организм дозагексин кислотасын башка майлы кислоталардан тартып алырга сәләтле. Ләкин бу гына әз. Шуңа күрә сельдь, скумбрия, форель кебек балыкларны яратыгыз.

Вируслардан саклану

Яшьлекне озынайту өчен селен матдәсе бик кирәк. Чөнки ул һәртөрле яман шешләрнең үсешен тоткарлый, хәтта СПИДка каршы тору сәләтен арттыра. Ул шулай ук зарарланган күзәнәкләрне яңарта, иммунитетны ныгыта, вирусларга, зарарлы бактерияләргә каршы торучанлыкны көчәйтә. Тән тиресе, тырнаклар, чәчләр тәртиптә булсын өчен дә селен кирәк. Бигрәк тә ул нервларны ныгыту хасиятенә ия: гасабилыкны киметә, кәефне яхшырта.

! Яши-яши организмда селен микъдары кими. Шуңа күрә аны аптекадан алып эчәргә яки селенга бай ризык ашарга киңәш итәбез. Көнбагышта, иттә, тунец балыгында, кылыч балыкта, сарымсакта селен күп. Бигрәк тә бразилия чикләвеге селенга бай. Бер данә чикләвектә селенның бер көнлек дозасы бар.


КУЧКАР. Аттан алда чапмагыз. Гаиләдәге мөнәсәбәтләргә дә, эштәгесенә дә кагыла бу. Вакыйгаларны ашыктырмавыгыз хәерле, бар да үз җаена гына барсын. Белем эстәү белән шөгыльләнсәгез, уңыш килер. Яңа белемнәр киләчәктә финанс ягын тотрыклыландырыр.


ҮГЕЗБОЗАУ. Планнарны үзгәртергә туры килмәгәе. Теләкләр белән мөмкинлекләрнең туры килмәве бераз кәефне кырып кыруын, әмма артык кайгырмагыз, эчке сиземләүгә ышансагыз, оттырмассыз.


ИГЕЗӘКЛӘР. Сезгә бу айда фикерләүдә генә түгел, гамәл кылуда да хәрлек кирәк. Кемнеңдер сүзен тыңлап йөрсәгез, эшегезне уңышлы тәмамлый алмассыз. Яңа һөнәрләргә өйрәнү өчен яхшы вакыт.


КЫСЛА. Эчке сиземләвегез бик нык ярдәм итәчәк. Уңышлы ай. Эшләрнең гөрләп баруы күңелне күтәрә. Күңел күтәренкелеге бәхет хисен көчәйтә. Әмма булганыннан артыгына ымсынмагыз, юкса, уңыш сездән качарга да мөмкин.


АРЫСЛАН. Мөстәкыйльлеккә омтылышыгыз көчле анысы, әмма үзгәрешләр яратмавыгыз яман. Айның беренче чиреге уңышлы узар, җәмгыятьтәге урыныгыз ныгыр. Яңа тәкъдим булырга тора, кабул итсәгез, отарсыз.


СӨМБЕЛӘ. Уңыш та, уңышсызлык та үз-үзеңә ышанычтан тора. Авыррак ай, әмма юлыгыздан тайпылмый барсагыз, планнарыгыз тормышка ашар. Эчке дөньягызны үзгәртердәй мөһим вакыйга булуы ихтимал. Ай башында керешкән эшләр яхшы нәтиҗә бирер, финанс ягы тотрыклыланыр.


БИЗМӘН. Аралашулар, яңа танышулар ае. Өстәмә вазыйфалар килеп чыгарга мөмкин, алар сезнең көчне алыр. Ай башында башлаган эшләр хәерле тәмамланачак. Ай ахырына таба сүлпәнлек тоярсыз, мөһим эшләрне ул вакытка калдырмагыз.


ЧАЯН. Бу ай күпкә өметләндерәчәк: тормышыгыз әкрен, әмма нык адымнар белән яхшыруга таба бара. Уңыш көттеребрәк килер, сабыр булыгыз. Ай башында корган планнар тормышка ашар, иң мөһиме: ялкауланмагыз, үз-үзегезне җиңегез.


УКЧЫ. Мәшәкатьле булса да, уңышлы ай. Алда өмет уты күренер, әмма ул утны бик түземнәр генә дөрләтә алыр. Ай башында кызыклы һәм кирәкле мәгълүмат алырсыз, ул тормышыгызга дөрес юнәлеш бирер.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Яңа казанышлар ае. Айның беренче чиреге аеруча куанычлы, шатлыклы булачак. Үз-үзегез белән горурланып куярдай гамәл кылырсыз, тирә-юньдәгеләрдән дә мактау ишетерсез. Акчагызны сак тотыгыз, ашыгып әйбер сатып алмагыз.


СУКОЯР. Тормышка үзгәреш кертердәй яңа танышлар очратырсыз. Бу ай һәр өлкәдә дә уңышлы булырга охшаган. Яңа идеяләр туып кына тора. Әгәр дә әз генә күбрәк тырышлык күрсәтсәгез, ул идеяләрнең күбесен гамәлгә ашырачаксыз.


БАЛЫК. Айның беренче яртысы уңышлы булачак. Катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә туры килүе бар. Көч тә, кыюлык та җитәрлек сездә. Барысын да уңышлы башкарып чыгарсыз. Артык хыялга бирелүегез эшегезгә зыян салырга мөмкин, җиргә төшегез.

*гыйнвар*да кабынган йолдызлар

Татарстан



Диләра ЗӨБӘЕРОВА (9.01.1930–15.12.2000) – **язучы, журналист.**
Татарстанның Сарман районы Күтәмәле авылында туган дип язылса да, чынлыкта, төрмәдә туа. Әтисен – мулла нәселеннән чыккан Гази абыйны, аннан соң «халык дошманы хатыны» дип, әнисен дә кулга алалар. Диләра, җидееллык мәктәпне тәмамлап, Алабуга педагогика училищесына укырга керә, аннан Казан дәүләт педагогика институтында укый. 1952 елны Татарстан китап нәшриятында эшли башлый. 1962 елдан алып пенсия яшенә җиткәнче хәзерге «Сөембикә» журналында эшли. «Кичер, сөеклем», «Кызлар, кызлар...», «Яшьләр күңеле», «Куш өянке шаһит» исемле хикәя һәм повесть җыентыклары басылып чыга. 1980 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Россия



Галина УЛАНОВА (8.01.1910–21.03.1998) – **балерина.**
Санкт-Петербургта туа. Әтисе – Сергей Уланов, балет режиссеры. Әнисе исә хореография училищесында укыта. 9 яшендә хореография училищесына укырга керә. 1928 елдан хәзерге Мария театрында эшли башлый. 19 яшендә беренче төп партисен – «Лебединое озеро» спектаклендә Одетта-Одиллия ролен башкара. 1944 елдан – Мәскәүдәге Зур театрда прима-балерина. 1962 елда балерина карьерасын тәгәлләп, Зур театрда балетмейстер-репетитор була. Әле үзе исән чагында ук Стокгольм һәм Санкт-Петербургта аңа һәйкәлләр куела. СССРның халык артисты, дүрт мәртәбә СССР премиясе лауреаты.

Чит илләр



Джулия ОРМОНД (4.01.1965) – **актриса.**
Англиянең Эпсоме шәһәрендә туа. Кечкенәдән спортны ярата. Актриса булу уе башына да кереп карамый – рәссам булырга хыяллана. Бер ел сәнгать мәктәбендә укыгач, аны ташлап, Лондондагы Веббер-Дуглас исемендәге драма сәнгате академиясенә укырга керә. Актерлык эшчәнлеген «Молодая гвардия» (1991) һәм «Сталин» (1992) фильмнары белән башлап җибәрә. 1993 елда «Дитя Макона» фильмында уйнап, Европа тамашачысына танылa. Актрисаның иң уңышлы эшләре дип «Первый рыцарь» һәм «Сабрина» фильмнарында башкарган рольләрен атыйлар. 1998 елда Никита Михалковның «Сибирский цирюльник» фильмында уйный.





ТӨРКИ ДӨНЬЯ ҖЫРЧЫСЫ

Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Сәгыйдә Сираҗиеваның иҗаты – бөтен төрки дөньяның ямен, гамен, моңын бергә туплаган галәм. Ул колачлаган темаларны бер сүз белән әнә шулай гомумиләштереп тә булыр иде. Шул ук вакытта без аның архивында Тукай сериясе булуын да («Милли моң», «Туган тел», «Күңелем Тукай белән сөйләшә»); риваятьләр, дастаннар нигезендә эшләнгән шәкелләр барлыгын да («Бөек дала», «Хан кызы Шан», «Хан кызы Рабига»); тарихи теманы чит итмәвен дә («Бөек Болгарстан» триптихы, «Болгар» сериясе) беләбез. Халыкара, Бөтенроссия, республика, шәһәр күргәзмәләре уңаеннан басылган утыздан артык каталогта күрергә була рәссамның репродукцияләрен. Бер сулышта башкарылгандай, ниндидер эчке эзлеклелек, нәзакәтлелек, шигъри моң берләштерә рәссамның эшләрен. Колак салсаң, вакыт-вакыт бишек җырларын, Зөһрә кызның чулпы чыңын, йә булмаса киң даланың төнге тынлыгын ярып үткән тояк тавышларын ишеткәндәй буласың...

Бу моңга Румыниядә яшәп иҗат итүче кырым татары – шагыйрь Мурат Танер да таң кала. Һәм... төрле еллардан 37 шагыйрьнең шигырьләре кергән антологияне бизәр, ягъни бер аһәңдә иҗат итәр өчен нәкъ менә Сәгыйдә Сираҗиева иллюстрацияләрен файдалана. Китапка сүз башы язган Рам Кришна Сингх (Һиндстан): «Сәгыйдәнең кирәгеннән артык камил сәнгате ул – эчке рух тантанасы. Ул җанның нечкә кылларын Шәрык һәм Гареб динамикасы белән берләштерә. Тирән, нәфис иллюстрацияләре – вакыт-вакыт мистик риторика элементлары булган Рух авазы кебек», – ди.


Әйе, рәссамның үз алымы, үз стиле. Күргәзмәгә килүче тамашачы, картиналарга текәлеп, һәр детальне җентекләп өйрәнергә юкка гына тырышмый. Беренче карашка бар да бик гади сыман: ак кәгазьгә гель-каләм белән төрткеләр генә төртеп чыгасы. Кайда һәм күпме төртергә кирәген дә белсәң... Сәгыйдә ханым күргәзмәләр вакытында осталык дәресләре уздыруны артык эшкә санамый. Кызыксыналар икән, өйрәнсеннәр генә... Монда да ул олы җанлы педагог булып кала. Остаз шәкертләренең күргәзмәләрен уздыруны да гадәткә керткән. Аның укучылары Санкт-Петербург, Мәскәү, Новосибирск, Саранск, Алабуга, Казан, Чаллы шәһәрләрендә узган Халыкара конкурсларда катнашып, мәктәпкә диплом арты диплом алып кайта. Араларында мәдәният идарәсе стипендиатлары булу да – зур мәртәбә. Бүгенге көндә 60 тан артык укучысы Турин (Италия), Болгария, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Ижау, Чаллы югары уку йортларында белем ала – тормышын сәнгать белән бәйләргә ниятли. Шуңа күрә дә бүген аны һәр ике як: Рәссамнар берлеге дә, шул исәптән – милли сәнгатьне пропагандалауга йөз тоткан «Тамга» иҗат төркеме дә, Сәгыйдә ханым укытучы булып эшләгән Чаллы шәһәренең 1 нче Балалар сәнгать мәктәбе дә үзенеке саный.

Расиха ФӘИЗОВА















СӘГЫЙДӘ СИРАҖИЕВА





Сәгыйдә Сиражиева эшләре

2015 елда мөселман бәйрәмнәре һәм истәлекле көннәр

(һиҗри буенча 1436—1437 еллар)

3 гыйнвар — Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, сәдака (зәкят) өләшенә.

20 апрель — изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

23 апрель — Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдулла һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

15 май — Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

21 май — Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

1-2 июнь — Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, игелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлләрен һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

18 июнь — изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

13 июль — Кадер кичәсе.

17 июль — Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете.

23 сентябрь — Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

24 сентябрь — Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме, ул өч көн дәвам итә.

25, 26, 27 сентябрь — Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус догалар укыла.

14 октябрь — 1437 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына. Бу көнне Аллаһы Тәгалә игелек кылган кешеләрнең гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

23 октябрь — Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән игелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәен (626—680) җәзалап үтерелгән көнне изге вә хөрмәтле санап, ураза тоткан.

13 ноябрь — Сафәр ае башланган көн.

22 декабрь — Мәүлид кичәсе.

Ай исәбенә нигезләнгән һиҗри календареның икенче ае 29 көннән гыйбарәт.

Төзүче-мөхәррир — хаҗи Абдулла ДУБИН.